PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 3 / 2022

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ *тормыш кагыйдәләре*

«Әле дә син бар әле дөньяда» БЕР ҖЫР *тарихы*

«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ» *бәйгесе яңа исемнәр*

Рәмзия РӘФЫЙКОВА:

«Һәр хатын-кыз матурлыкка төренеп яшәсен!»

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып киткән әниегез нәрсәләр искә төшерә, нинди истәлекләр сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең туй күлмәген киеп көзге алдында бөтерелгән мизгелне сурәтләгән фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син, кызым!» – дип әйтәдер әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән бер мизгел дә көтәбез!

■ Әти-әнинең туе белән безнең туй арасы 25 ел икән. Аларныкы – 14, безнеке 16 августта. Туй алдыннан күлмәкне кешедән генә алып тору турында да сүз булган, ахрысы, әни моны еш искә төшерә иде. Ә аның үзе тектереп киясе килгән. Фотога да төшә алмагач... Туйларының кадерле бер ядкаре булган күлмәк әнинең сандыгында саклана. Үсмер чакта, әни өйдә югында, алып, аны киеп караганым да хәтеремдә. Туй фотоларыбыз булса да, балдаклар алышсак та, туй күлмәген кемгәдер бирәсем, сатасым килмәде. Минем күлмәк тә сандыкта саклана. Туй күлмәгем кызым Алиягә ярый инде. Аның үзенә дип алган күлмәген кияр көнен күрергә иде дип телим. Бу инде һәрбер әнинең теләге. Балаларның бәхетле булуларын күреп сөенергә язсын безгә!

Айсылу ГАЛИӘХМӘТОВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Рәмзия Рәфыйкова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 21.02.2022 ел.
Чыгу көне: 1.03.2022 ел.
Заказ О-0515
Тираж 10525

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Алена Әскәрова эше

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Минем белән килешерсездер: тормышта кайта-кайта уйландыра торган очраклар була. Үзем белән булган шуларның берсе турында сөйлисем килә.

Университетны тәмамлагач, беренче кызым белән йөкле чакта, берничә ай «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») редакциясендә эшләп алдым. Ул чорда редакцияләрдә компьютерлар әле юк – газета типографиянең үзендә җыела иде. Мин – редакция белән типография арасында элемтә тотучы. Вазыйфам әллә ни авыр түгел: әзер текстларны цехтагыларга төшерәм, басылган газета битләрен редакциягә алып менәм.... Типографиянең верстка цехында хатын-кызлар гына диярлек эшли, алар белән эш арасында серләшеп тә алабыз. Минем бала табар вакытым җитә, шуңадыр сүз күбрәк гел яңа туган бала тирәсендә әйләнә: нигә эче авырта, ничек коендырырга, ничә тапкыр ашатырга... Ә бер көнне ирләр турында да сүз чыкты. Һәркем үзенекен искә төшерде:

– Мин яшь бала белән декрет ялында утырганда, ирем кайтуына бөтен эшне эшләп куя идем. Ашарга пешкән, өем җыештырылган, бауда – юып элгән бала чүпрәкләре кибә...

– Ә мин, әнә сине көтәләр дип, ваннага җебетергә салган бала чүпрәкләренә ымлап кына күрсәтә идем...

Үземнең ул чактагы халәтемне күз алдыма китереп, хәзер дә елмаеп куям. Яңа кияүгә чыккан, беренче баласын көткән кичәге студент, бу апаларның әле берсенә, әле икенчесенә карап: «Боларның кайсысы дөрес икән?» – дип югалып басып торган идем...

Безнең гаиләдә беренче модель дә, икенчесе дә урнашмады – үзебезнеке барлыкка килде. Еллар узды, тәҗрибә арткан саен, бу хәл ешрак искә төшә һәм «һәрбер хатын-кызның үзенең бәхетле гаилә формуласы бар» дигән фикерем ныгый гына бара. Ул формула бик күп төшенчәләрне туплаган. Әмма алар арасында, минемчә, иң мөһиме – сабырлык һәм зирәклек. Бу санныбызда әлеге фикер белән сез берничә тапкыр очрашырсыз әле.

Бәйрәм белән! Бәхетле булыйк!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнен тышлыкта

«Нәрсәгә дә булса ирешер өчен бик-бик теләргә һәм ул теләкне уңай эмоцияләр белән баетырга кирәк. Шул чакта һәркемнең хыялы чынга ашачак...»



16

Тәтеш принцессасы
Эльмира Закирова

6



«Мин тизлек яратам!»
Чулпан Галиәхмәтова

10



Акча санаганны ярата
Фәнзилә Мостафина

22



«Наз баланы бозмый»
Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» 14–21

Татар дөньясы

«Ирeңнeң әнисен ярат!» 24
Гүзәл Шәрифуллина

«Миңа малай кирәк!» 27

Ефәк баулы былбыл кош бардыр синең илеңдә... 28

Дисбе анасы 32
Гөлнур Сафиуллина

Мәдәни тормыш

Минем Җирдән үтеп барышым... 34
Таңчулпан

Өлгерәсе иде!.. Таяныр талларың булмаса... 36
Ләлә Сабирова

Яшәеш

Хатлар 46

Күзләремә бер каравың җитә... 52
Фәния Сәетгәрәева-Габидуллина.

«Мәхәббәт — дуслыкның бер күренеше генә». 54

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау—җавап 56

Ураза тотарга әзерләнәбез 58

Матур иреннәр сере 59

Өенең яме — гөлләрдә 62

Тест&йолдызнамә 63

Соклану хисләремне сурәтлим 64
Зилә Нигъмәтуллина

42

Олы юлның сикәлтәләре
Лирон Хәмидуллин

48

Чикнең теге ягында
Алсу Шакирова

60

Брауни
Алмаз Гафиятов тәкъдим итә

»





Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның тормыш кагыйдәләре

(Төрле елларда чыккан интервьюларыннан)

«МИН ТИЗЛЕК ЯРАТАМ!»

РЕСПУБЛИКАГА КҮБРӘК ЧИТТӘН РЕСУРСЛАР АЛЫП КЕРЕРГӘ КИРӘК – акча, акыл, компетенцияләр. Ә моның өчен урыннарда шартлар булдыру, килешергә өйрәнү зарур, ә иң мөһиме – дөнья буйлап йөрергә, йөрергә, йөрергә...

ҮТӘ АЛМАСЛЫК КАРШЫЛЫКЛАР БУЛМЫЙ. Тормышның бу чорын йә әлеге хәлнең үткәнен күтәргә генә кирәк. Син бит исән-сау, димәк, нәрсә дә булса эшли аласың. Уйлый аласың!

«Минем башка яшисем килми», – диләр кайберәүләр. Ничек инде яшисе килмәсен?! Аллаһы Тәгалә безгә гомер биргән. Һәр иртәне күзең ачуга исән булганың, уянганың өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтергә тиешсең. **ГОМЕР – БЕР ГЕНӘ УЛ.** Бер кешенең дә тормышы бал да май гына түгел.

Спорт ул – спорт! Эшне, динне алыштыра алмый, әмма кешенең холкын формалаштыра. Спорт белән шөгыльләнгән кеше – сәламәт һәм максатчан. **СПОРТСЫЗ ЯШӘРГӘ ЯРАМЫЙ.** Эшең никадәр генә күп булуга карамастан, физкультура өчен вакыт табарга кирәк.

МИН – ПАТРИОТ. Әти-әнием, мәктәп, институт, эшли башлагач, өлкән иптәшләр мине шулай тәрбияләде. Мин – көчле Россия өчен. Мин – көчле гаилә өчен.

ҮЗЕНЕҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ, ДИНЕ БУЛГАН РОССИЯ КЕШЕСЕ БУЛЫРГА ТЕЛИМ. Ислам дине – минем дин. Әти-әниемнәр дине. Бәйрәмнәрдә мәчеткә барам, әмма намаз укырга вакытым юк. Динебезне сакларга тиешбез. Мин аны улыма тапшырачакмын, ул – балаларына...

ҺӘРКАЙСЫГЫЗ МИНЕ ТӘНКЫЙТЬЛИ АЛА: ЧӨНКИ БАШКАРГАН ЭШЛӘРЕМ ДӘ КҮП, ДӘГЪВА БЕЛДЕРЕРЛЕК УРЫННАР ДА БАР. Ә мин, кызганыч, сезгә дәгъва белдерә алмыйм...

Эш юк дип әйтү – эшләмәскә сәбәп ул. Ишегалды себерүчеләр, вахтерлар, йөк ташучылар һәрвакыт кирәк. Әмма кешеләрнең эшлисе килми. Эшкә килгән өчен генә хезмәт хакы бирүләрен теләүчеләр бар. Минем әти 29 ел Саба урман хуҗалыгы директоры булды. Безнең бакча, сыерлар, бозау, кош-корт бар иде. Әни 79 яшенә кадәр бакча, сыер тотты. Ул бер кешене дә яллап эшләттермәде. Башта без өч малай, аннан соң балаларыбыз ярдәм итте. Кагыйдә шундый иде. Әни безгә ипи пешерде, һәркайсыбызга атна саен сөт җибәрде. Һәрберебез хәлле, әнигә ярдәм итәр өчен кеше ялларга мөмкинлегебез бар иде. Әмма юк. Ярамый. **ТЫРЫШКАН КЕШЕ ХӘЕРЧЕ БУЛА АЛМЫЙ.** Әгәр берни эшләми өйдә ятасың икән, әлбәттә, ашарың булмаячак.

РӘХӘТЛӘНЕП ТУГАН ЙОРТЫМА КАЙТАМ. Әни, өлкән яшьтә булганлыктан, пешерә алмый инде. Миңа балачакта ашаган ризыклар ошый. Борай, ит, бәрәңгедән пешерелгән гап-гади ашлар. Бу – үз ризыгыбыз, өйдә әзерләнгән.

МИН – УРМАНЧЫ УЛЫ. Урманда миңа бик рәхәт.

ҮСЕП КИЛҮЧЕ БУЫННЫ ТӘРБИЯЛӘҮГӘ ТАГЫН ДА ИГЪТИБАРЛЫРАК БУЛЫРГА КИРӘК БЕЗГӘ. Элек мәктәпләр алдында балаларны тәрбияләү бурычы тора иде, хәзер, миңа калса, бу мәсьәлә бераз читтә калды. Тиккә генә Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә, сыйныф җитәкчеләренә өстәмә түләү булдырылмады. Мәктәп – белем белән бергә һәрвакыт тәрбия үзәге дә иде. Димәк, кайдадыр баллар, уку сыйфаты, олимпиадалар белән мавыгып киттек.

АТА-АНАЛАР БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ. Әгәр атаана җаваплылык тоймый икән, мәктәп кенә моны хәл итә алмый.

ИНТЕРНЕТ ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТТЕ, ӘЛБӘТТӘ, МОНЫҢ ЯХШЫ ЯКЛАРЫ БИК КҮП. ӘММА ЯХШЫЛЫК БЕЛӘН БЕРГӘ НЕГАТИВ ӘЙБЕРЛӘР ДӘ БАР. Без хәзер үзебезне интернетсыз, цифралы трансформациясез күз алдына да китерә алмыйбыз. Сәгатьләр буе гаджетларда утыру, кирәксез мәгълүмат җыю... Ул мәгълүматны тулысынча аңлап һәм эшкәртеп тә бетереп булмый. Балалар өчен бу бигрәк тә куркыныч.

Әгәр алга киткән илләрдәге ата № 1, ата № 2 гаилә моделен үрнәк итеп алабыз икән, моның ахыры нәрсә белән тәмамланганын беләбез. Бу безнең рухка, дингә, традицияләргә туры килми. **АТА-БАБАЛАРЫБЫЗ БИК ЗИРӘК ҺӘМ ҮТКЕН АКЫЛЛЫ БУЛГАННАР. МӘДӘНИЯТЕБЕЗГӘ, ТРАДИЦИЯБЕЗГӘ, ДИНЕБЕЗГӘ САЛГАННАРНЫҢ БАРЫСЫН ДА САКЛАРГА КИРӘК. САКЛАМЫЙБЫЗ ИКӘН, ҮЗЕНЧӘЛЕГЕБЕЗНЕ ЮГАЛТАЧАКБЫЗ.**

Фото: www.president.tatarstan.ru

ЛАЕКЛЫ КЕШЕЛӘР РЕСПУБЛИКАДА БИК КҮП. Моны хакимиятнең федераль органнарында эшләүче коллегаларыбыз раслый. Татарстан һәрвакыт үз кадрлары белән дан тотты.

Теләсә нинди мавыгу өчен вакыт табып була. **БАРЫ ТИК ИРТӘ ТОРЫРГА, СОҢ ЯТАРГА ГЫНА КИРӘК.**

МИН, ГОМУМӘН, ТИЗЛЕК ЯРАТАМ – ЭШТӘ ДӘ, АВТОУЗЫШЛАРДА ДА.

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ – МИНЕМ УКЫТУЧЫМ. Бу күп нәрсә турында сөйлидер дип уйлыйм. Минтимер Шәрипович белән иңне-иңгә куеп 12 ел эшләдек. Без бер организм кебек. Теге яки бу проблемага аның ничек каравын 95 процентка беләм.

ТАТАР КЕШЕСЕ КАЙДА ГЫНА ЯШӘСӘ ДӘ – ҺӘР ҖИРЛЕКТӘ УҢЫШКА ИРЕШӘ, МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРӘ.

Бала туган телен мәктәптә генә түгел, өйдә дә өйрәнергә тиеш. Ана телен бала иң элек гаиләдә иң якын кешеләреннән – әти-әнисеннән, әби-бабасыннан белсен. Өйдә баласына туган телне өйрәтә алмаган, ә халык алдында милли сәясәт турында сүз көрәштереп йөргән гаиләләр өчен миңа оят. **ӘГӘР МӘДӘНИЯТЕБЕЗНЕ, ТРАДИЦИЯЛӘРЕБЕЗНЕ САКЛАРГА ТЕЛИБЕЗ ИКӘН, ӘНИ КЕШЕ БАЛАСЫНДА ҮЗ ТЕЛЕНӘ, ҮЗ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕНӘ МӘХӘББӘТ УЯТЫРГА ТИЕШ.**

Ике сәгатькә килеп, телевидениедән чыгыш ясап, патриот булуыңны, Россияне яратуыңны, аның өчен борчылуыңны сөйләү җайлы ул. **Ә МЕНӘ РЕЗИН ИТЕКЛӘР, СЫРМА КИЕП, ТӨЗЕЛЕШ БУЕНЧА ЙӨРҮЧЕ КЕШЕЛӘР БЕЗДӘ БИК АЗ.**

Безнең Россиянең төп бәласе – максат турында онытып, күп сөйләшү. **КАЙБЕР ЧАКТА ФАЙДА ӨЧЕН, АРТЫК КҮП СОРАУ БИРМИЧӘ, КӨТЕП ТОРУЫҢ ХӘЕРЛЕ. ҮЗЕННӘН-ҮЗЕ ҖАЙГА САЛЫНЫРГА МӨМКИН.**

Беренче җитәкче булып, бары тик киңәш тыңлап кына эшлисең икән, яхшылыкка илтмәячәк. **ДӨРЕСМЕ, ДӨРЕС ТҮГЕЛМЕ – КАРАРНЫ ҮЗЕҢ КАБУЛ ИТӘРГӘ ТИЕШСЕҢ.**

ИРЕКЛЕ КЕШЕЛӘР ЮК УЛ. БАРЫБЫЗ ДА КҮПМЕДЕР КҮЛӘМДӘ ИРЕКСЕЗ. Миңа да регламентны сакларга кирәк. Дөрес, эшлекле очрашуларга кагылышлы мәсьәләдә мине беркем дә ирексезләми. Кая барасымны, кем белән очрашасымны үзем хәл итәм. Минем ирек дәрәҗәсе теләкләремә бәйле.

КЕШЕ ЯРАТКАН ЭШЕ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ ИКӘН, БУ – БИК ЯХШЫ.

Илдә аерылышулар проблемасы бар. Гаиләдә ниндидер каршылыклар чыгарга, ир белән хатынның ихтыяҗлары һәрвакыт туры килмәскә мөмкин, әмма бу аерылышырга кирәк дигән сүз түгел әле. **ШУНЫСЫ ДА МӨҺИМ – ТАГЫН ЯҢА ГАИЛӘ КОРЫП ТА, БӘХЕТ ТАБЫЛМАСКА МӨМКИН БИТ. ШУҢА КҮРӘ БУЛГАН ГАИЛӘНЕ САКЛАРГА, АҢА НЫКЛАП ТОТЫНЫРГА КИРӘК.**

Югалтуны онытып булмый. **ӘММА ТОРМЫШТА БУЛГАН ЮГАЛТУЛАР, КЫЛГАН ХАТАЛАР СИНЕ ҖИҢМӘСЕН.** Бу хакта һәрвакыт уйлап йөрергә кирәк түгел.

БАЛЫК ТОТУ – МИНЕМ ӨЧЕН ТАБИГАТЬКӘ ЧЫГУ МӨМКИНЛЕГЕ, ШӘП УРЫН БИТ УЛ! Бер балык тотмасам да, кәефем төшми, психоз юк. Улымны үзем белән алу мөмкинлеге дә әле ул. Юкса мин аны күрмим диярлек. Балык тоту аңа да ошый.

Мәктәптә «дүртле»гә укыдым. Әмма өй эшләрен эшләргә, гомумән, укырга яратмадым. **КРЕАТИВЛЫГЫМ АРКАСЫНДА ОТА ИДЕМ.**

МИННӘН НИНДИ ДӘ БУЛСА ФАЙДА БУЛСЫН ДИП ЭШЛИМ.

ӘТИ-ӘНИЛӘР НӘСЫЙХӘТ БИРМИ ТОРГАНДЫР, Ә ЯШӘҮ РӘВЕШЛӘРЕ, ҮЗ-ҮЗЛӘРЕН ТОТЫШЛАРЫ АША СИҢА НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕҢНЕ КҮРСӘТӘДЕР. НИ ГЕНӘ БУЛСА ДА, ӘТИ-ӘНИЕҢ ӘБИ-БАБАҢ НИШЛӘГӘН, ШУНЫ КАБАТЛЫЙСЫҢ. Бар нәрсә дә сүз белән әйтелми. Мәсәлән, истә калган, мин кабатлаган әйберләр бик күп: уң аяк белән тору, аяк киемен иң беренче уң аякка кию, ашаган ризыгыңны тәлинкәдә калдырмау, ашап туйганнан соң дога кылу...

ГАИЛӘ УЛ – ХАТЫН-КЫЗ. Безнең гаиләдә әни баш иде. Нинди генә башлык булсам да, минем гаиләдә дә хатыным баш. Һәм ул бар нәрсә белән идарә итә. Әгәр дә хатын-кыз, мәсәлән, бизнес белән дә шөгыльләнә икән, димәк, аңа икеләтә авыр.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА КОМПЛИМЕНТЛАР ӘЙТЕРГӘ КИРӘК. Аларга да күңелле, сиңа да рәхәт.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.

РЕДАКЦИЯДӘН: Рөстәм Нургалиевич, журналыбыз укучылары исеменнән Сезне 65 яшьлек юбилеегыз белән котлыйбыз. Сез – үзебезнеке! Татарстанны, аның халкын яратучы, традицияләребезгә, динебезгә, телебезгә хөрмәт белән караучы җитәкчебез. Республика үсеше өчен көчегезне кызганмавыгыз, җаныгызны биреп эшләвегез сокландыра. Куйган максатларыгызга ирешү өчен сәламәтлек, ныклык телибез!

БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛГА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА

«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП)
рәсми каталогы буенча



1

Татарстанлылар өчен бер елга индекс – **П8299**

ярты елга индекс – **П2204**

2

Республикадан читтә яшәүчеләр өчен индекс – **П0279**

3

РЕДАКЦИЯДӘ
Килеп алу шарты белән
ярты елга язылу бәясе – **330 сум.**
Теләсә кайсы айдан язылырга мөмкин.

Яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның
15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала.

Хәзер «Сөембикә» журналын Wildberries, Kazan Express, Ozon,
«Татмедиа» онлайн кибетеннән дә сатып алырга була.

БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru**
ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**
Фейсбукта: **www.facebook.com/syuyumbike**
Инстаграмда: **www.instagram.com/suyumbike_journal**

РЕКЛАМА 16+

АКЧА САНАГАННЫ ЯРАТА



Фәнзилә МОСТАФИНА

«Бездә менталитет шундый: бүгенге көн белән генә яшибез. Керемнәрне карамыйбыз, чыгымнарны исәпләмибез», – ди финанс белгече Ләйсән ХАЛИКОВА. Юкса гади генә кагыйдәләрне истә тоту, билгеле бер финанс гадәтләре булдыру тормышны шактый җайлаштырыр иде. Белгеч белән бергәләп шул кагыйдәләрне барладык.

Әле генә шактый чыгымлы Яңа ел бәйрәмен уздырып җибәргән идек, февральдә – Гашыйклар көне һәм Ватанны саклаучылар бәйрәме, аннары – 8 Март, араларында туган көннәр дә бар. Бәйрәм булгач, билгеле инде, якыннарны сөендерәсе килә. Шул ук вакытта «бүләккә акчаны ничек җиткерергә» дигән сорау да күңелне кимерә.

– Бәйрәм чыгымнары турында сөйләшәбез икән, иң беренче үзебезнең финансларга игътибар итәргә кирәк. Әйтик, хезмәт хакы бар, ул – даими керем. Шулай ук айлык чыгымнарыбыз бар, аларны якынча булса да чамалыйбыз. Шуннан соң калган акча (керем минус чыгым) дельта дип атала. Дельтадан, беренчедән, үзебезгә «финанс мендәре» формалаштыра, икенчедән, бүләкләргә, көтелмәгән сатып алуларга һәм киләчәк максатларга акча аерып куя алабыз. Кайберәүләр, минем хезмәт хакым түбән, ничек мин ул акчадан дельта чыгарыйм, дип әйтә. Минемчә, бу хезмәт хакы күләменнән түгел, күбрәк үзебезнең нияттән тора. Дельта нинди генә зурлыкта булмасын, акча җыярга мөмкин. Әйтик, хезмәт хакыгыз 15 мең сум, ди. Шуның 14 меңе чыгымнарга китә, дельта бер мең сум кала. Шуның 100 сумын «финанс мендәре»нә, 100 сумын бүләкләргә аерып куя аласыз. Бәйрәмнәрнең, туган көннәрнең кайчан буласы билгеле. Шуңа күрә аларның чыгымнарын алдан планлаштырсаң уңайлырак.

Бүләкләр бирешкәндә алдан сөйләшү дә чыгымнарны киметергә ярдәм итә. Мәсәлән, Яңа елда балаларга гына бүләк бирәбез, олылар, үзара бүләк бирешмибез, табынга гына җыелабыз дип килешергә мөмкин. Икенче мисал: туган көн иясеннән бүләккә нәрсә кирәген сорарга, ул теләгән әйбер кыйммәтрәк булып чыкса, берничә туган яки дус берләшеп алырга була. Шулай эшләсәң, бүләкне ошатырмы, юкмы дип борчылмыйсың да, кесәгә дә бик сукмый.

Аннан соң хәзер теләкләр исемлеге (вишлист) популярлашып бара. Кеше үзенә кирәкле әйберләр исемлеген төзи дә шуны дусларына, якыннарына тарата. Анда төрле суммага бүләкләр языла. Һәм якыннары, үз бюджетын чамалап, шуннан берәр әйберне сайлап бүләк итә. Нәтиҗәдә, ике як та канәгать кала.

Бер дә булмаса, бүләкне кредитка алу варианты бар. Хәзер банклар, микрофинанс оешмалары нинди генә тәкъдимнәр белән чыкмый!

– Чынлап та, тәкъдимнәр бик күп. Ләкин аларга кызыгырга киңәш итмәс идем. Шундый маркетинг алымы бар: башта банклар берничә айга процентсыз яисә бик түбән процентка кечкенә генә сумма биреп карый. Кеше кызыгып ала һәм әҗәтен хезмәт хакыннан каплый. Аннары банк зуррак сумма тәкъдим итә, анысы инде процент белән. Зуррак суммалар ала башлагач, хезмәт хакы ул хәтле югары булмау сәбәпле, кеше әҗәтен түли алмас хәлгә килә, шул рәвешле кредит тозагына эләгә.

Кредитны киләчәк тормыштан энергия алу дип тә әйтер идем. Чөнки бурычка алып, әле эшләмәгән акчаны тоткан булып саналасың. Ниндидер эмоцияләргә, хезмәт күрсәтүләргә кредит алсаң, алар үтеп киткәннән соң, тәме бетә, кредитны түләү теләге дә калмый. Шуңа күрә аңа мәҗбүри чыгым итеп карамыйсың. Соңга калып түләргә, бөтенләй түли алмый башларга да мөмкин. Процентлар булу сәбәпле, әҗәт суммасы арта да арта, һәм кеше әҗәт чокырына килеп эләгә.

Шулай да кичекмәстән акча кирәк, һәм кредит алудан башка чара юк икән, финанс оешмаларының процентларын чагыштырып, Үзәк Банк сайтында лицензияләрен тикшереп карарга киңәш итәм. Рәсми сайтта мәгълүматы булмаган оешма белән бәйләнешкә кермәгез. Банкта таләпләр күбрәк, акчаны да көнендә үк бирмәскә мөмкиннәр. Шуңа күрә күпләр беренче

очраган «биш минут эчендә акча бирә торган» микрофинанс оешмасыннан алуны кулайрак саный. Алар акчаны тиз бирсә дә, шартлары начаррак. Әйтик, банклар елына 10–15 процент белән кредит бирсә, МФОларның кайберләрендә көнгә бер процент булып бара, димәк, аена 30 процентлы кредит дигән сүз.

Кредит карталары да тормышыбызга ныклап үтеп керде. Аларның уңай яклары күбрәкме, тискәреме?

– Бер яктан караганда, алар бик уңайлы сыман. Күпмедер акча тотасың һәм хезмәт хакы алгач түлисең. Әмма бу – психологик тозак. Беренчедән, инде әйткәнемчә, әле эшләмәгән акчаны тотасың булып чыга. Икенчедән, әйтик, аена картадан 50 мең тоттың, ә хезмәт хакың 60 мең сум ди. Берьюлы 50 меңне әҗәт түләүгә чыгарып салу психологик яктан җиңел түгел. Аннары кредит карталарының начар ягы шунда: процентлары бик югары. Банкларның күбесе өч ай бушлай куллана торган кредит картасы бирергә ярата. Шул вакыттан соң тотылган акчаны кайтарып өлгермисең икән, процентлар дүртенче ай өчен генә түгел, үткән өч ай өчен дә тотып калына. 30 проценттан башланса да, бик зур сумма түләргә туры киләчәк дигән сүз. Ә кулланучы кредитын банклар 10–15 процент белән тәкъдим итә. Шуңа күрә тиешле вакыт эчендә әҗәтегезне кайтара алуыгызга ышанып бетмисез икән, кредит картасы урынына кулланучы кредиты сайларга киңәш итела.

Чыгымнар күбрәк булган саен, ничек күбрәк акча эшләргә, дигән уй да ешрак туа. Сорау тәкъдим тудыра дигәндәй, интернетта хәзер адым саен – өйдән чыкмый гына зур акчалар эшләү турында игъланнар, инвестиция тәкъдимнәре... Ничек мошенниклар кулына эләкмәскә?

– Төп кагыйдә – инвестиция ясарга уйлаган компанияне алдан тикшереп карарга. Бик яраткан блогерыгыз рекламаласа да, ул компания ышанычлы дигән сүз түгел әле. Икенчедән, инвестицияләр белән эшлибез дип, ниндидер компаниягә чакыралар һәм гарантияләнгән керем вәгъдә итәләр икән, шундук шик туарга тиеш. Чөнки финанс базарында беркем бернинди гарантия бирми, акция бәяләре теләсә кайсы вакытта төшәргә яисә кинәт өскә сикерергә мөмкин. Компания Россиядә теркәлгән булса, аны салым органнары һәм Үзәк Банк сайтларында тикшереп карарга кирәк. Аеруча кайчан ачылганына игътибар итегез, яңа гына ачылган булса, шулай ук шикләнергә урын бар.

Статистикага карасак, Россиядә күпләрнең «финанс мендәре» юк. Аның кирәклеген барыбыз да аңлыйбыз, ләкин хезмәт хакың зур булмаса, аның да күп өлеше ипотека каплауга, коммуналь түләүләргә, ашау-эчүгә китеп барса, ул «мендәр»не ничек тупларга соң?

– Элек әбиләрнең «кара көнгә» дип җыйган акчасы булган, бу – шул ук финанс мендәре инде. Ул хәзер дә һәр гаиләдә булырга тиеш. Аның күләме кешенең яки гаиләнең чыгымнарына карап билгеләнә. Әйтик, кеше



Фото: Анна Арахамия



берүзе генә яши һәм чыгымы аена якынча 10 мең сум, ди. Аның «финанс мендәре» кимендә өч айга җитәрлек, ягъни 30 мең сум күләмендә була. Әгәр ир, хатын һәм баладан торган гаиләне карыйбыз икән, ким дигәндә алты айны алабыз. Гаиләнең айлык чыгымын 6 га тапкырлыйбыз, шул сумма «финанс мендәре»н тәшкил итәргә тиеш. «Финанс мендәре»н бер айлык хезмәт хакыннан гына җыеп бетерергә дигән сүз түгел. 100, 200, 500 сумлап булса да аерып куеп барырга була, шуны гадәткә кертсәң, кирәкле сумма җыела. Ә инде мөмкинлек булганда керемнең 10 процентын «финанс мендәре»нә күчереп барырга киңәш ителә.

Үзебез нәрсәдәндер баш тартып та тора алабыз, ә менә бала сораса... Булмаган акчаны бар итеп сатып алабыз. Балага ул ошаткан әйбернең артык кыйммәт икәнен, әлегә аны алып булмавын ничек әйбәт итеп аңлатырга соң? Гомумән, баланы акча белән кайчан, ничек таныштыра башларга?

– Акчагызны күпмедер дәрәҗәдә янга калдырырга теләсәгез, шул ук вакытта балага да алдагы тормышында җиңелрәк булсын дисәгез, аны акча белән яшьтән үк таныштырырга тәкъдим итәм. Акчаның ничек эшләнгәнен үз телегездә аңлатырга кирәк. Хәзер заманча гаиләләр акча тотарга болай өйрәтә: әйтик, бала атна буе яхшы укый ди, атна азагында әти-әнисе ниндидер бүләкләү уйлап таба – 50 яки 100 сум акча бирә. Шундый ук бүләкләүне тәртибе яхшы булган, әнисенә булышкан өчен дә кертергә мөмкин. Беренчедән, бала тәртибенә, укуына игътибарлы була, эш белеп үсә. Икенчедән, акча эшләргә өйрәнә. Дөрес, монда чаманы югалтырга ярамый. Ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре кулланучы мөнәсәбәтенә әйләнергә тиеш түгел. Һәр эш өчен түли, акча белән манипуляция ясый башласагыз, баланың «савыт-сабаны акча түләсәгез генә юам», дип әйтә башлавы да ихтимал. Шуңа күрә мондый бүләкләү еш булмасын. Эшләп алган акчаның кадере калсын. Бу – баланың шәхси акчасы була. Аны ничек тотасын сөйләшеп куярга кирәк. Әйтик, кибеткә кергәч бала ниндидер уенчык сораса, «әйдә, синең акча янчыгыннан тотабыз» дип тәкъдим итәргә мөмкин. Шул вакытта бала уйлый: бу уенчык аңа шулхәтле кирәкме, акчасын шуңа тотарга телиме? Һәм шул рәвешле үзе карар чыгара, акча тотарга өйрәнә.

Күпчелек гаиләләрдә акча хатын-кыз кулында. Шул ук вакытта уртак бюджет булдыручылар, банкта уртак счет ачтыручылар да бар. Бу ни дәрәҗәдә актуаль?

– Уртак счетлар, чыннан да, популярлашып китте. Гаиләнең берәр әгъзасы үз исеменә счет рәсмиләштерә дә аны үзе теләгән кешеләргә, әйтик, хатыны яки иренә, 14 яше тулган балаларына ача. Аларның барысына да банк картасы бирелә һәм барысы да шунда булган акчаны тота ала. Әлеге счет юридик яктан кем исеменә ачылган – шуныкы булып санала. Кемнең нинди суммага нәрсә алганы счетка беркетелгән бөтен кешегә дә күренеп тора, шуңа карап гаилә чыгымнарын да исәпләп була. Гаиләнең берәр әгъзасы «ашарга көн саен мин генә алам, ә син миңа акча бирмисең» дигән дәгъва белдермәсен өчен, шушындый уртак бюджет булдырырга мөмкин. Ләкин аны ничек итеп тулыландырып барасын алдан килешеп кую хәерле. Ә инде гаиләдә билгеле бер финанс кануннары булдырылган, әйтик, эре сатып алулар – ир-ат җилкәсендә, ә көндәлек азык-төлекне хатын ала дип килешенгән икән, мондый уртак счет кирәк тә түгел дип уйлыйм.

Дөнья булгач, төрле хәлләр булырга мөмкин. Гаиләдә ир генә акча эшли икән, туендыручысын югалткан очракта хатын-кыз һәм балалар финанс ягыннан бөтенләй якланмаган хәлдә кала. Моны булдырмас өчен хатын-кызларга нинди киңәшләр бирерсез?

– «Финанс мендәре» юк икән, туендыручы – бу очракта ир кеше – эшен югалтса, инвалид калса яисә кинәт үлеп китсә, гаилә чынлап та авыр хәлдә калырга мөмкин. Шундый нәрсә килеп чыкмасын өчен, иминият килешүе төзү тәкъдим ителә. Дөрес, Россиядә иминиятләштерүгә бик ышанып бетмиләр, чөнки, мәсәлән, машинаң юл казасына эләксә, иминият компанияләренең тиешле акчаны тулысынча түләми торган гадәтләре бар иде. Әмма кешене иминиятләштерә торган программалар – бик яхшы эшли торган инструмент. Туендыручының гомере иминиятләштерелгән икән, аның белән нәрсә дә була калса, гаилә шул иминият акчасына берникадәр вакыт үзен ризык һәм кирәк-ярак белән тәэмин итеп тора алачак.

ФИНАНС ТЕМАСЫНА КИТАПЛАР

- Балаларга (үзегезгә дә кызыклы булыр): «Пёс по имени Мани», Бодо Шефер;
- Үсмерләргә: «Юный инвестор», Кэтрин Бейтман;
- Үзегезгә: «Самый богатый человек в Вавилоне», Джордж Клейсон.

ФАЙДАЛЫ ФИНАНС ГАДӘТЛӘРЕ

- Кибеткә кирәкле әйберләр исемлеген төзеп һәм якынча бәяләрен алдан карап барырга киңәш ителә. Аның өчен хәзер смартфоннарга урнаштырыла торган «Едадил», «Biglion» «Tiendeo» кебек уңайлы кушымталар бар.
- Инстаграмда барлык кибетләрдә булган акция, ташламаларны күрсәтеп баручы аерым блогерлар күп. Аларның киңәшләре техника, кием-салым яисә азык-төлек алганда ярдәм итәргә мөмкин.
- Кирәкмәгән әйбердән арыну, шул ук вакытта акча да эшләү өчен, кулланылмый торган кием-салым яисә башка нәрсәләрне бушлай игъланнар сайтлары аша сатарга мөмкин. Шул ук вакытта үзегез дә кирәкле әйберне шундый онлайн-мәйданчыкларда эзләп карый аласыз.



Белгеч фикере

Айсылу НӘГЫЙМОВА,
социология фәннәре докторы, профессор, психолог

АКЧАНЫҢ КАДЕРЕ БЕТКӘЧ БЕЛЕНЕР

Акчаны табу читен, тапкач саклау, тоту – аннан да читен, диләр. Гаиләдә, гомумән, тормышта акча тота белү-белмәү зур роль уйный, кайбер очракта хәтта аңлашылмаучылык, зур проблемалар килеп чыгуга сәбәп булып та тора. Хатын-кызлар арасында аз гына акчаны да бәрәкәтле итеп тота белүчеләр бар. Шул ук вакытта иренең ай буе эшләп тапкан акчасын, кирәклеге дә шикле булган юк-барга туздырып бетерүчеләр дә җитәрлек. Нигә шулай килеп чыга соң? Сәбәпләренә тукталыйк.

Бөек психолог Зигмунд Фрейд әйткәнчә, еш кына мәсьәләнең тамыры монда да кешенең балачагына барып тоташа. Баланың гаиләдә, әти-әнисеннән алган тәрбиясе, үз-үзен тоту үрнәкләре аның мөстәкыйль тормышында да чагылыш таба. Әгәр ул кечкенәдән акча тотуга тотнаксыз мөнәсәбәт күреп үссә, үзе дә шуңа охшаган модель сайлаячак. Яки, киресенчә, моның капма-каршысы булган очракта – һәр тиенне санап, иң кирәк нәрсәләрдән дә баш тартып яшәүче гаиләдә гаять аскет табигатьле балалар үсәргә мөмкин.

Гаилә тәрбиясе дигәннән, кайчак матди яктан бик кысмырык яшәгән әти-әни дә, балаларга берни дә кызганмый: соңгы акчасына булса да, ул сораган кыйммәтле уенчыкны да, кием-салымны да алып бирә. Өстәвенә, балага бу бүләкләрнең әһәмияте, кыйммәте дә аңлатылмый. Акчаның каян килгәне хакында уйларга өйрәнмәгән бала, үсә төшкәч тагын да кыйммәтлерәк бүләкләр сорый, ата-ананың мөмкинлеге булмаса, тавыш чыгарып, барыбер үз дигәненә ирешә. Мондый тәрбия алган кызлар кияүгә чыккач та акча тотуга карата шундый ук мөнәсәбәт күрсәтә: аны искиткеч бер җиңеллек белән туздыра – сарыф итә.

Акчага карата мөнәсәбәтнең, әйткәнемчә, икенче, капма-каршы ягы – чамасыз саранлык яки чиктән тыш акча җыю белән мавыгу. Монысы да үзенә күрә бер чир сыман: ул кеше тормышының ямен җибәрә, кайчандыр ирешәчәк эфемер максатлар (зур йорт, кыйммәтле автомобиль, сәяхәтләр һәм башкалар) хисабына бүгенге матур җитеш тормыш корбан ителә – яшәүнен тәме югала.

Әйе, «Акчаны табарга өйрәнгәнче, тотарга өйрән», дип юкка әйтмиләр. Галимнәрнең тикшеренүләре күрсәткәнчә, күпчелек кеше акчага гаять рациональ карый, шулай да бүгенге реклама, агрессив сәүдә чаралары бу мәсьәләгә карата бик нык булганнарны да күпләп акча туздырырга этәрергә сәләтле. Акча сарыф итүдә чама хисен – рациональ мөнәсәбәтне ничек тәрбияләргә соң? Гомумән, акчаны дөрес куллану мөмкинме?

Күреп торабыз, бүгенге сәүдә системасы кеше психологиясенең үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән агрессив реклама аша оештырыла. Шунлыктан берничә бик гади кагыйдәне истә тотарга кирәк: ашыйсы килгән чакта азык-төлек кибетенә керергә тырышмагыз – кирәген дә, кирәкмәгәнен дә күпләп алачаксыз. Начар кәефне шопинг белән «төзәтү» дә дөрес түгел: кәеф күтәрелсен өчен генә артык кирәге дә булмаган әйберләр алу ихтималы арта. Начар кәефне спорт белән шөгыльләнеп, физик активлык күрсәтеп тә күтәрергә мөмкин бит. Дуслар, туганнар белән очрашу, концерт-театрларга бару шулай ук уңай тәэсир ясый. Иң мөһиме: реклама чараларының йогынтысына бирелмәгез, эмоцияләр аркасында кирәкмәгән товар алудан сакланыгыз.

Кечкенә вакытыннан ук балада акчага карата дөрес мөнәсәбәт формалаштыру мөһим. Моның өчен кайбер күнекмәләрне гадәткә кертергә кирәк. Әйтик, кулына биргән бар акчаны тиз арада тәм-томга сарыф итеп бетерү ярамаганын, кесә акчасының бер өлешен туплап, үзе өчен кирәк һәм кыйммәтрәк булган әйберне алуга да тотарга мөмкин икәнен аңлатып тору. Шулай ук баланың кечкенәдән даими рәвештә кибеткә ипи-сөт алып кайтырга йөрүе дә кайбер күнекмәләр формалаштыра: акчага карата җаваплы мөнәсәбәт тәрбияли, акчаның кыйммәтен аңларга булыша.

«Акчаның кадере беткәч беленер», ди халык мәкале. Тик ул чакта соң булуы бар...



Зилә ВӘЛИЕВА,
Татарстан Республикасының
Иҗтимагый палата рәисе,
«Татарстан хатын-кызлары»
иҗтимагый оешмасы җитәкчесе







Бүген бәйгеләр яңалык түгел – көн саен берәрсе белән очрашабыз. Гомумән, иҗтимагый тормышыбыз төрле бәйгеләрдән, рейтинглардан тора. Әмма «Ел хатын кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» Республика бәйгесенең башкалардан аерылып торган үзенчәлекләре бар. Беренчедән, ул инде менә берничә дистә ел дәвам итә. Аны шулай озак яшәтүчеләр – республикабызның иң булдыклы, иң эшлекле, иң чибәр хатын-кызлары. Аларны бу конкурска җирлектәге хатын-кыз оешмалары, якташлары, хезмәттәшләре тәкъдим итә. Үтә дә җаваплы сайлау дияр идем мин аны. Чөнки аның аркылы замана хатын-кызы образы туа, җәмгыятьнең бүгенге көн хатын-кызларына карата таләпләре чагыла. Заманча таләпләр! Ләкин тирәнгәрәк кереп карасак, сайлап алуның нигезендә һәрвакыттагыча хатын-кызның борынгыдан килгән асылына мөрәҗәгать итү ята. Безнең героиняларыбыз, бер яктан, үзләренең эшлекле, булдыклы, талантлы, белемле, тәвәккәл булулары белән зур эшләр башкаралар. Икенче яктан, алар барыбер гаилә тоткасы булып, аны ныгытучы, балаларны тәрбияләүче, иренә ышанычлы терәк, таяныч булып калалар.

Ел саен бәйгедә катнашучылар белән очрашабыз да, чын күңелдән дулкынланып, гаҗәпләнеп, алар белән сокланып ел дәвамына җитәрлек тәэсирләр җыябыз. Һәр бәйге саен яңадан-яңа шәхесләр ачабыз. Бу дөньяны армый-талмый алга өндәүче, нинди генә ыгы-зыгы чыкса да, барыбер тормышны яратучы, балаларын сөеп, гаиләсен карап, күркәм эшләре белән дөньяны ямьләп яшәүче хатын-кызлар бар алар! Бөтен республикага үрнәк булырдай затлар! Быелгы бәйгедән дә шундый шәхесләр, шундый тәэсирләр көтәм: катнашучыларыбыз һәркемне сокландырыр, күңелдә матурлыкка, зирәклеккә, затлылыкка ышаныч хисләре туар дип өметләнәм.





































Сәрия САБУРСКАЯ,
Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

«Ел хатын кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесе традиция буенча ел саен 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне алдыннан уздырыла.
Ул тормышның төрле өлкәләрендә: гаиләдә, бизнеста, фәндә, мәдәнияттә, сәламәтлек саклауда, җитештерүдә, дәүләт идарәсендә, шулай ук төрле гражданлык инициативаларында эшлекле сыйфатларын һәм иҗади потенциалларын камилләштерүче заман хатын-кызы һәм ир-атның позитив образын булдыруга юнәлтелгән. Менә инде 20 елдан артык әлеге бәйге катнашучылар өчен шәхси һәм профессиональ яктан үсү өчен нәтиҗәле старт мәйданы булып тора.

Шул ук вакытта ул чын гаилә бәйрәменә дә әйләнде. Бәйге бөтен гаиләне берләштерә бит: әниләре, әбиләре, хатыннары өчен бөтен туганнары, дуслары, хезмәттәшләре борчылып җан ата. Катнашучыларның бәйге барышында сәхнәдә күрсәткән осталыклары ихлас хөрмәт һәм соклану уята.

«Ел хатын кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә катнашучы хатын-кызларның гына түгел, аларның гаилә әгъзаларының, балаларының, оныкларының, якыннарының активлыгын да арттыра, яңа буын актив җәмәгать эшлеклеләре, җитештерү алдынгылары һәм талантлы әти-әниләрне тәрбияли.

Катнашучылар саны елдан-ел арта. Минемчә, бу бәйге беркайчан да үз потенциалын, мөмкинлекләрен сарыф итеп бетермәячәк. Тормышның асылын тәшкил иткән һәрнәрсәне – гаилә учагын, кадерле һәм якын кешеләрне, эшеңне, җәмгыятьне яратуга юнәлтелгән ул. Бу – аның төп мәгънәсе. Ә ярату – яшәү дәртенең саекмас чишмәсе ул.



Эльмира ЗАРИПОВА,
Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры

Яңа коронавирус йогышы пандемиясе балалары булган гаиләләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән социаль сәясәтнең дөреслегенә тагын бер кат инандырды. Дәүләт тарафыннан моңарчы күрелмәгән социаль ярдәм чаралары кертелү меңләгән кешеләр өчен бәяләп бетергесез кайгырту булды. Ул республикада демографик тенденцияләрне үстерүгә дә йогынты ясады. Әйтик, ун ел эчендә Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләр саны 66 процентка артты.
Гражданнар белән адреслы эшләү, кирәкле барлык түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашыру, балалы гаиләләргә булышу турында тулы мәгълүмат бирү – болар барысы да социаль тармак хезмәткәрләренең фидакарь хезмәтеннән башка мөмкин булмас иде. Татарстан Республикасының социаль тармагы 9,6 мең хезмәткәрне берләштерә. Социаль эш формалары елдан-ел камилләштерелә, хезмәт күрсәтү даирәсе киңәя, аларның сыйфаты һәм файдалану мөмкинлеге арта. Әмма бернинди яңарышлар да безнең төп үзенчәлекне – социаль хезмәткәрләрнең рухи сыйфатларын алыштыра алмый. Социаль хезмәткәрләр – иң кешелекле һәм игелекле һөнәр ияләре алар. Ул түземлек, үз-үзеңне һәрвакыт дөрес, ипле тотуны, башка кешеләрнең проблемаларын дөрес хәл итүне сорый. Безнең тармакта эшләүчеләрнең күбесе – хатын-кызлар. Үзләре дә – әни кеше, ир хатыны, күп балалы гаиләләрдә балалар үстерүчеләр. Катлаулы Covid-19 шартлары алар өчен гаять зур сынау булды! Нәфис ханымнар, гүя фәрештәләр, ярдәмгә мохтаҗларны якларга ашыкты. Эшләренә тугрылык, кешеләргә җылы мөнәсәбәт күрсәткәннәре өчен ихлас рәхмәт белдерәсем килә аларга!



Елена КУЗЬМИЧЕВА,
Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе рәисе

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз!
Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе һәм шәхсән үз исемемнән Сезне яз бәйрәме – 8 Март белән тәбрик итәм! Хатын-кыз йөрәге – мәхәббәт, яхшылык, наз чыганагы ул: алардан башка безнең дөньябыз тотрыклы була алмый.
Бүген хатын-кызлар нинди генә рольләр башкармый: алар әни дә, хатын да, гаилә учагын саклаучы да, үз һөнәрләрендә югары классы белгеч тә, эшмәкәр дә, җәмәгать эшлеклесе дә... Кайсы өлкәдә хезмәт куйсалар да – һәммәсендә гүзәл һәм кабатланмас булып кала беләләр.
Бүгенге заман хатын-кызында югары профессиональлек, эшлеклелек сыйфатлары күңел матурлыгы, наз һәм якыннары турында кайгырту белән ярашкан. Аларның зирәклеге, җаваплылыгы эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә уңышка ирешергә мөмкинлек бирә.
Бу матур якты көндә Сезгә чын күңелдән бәхет, сәламәтлек һәм куанычлар телим! Якыннарыгызның мәхәббәте һәм игътибары күңелегезне гел җылытып торсын!

Үзен күреп сөйләшкәнче үк, аны тасвирлаган сүзләрне гаҗәпләнү катыш соклану аша күңелдән үткәрдем. Һәркайсы кызыклы язма исеме сыман ымсындырып тора.
«Үз фатирыннан кафе ясаган бизнес-леди...»
«Тәтештә аны принцесса Диана дип йөртәләр...»
«Шәһәргә килгән туристлар аның кафесын сайлый...»
«Ул – товар һәм акча мөнәсәбәтләреннән бигрәк, җан җылысы белән алдыра...»
Барысы да Рәмзия Рәфыйкова турында. «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең Буада узган зона турында ул хатын-кыз – бизнес-леди булып ачылды. Тәвәккәл, тырыш, эшлекле, яңача карашлы, зәвыклы... Аның турындагы видеоны караганда Тәтешне барып күрәсе, Рәмзия Әхмәт кызының үзе белән очрашасы, аның атаклы кафеларында утырасы килә башлады. Әйтерсең, без дә теплоходтан төшүче туристлар. Иделнең биек ярыннан борынгы шәһәргә алып менүче текә агач баскычның басмаларын саный-саный югарыга күтәрелләбез. Монда шундый гыйбарә бар: күпме генә кеше басмаларны санамасын, һәркайсы исәпне югалта, саташып-буталып бетә икән. Кайчандыр бирегә язучы Илья Ильф та килгән булган һәм болай язып калдырган: «Тәтеш. 640 басмадан торган баскыч. Яшел һәм ал ярлар...» Ләкин язучы шактый ялгышкан диләр. Кемнәрдер – 250 ди, кемнәрдер 340 ны санаган... Сәүдәгәрләр һәм балыкчылар шәһәре ике катлы йортлары, кабатланмас архитектура һәйкәлләре, җирле меценатларның утарлары, гаҗәеп Балык музее белән каршылар.... Ярар, монысы хыялда гына. Ә без февраль бураннары белән узыша-узыша, барыбер Тәтешкә юл алырбыз. Кар көртләрен ера-ера, тизрәк Рәмзиянең кафеларына ашыгырбыз. Башымда кырыкмаса кырык сорау бөтерелә. Рәмзия Рәфыйкова бу юлга ничек тәвәккәлләп кереп киткән? Эшмәкәрлек таланты каян килә аңа? Булышчылары кемнәр? Кыенлыкларны ничек җиңә? Характерындагы кайсы сыйфатлары аны чып-чын бизнес-леди итә?..



Эльмира
ЗАКИРОВА

ТӘТЕШ ПРИНЦЕССАСЫ

Бухгалтер да, дизайнер да

...Спорт киеменнән булган сөйкемле ханым җитез генә машинасыннан чыкты да, тездән карга чума-чума, юлны ача башлады. Шундук танып алдык инде: Рәмзия! «Менә шулай кар көрәүче дә, урам себерүче дә була алам, – дип көлә ул. – Аш-су әзерләүче дә, товар табучы да, машина йөртүче дә, бухгалтер һәм дизайнер да – үзем...» Юк, мактанып та, зарланып та әйтми ул. Тавышында шаянлык ноталары яңгырый. Шалт итеп уйлый да шундук эшләп тә ата торганнардан. Үзе яшәгән шәһәргә һәм аның кешеләренә битараф булмаган Рәмзия Әхмәт кызы кайчандыр тәвәккәлләп зур эшкә алынган. Искиткеч зәвык белән яратып төзелгән кафелары әллә каян үзенә тартып тора хәзер. Үзенә бер аурасы булган «Абажур»ы да, ясмин гөле исеме белән йөртелгәне дә, фирүзә төсендәге диварлары, аңа төстәш пәрдәләре белән балкып каршылаучы банкет залы да. Җәйге чорда теплоходлар, метеорлар күп туктый икән пристаньга. Шәһәрдә биш-алты кафе булса да, туристлар ни өчендер гел Рәмзия кафеларын сайлый. Кайсы кафега керергә икәнен хәтта алар да инде белеп бетергән. Көндәшлек каты булуга да карамастан, алар бөтен районда популяр урынга әйләнгән: югары сыйфат билгесе белән бәяләп, шәһәр кунакларына тәкъдим итә башлаганнар. Һәркемне ягымлы йөз белән каршылап, бирегә килүчеләрнең хәленә кереп, ышаныч һәм абруй казанганнар шулай. Бәяләре дә түзәрлек. Килгән кешеләр иртән дә, көндез дә бирегә ашарга йөри икән. «Туристлар, гадәттә, балык ризыкларын сорыйлар. Барысының да нәкъ менә безнең Идел балыгын авыз итәсе килә. Кырпы, җәен, судак булсын менюда, – ди Рәмзия. – Тәтештә булмаган кешенең чын балык күргәне юк, диләр бездә». Һәм ул балыкка бәйле кызык бер вакыйганы да сөйләп китә. Моннан йөз еллар элек 960 килолы кырпы балыгын тоткан берәү. Аны ачтан интегүчеләргә гуманитар ярдәм итеп Казанга җибәргәннәр. 196 кг кара уылдык тәтешлеләргә тәтегән. Шул балыкны тоткан абзый өенә бер чиләк кара уылдык алып кайткан! Кырпы балыгы бер гасыр яши ди!

...Китаплар, картиналар, вазалар, карандаш-ручкалар... Рәмзия Әхмәт кызының эш кабинетына кергәндә шундый фотообойлы дивар озата. Бу – хуҗасының эчке дөньясына, аның рухи халәтенә барып тоташа кебек. Хәтта киеме дә – инде башка. Эшлекле, зәвыклы, җитди. Бу кыяфәттә, мондый чәчләр, бу стиль белән ул принцесса Диананы хәтерләтә. Аның кебек ягымлы, кешелекле. Аның кебек хәйриячелек белән шөгыльләнә... Спорт ярышлары, Өлкәннәр көннәре, балалар йортлары... Барысын да колачларга, һәммәсенә булышырга ашыга Рәмзия.

«SOS Балалар авылы»нда тәрбияләнүче күпме әти-әнисез балаларны сөендергән инде ул! Җидешәр-сигезәр баланы тәрбиягә алган гаиләгә күпме бүләкләр җибәргән! «Могҗизалар тудыручы тылсымчы сез!» – дип, хәйрия



Башлап җибәргәндә авыр булды, әлбәттә. Якыннарым булышмаса, булдырып чыга алуым икеле иде.

проектлары координаторы Елена Богомазова Рәхмәт хаты юллаган Рәмзия Әхмәт кызына. (Соңыннан белдем: Тәтештә дә, яратып, «принцесса Диана» дип әйтәләр икән аның турында!) Эшләре белән район бюджетын тулыландыруга да үз өлешен кертә, яңа эш урыннары булдыру, халыкка хезмәт күрсәтү кебек бик күп актуаль проблемаларны да чишәргә булыша.

Рәмзия Рәфыйкова сөйләгәннәрдән сорауларыма җавап таба барам.

– Эшмәкәрлеккә кереп китүем эчке халәтемнән килеп чыккандыр. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, 13 ел педучилищеда бухгалтер булып эшләдем башта. Иртән сигезгә киләм, кич биштә кайтып китәм; хезмәт хакларын исәплим, студентларга стипендияләр саныйм. Гел бертөрлелек... Холкыма бөтенләй туры килми бу эш! Холкым буенча авантюрага бара торган кеше бит мин! Танышларым сәүдә вәкиле булып эшләргә тәкъдим итте. Атнага берике көн заказлар җыям да, аннары мин иреклe. Эшем ошый. Төрле районнар буйлап йөрим: Чүпрәле, Буа, Апас, Кайбыч...

– Ә үз фатирыгызны кафе итү каян башыгызга килде?

– Күрәм, эшем буенча барып чыккан һәр районда уңайлы кафелар бар. Ә безнең Тәтештә менә андыйлар юк иде. Берчак Буадан кунаклар килеп төште, коллегаларым. «Әйдәгез, берәр җирдә кофе эчеп чыгыйк», – диләр. Үзебездәге бердәнбер кафега алып киттем... Һәм ник кердек дигән көнгә калдым! Андагы шыксызлык, шапшаклык!.. Оятымнан җир тишегенә кереп китәр хәлдә идем! Һәм бу минем сабырлыкның соңгы тамчысы булды! «Болай булмый, нидер эшләргә кирәк!» – дип, каттый карарга килдем шунда. Шәһәребездә әйбәт кафе ачасым килде. Кафены ачаргамы, юкмы дигән сорау туу белән, сораштырып йөрдем әле башта. Район кулланучылар җәмгыяте кафелары бар бит. Үзем ачам димим, сак кына сораштырам. «Ой, юк! Башка бер бәла генә! Шундый эш буламы! Бернәрсә барып чыкмый», – диләр. Хәзер менә барысын бер бизмәнгә салып карыйм да... Минем бит үз бизнес-планым бар иде. Якынча һәрнәрсәне күзалладым, санап, исәпләп карадым. Куркыныч төш кебек иде башта. Хәзер интернеттан да шактый нәрсәгә өйрәндем инде. Аналитиклар: «Тотынырга да эшли башларга кирәк! Һичьюгы, башлап җибәрергә. Ялгыш та, минем барып чыкмый, диярга ярамый!» – диләр. Грандиоз планнар туды башымда. Ә кесәдә 300 сум акча...

Өйдә ире Фәнис белән утырып сөйләшә дә, тәвәккәлләргә була Рәмзия. Үз эшен ачарга ниятен белгәч, район хакимиятендә хуплап алалар һәм... искереп беткән бер бина тәкъдим итәләр. Шәрә стеналардан гайре бернәрсә булмый анда. Ни тәрәзәләре, ни ишекләре... Түбәсе тишек. Нишләргә? Артка юл юк. Һәм очы-кырые күренмәгән эшләр башлана. Кирәкле документларны тутырулар, килешүләрнең

Ял иттерә, тынычландыра торган романтик кафе булырга тиеш дигән уй бөтен барлыгымны биләп алды.



Хезмәттәше Ольга – Рәмзия Әхмәт кызының яшьтәше дә. Бер-берсен 4 яшьтән – балалар бакчасына йөргән чаклардан ук беләләр.

бөтен баскычларын үтүләр... Мәскәүдә бизнес белән шөгыльләнүче абыйсыннан бурычка акча алып кайта Рәмзия. Ләкин күпмедер сумма барыбер җитми. Кредит коткара. Шулай итеп, иске бинаны аукционда сатып алалар ниһаять. Ләкин ул шактый чыгымнар да сорый икән.

– Педучилищеда эшләгәндә иске генә бер фатир биргәннәр иде, тоттык та шунда кафе ясарга булдык, – ди Рәмзия. – Башта кечерәк бер кафе ачабыз, аннан акча кереп торачак, безнең бар да барып чыгачак дип уйладым. Кая ул?! Бигрәк беркатлы булганмын инде! Ярый әле 24 процент белән кредит бирделәр. Хәзер мин 8 процент белән дә алырга куркам. Бер кредит алабыз, икенчесен... Бурычларны шуның белән каплыйбыз. Хезмәт хакы түләргә кирәк, салым, кредит түләргә... Мин бик җаваплы, түләүләрне бер генә көнгә дә соңарта торган кеше түгел. Төн йокылары йокламый эшләдек инде анысы. Барысын да үз кулларыбыз белән бит!

Бәхет тынлыкны ярата

– Эш барышында иң кыены нәрсә иде, Рәмзия?

– Иң кыены... бик озак эшләдек без. Бу бизнеска кереп киткәнче кем белән дә булса киңәшләшәсе калган. Шундый ук кафелары булган танышлардан сорарга була иде бит. Ләкин мин никтер кыенсындым. Бөтенесен үземә уйлап табарга, үземә оештырырга туры килде. Башта беркемгә дә сөйләмәдек, беркем берни белмәде. Кем нәрсә эшләмәс – фатир үземнеке бит. Бәхет тынлыкны ярата, диләр. Эш ахырына якынлашкач, район хакимиятенә бардым. Яши торган торакны яшәми торганга үзгәртергә рөхсәт алдым. Безгә район җитәкчеләре бик булышты, рәхмәт аларга. Ачылган көнне халыкны күрсәгез! Урамнан ук чират! Официантлар заказларны чак үтәп өлгерә...

Бераздан инде күрше фатирны да сатып алып киңәяләр, һәм шулай итеп банкет залын да ачалар. Ярым җимерек иске бина 14 елдан соң Рәфыйковлар хыялланган урынга әйләнә. Җиһазлар эзләп кайларга гына бармыйлар! Казан, Ульяновск, Рязань... Мебельләрне әнә Кировтан алып кайталар. Банкет залы ачылу ул чакта Рәмзия өчен иң бәхетле көн булгандыр. Бар да ошата! Тикмәгә генә алынмаганмын икән бу эшкә дип шатлана яшь эшмәкәр. Ләкин ничекләр эшләгәннәрен күрсәләр икән! Кулдан эш төшкән, кәеф киткән чаклар да була. Тәүлек буе эшләү, кадрлар проблемасы, рискка бару, зур җаваплылык... Ләкин тугарылырга ярамый. Тиз генә үзеңне кулга аласың һәм тагын алга барасың. Шулай эшлиләр дә. Хәзер әнә еракган килүче кунаклар өчен банкет залының икенче катында кечкенә кунакханә төзеп яталар.

...Ирешелгәннәр белән туктап кала торганнардан түгел ул. Шәһәрне иске – ярым җимерек бинадан да коткара, тирәюнен чәчәкләргә дә күмә. Кечкенә чагыннан ук нәрсәләрдер уйлап чыгарырга, рәсемнәр ясарга яраткан, курчакларына әллә нинди модалы күлмәкләр кидереп уйнаган кыз бит ул. «Минем өемдә бөтен нәрсә матур булырга тиеш: тәрәзә пәрдәләре дә, келәмнәр дә, җиһазлар да», – дип хыяллана ул. Чып-чын хатын-кыз теләге. Һәр хатын-кыз әнә шулай камиллеккә омтыладыр. Ә Рәмзиягә бар дөньяны ямьгә төрү вәкаләте күкләрдән ирешкәндер, мөгаен. Әнә шулай илһамланган эшмәкәр ханым тагын барысын шаккаттыра. Башка кафеларга охшамаган, үзенә бер атмосферасы, стандарт булмаган менюлары белән җәлеп иткән «Абажур» кафесын ача. Банкетлар уздырырга ярамаган пандемия чорында концепцияне үзгәртергә туры килә, әлбәттә. Шәһәрдә бит болай да кичләрен беркая барып булмый. Нишләргә? Төрле вариантларны күңеленнән үткәрә Рәмзия. Башта пиццерия ачарга ниятли. Бер тапкыр гына кулланыла торган савыт-сабалар алуны күздә тота. Бәлки, бургер яхшырак булыр дип тә уйлый. Ләкин Рәфыйкова максималист бит! Булган-булган, савытлары да, мебеле дә затлы булсын аңа!

– О-ой! «Абажур»ны бик оза-а-ак тудырдым мин! Ирем улым белән бөтенесен үз куллары белән эшләде инде. Алтын куллы алар минем! Диваннарны үзләре ясап, тышладылар. Су торбалары өстәлләр ясауга ярап куйды. Арзан да, үзенчәлекле дә килеп чыкты. Бизәү өлеше – минеке. Обойлар, шторалар, төсләр... Мебель эзләп, тирә-як шәһәрләрне айкау, хәтта көненә икешәр барып кайтулар дисеңме!.. Әллә нинди сихри бер урын булырга тиеш итеп күрдем мин аны! Обойлар да шул мохиткә туры килсен, өстәл-диваннар да... Абажурлар үзенә бер затлылык өстәсен. Дус кызларым булышты. Берсе – залда ремонт ясый, икенчесе – штораларны алыштыра, мин обойлардан башладым. Һәм бөтенесен шул фонга көйләдем, – ди ул.

Залга шәфәкъ төсе иңгән абажурлар аны тагын да көчәйтә. Хәтта купшы кызгылт чалмабашлар да эңгер-меңгернең шул илаһи серлелеген баета кебек.

Гаилә – таянычым

Көн ахырында инде без чит илдәге бер кафега килеп эләккәндәй булдык. Интерьер, шәп сервис, уңай энергетикалы үзенә бер колорит... Әйтерсең, Праганың бер кафесында утырабыз... Ә Рәмзия сөйли: «Чит илләргә баргач, кафеларын төрле яклап өйрәнәм, – ди. – Ничек хезмәт күрсәтәләр?

Дизайн нинди? Өстәлне ничек бизиләр? Болар барысы да кызык минем өчен. Беренче тапкыр Чехиягә бардык. Прага тәмам әсир итте, аның ниндидер төс-халәтләре монда да ияреп кайтты бугай... Төркия, Кипрлардан да үземә бер дөнья ачып кайттым... Пространство шундый булырга тиеш: кешенең гел киләсе килеп торсын». Банкет залының диварлары ук безне Италиягә алып киткән иде инде. Хәзер инде ул каршыбызда эшлекле ханымнан ихлас, өйдәгечә җайлы Рәмзиягә әйләнеп, җанына якын кешеләр, үз дөньясы турында сөйләп утыра. Әти-әнисе Апас районы Кече Болгаер авылыныкылар икән. Рәмзиягә 4 яшь булганда, гаиләләре Тәтешкә күчеп киткән. Ә тамырлар, нәсел барыбер үзенекен иткән. Әтисенең әтисе Миңнулла бабай Гарипов авылның дәрәҗәле мулласы булган. Булдыклылыгы белән тирә-якта дан тоткан. Мич тә чыгарган, итек тә баскан, авыл халкын яшелчә үстерергә дә өйрәткән. Аның алма бакчасы турында һаман шаккатып сөйлиләр икән. Ә ул салган йорт искиткеч матур, подвалларына кадәр кишттәләр тезеп төзелгән, ди. Тырыш булганнары, үз көчләре белән барысына ирешә алганнары өчен аларның нәселен авылда «ак байлар» дип йөрткәннәр. Ул асыл сыйфатлар менә кайдан килә икән Рәмзиягә! Әтисе Әхмәт абыйны исә һаман сагынып, яратып искә ала икән авылдашлары. Умартачы да, бакчачы да, аучы да, балыкчы да, механизатор да, эретеп ябыштыручы да, машинада да җилдерә, бөтен техниканың серен дә белә. Менә шундый мировой Әхмәт абый кызы инде Рәмзия. Кызганыч, балаларының уңышларын гына күрә алмаган – иртә киткән бу дөньядан Әхмәт абый. Рәмзияләре – эшмәкәр, Рәмисләре – районның баш ветеринары, Резедалары район мәгариф бүлеге методисты. Әнисе Мәрьям апа кызының иң зур ярдәмчесе бүген. «Мин больничныйда утыруларны, балалар өйдә үзләре генә дип, тизрәк өйгә ашыгуларны белмәдем дә. Кош-корт, мал-туар асрап яшәдек. Ирем эштә чакта чалгы алам да үзем печән чабып кайтам. Бу – ирләр эше, монысы – хатын-кызныкы дип утырсам, бер эш тә барып чыкмас иде», – ди Рәмзия. Ире турында аерым бер җылылык белән сөйли.



– Фәнис һәрвакыт булыша, аңлый мине. Берәү булса, фантазия дәрәҗәсендәге хыялларыма канат куя белмәс иде. Акылдан яздыңмы әллә, дип кенә җибәрер иде. Юк, ул андый түгел. Фәнис – чын мәгънәсендә ышанычлы терәк ул.

Фәнис белән Рәмзия техникумда бергә укыйлар. Егет беренче күрүдән үк гашыйк була чая кызга. Иптәш кызлары: «Фәнискә кияүгә чыгачаксың», дисәләр, «Шаяртмагыз әле», – дип көлгән генә булыр иде ул чакта Рәмзия... Техникумны кызыл дипломга тәмамлаган Фәнис авыл хуҗалыгы академиясендә дә үзен гел яхшы яктан гына күрсәтә. Ә бер елны группадашлар очрашуында Рәмзия ышанычлы, булдыклы бу шәп егеттә үзенең язмышын, киләчәген күрә. Фәниснең әти-әниләре дә чыгышлары белән шушы яктан – Тарханнан икән. Авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлагач, ул Тәтеш авыл хуҗалыгы идарәсендә эшли. Аннары Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына эшкә чакыралар. Рәфыйковлар Тәтеш белән Казанны бер итеп яши шулай. Уллары Равилгә – 24 яшь, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң ул кафеда эшли башлый, әнисенең уң кулы. Кызлары Гүзәлгә – 20 яшь. Ул да техникумда укыганда ук, 16 яше дә тулмаган килеш, кичләрен, ял көннәрендә әнисенә булышырга кафега ашыга. Бүгенге көндә Казанда үзенең матурлык салонын ачкан.

Рәмзия Рәфыйкованың бизнес-планында – якынча чыгымнар, нәрсә көтә, нинди табыш булачак, кайсы вакытка планлаштырыла – барысы да язылган. Бүген кадак сатып алалар, иртәгә – гипс, аннан соң – төрле тимер ише әйберләр... Штукатурлый да, плитка, обой да ябыштыра белә. Ләкин монда эш белү генә җитми әле. Хыялың булу да кирәктер. Зәвык та кирәк, рәссам күзләре белән карый белү дә. Психолог була белү дә... Рәмзия Әхмәт кызы фикерләре, киңәш-кагыйдә булып, блокнотка, күңелгә күчә бара.

«Кыенлыклар – эшмәкәрлекнең аерылгысыз юлдашы. Катлаулы ситуацияләрдән үзеңә сабак та аласың. Баштарак кадрлар алышынып тору белән очраштым. Хәзер инде янәшәмдә дистә елга якын бергә эшләгән кешеләр, мин аларга ышанам».

«Куркып тормаска, яхшы мәгънәсендә авантюрист булырга, дөрес чишелешләр таба белергә кирәк. Мондый эшкә алынганда тәвәккәллек, кайчак алны-артны артык уйлап тормау да ярап куя! Казанга йә Мәскәүгә үзем рульдә барам. Ә берчак кечкенә балаларыбызны утыртып, иптәш хатын белән Туапсега ук чыгып киттем машинамда. Фәнис каршы иде, аны да җайладым. Менә шундый инде мин».

«Эшеңне сыйфатлы итеп башкару шулай ук мөһим. Башлаганны ахырынача җиткерү һәм ахыргы нәтиҗәнең әйбәт килеп чыгасына ышану – менә нәрсә кирәк!»

«Һәр эшмәкәрнең булышчылары, таяныр кешеләре булырга тиеш. Минем гаиләм – минем тылым, таянычым. Беләсезме, гаиләң сине аңласа, һәрчак булышып торса, зур бәхет икән ул!»

Үзенең һәм башкаларның тормышы өчен җаваплылык алырга әзер, үз бизнесын көйләр өчен рәхәт, тыныч яшәүдән ваз кичеп, шушы юлны сайлаган тынгысыз, башкаларның хезмәтен бәяли белгән Рәмзия Рәфыйкованың бәхет сере, мөгаен, шундадыр.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



«Ата-анаң кайда булса, туган җирең – шунда», – ди Питрәч районы «Ак Барс» кошчылык комплексы» ААҖнең итне эшкәртү һәм үлчәп төрү цехы җитәкчесе Светлана ПЯТИБРАТОВА.
Тува шәһәрендә геолог гаиләсендә туган кызга Ленино-Кокушкино авылында төпләнгәнче бик күп юллар узарга туры килә әле.
«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Язмышым – һөнәрем» номинациясендә катнашкан бу ханымга жюри әгъзалары «Афәрин»нән башка сүз тапмады.

ҺӨНӘРДӘ – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМ

– Әтинең эше үзенчәлекле иде. Геологлар еш кына бер урыннан икенчесенә күчеп эшлиләр. Мин кечкенә вакытта ук Тувадан Таҗикстанга күченгәнбез. Мәктәпне Дүшәмбе шәһәрендә тәмамладым. Югары уку йорты сайлаганда күңелем Казанга ашкынды – С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институтына укырга кердем.

Әле ул вакытта авылда яшәячәген күз алдына да китерми шәһәр кызы. Дүшәмбедән килгән бит ул! Укуын тәмамлап та бетермичә кияүгә чыга Светлана. Шушы яктан – Ленино-Кокушкино егете була аның сөйгәне. Озак та көттерми, кызлары туа. Ләкин Светлана өчен академик ял алырга сәбәп түгел бу! Укуын вакытында тәмамлый ул.

– Кулга диплом алгач, ирем белән икебезне юллама буенча Алтайга җибәрделәр. Бийск шәһәрендә химия комбинатына эшкә урнаштык. Шунда төпләнеп калган да булыр идек, кызыбыз еш авырта башлады. Аның сәламәтлеген кайгыртып, минем әти-әни янына – Таҗикстанга күчендек. Дөньябызны түгәрәкләп, улыбыз туды, – дип искә ала Светлана ханым.

Тормыш шаукымы, илдәге сәяси вакыйгалар гаиләне тагын юлга кузгалырга мәҗбүр итә. 90 нчы еллар башында Дүшәмбе шәһәреннән Ленино-Кокушкино авылына күченеп кайталар. Бу юлы – китмәскә дип! Шул елдан бирле кошчылык фабрикасында эшли Светлана Борисовна. Быел хезмәт стажының 30 еллык юбилеен билгеләп үтә ул.

Кошчылык фабрикасында инкубаторлар операторы булып эшли башлаган яшь белгечне җитәкчелек тиз күреп ала. Үсеш юлына баскан фабрика яңа җитештерү юнәлешен башлап җибәрә – ыслау цехы ачыла бирәдә. Барлык кирәкле җайланмаларны, мичләрне кайтарталар. Фабрика өчен бу яңа юнәлешкә Светлана Борисовнаны җаваплы итеп билгелиләр. Цех җитәкчесе вазыйфасында җиң сызганып эшкә тотына ул.

– Яңа цехта ике кеше эшли башладык. Берсе – мин, икенчесе – минем кул астында эшләүче слесарь. Ике кешедән башланган коллективны 35 кешегә кадәр үстердек. Ике сменага бүленеп эшләдек. Кошчылык фабрикасын совхоз белән берләштереп, агрофирма барлыкка килгәч, җәй чорына ток мөдире вазыйфасын да йөкләделәр. Биш ел буе шулай барды эшем. Берничә елдан бройлер чебиләре үстерү цехына билгеләделәр. Ләкин анда озак эшләмәдем. «Синнән башка эш бармый», – дип, ыслау цехына кире кайтардылар.

Әнә шулай бөтен тормышы кошчылык фабрикасы тирәсендә әйләнә башлый Светлананың. Аның эш көне дә – бетми торганнардан. Хезмәттәшләре дә моны яхшы белә: Светлана Борисовнага киңәш сорап теләсә кайчан шалтыратырга була.

– «Ак Барс» кошчылык комплексы» ААҖдә чын патриотлар эшли, – ди гомуми эшләр буенча директор урынбасары Ләйлә Гайфуллина. – Бездә «синең эш», «минем эш» дигән нәрсә юк. Кирәк булса, цехка да барып эшлибез. Монда халык шулай тәрбияләнгән. Светлана Борисовна да әнә шундый чын патриот. Беркайчан да «нигә мин?» дими, җаваплылык алып, эшнең үзәгендә кайный. Коллективта аны хөрмәт итәләр, фикеренә һәрвакыт колак салалар.

– Эшемдә иң авыры – кешеләр белән эшләүдер. Һәркем белән уртак тел табарга, сорауларына канәгатьләндерерлек итеп җавап бирергә кирәк. Кешеләрне яратам мин, хөрмәт итәм. Күп очракта шул булышадыр. Кешегә карата гадел булсаң, алар да сиңа хөрмәт белән карый башлый. Бөтен сере шунда, – дип фикерли Светлана Пятибратова.

Тормышы эш белән генә бармый. Уңышлы хатын-кызның гаиләсе дә бәхетле булырга тиештер. Светлана ханымны эшендә «күп оныклы дәү әни» дип йөриләр. Ике баласыннан сигез онык сөю бәхетенә ирешкән ул! «Җиде кызга – бер малай», – дип елмая бәхетле әби.

– Туганнарым, балаларым, әти-әниләр дә монда яши. Кызыбыз белән улыбыз да гаиләләре белән безнең янга кайтып урнаштылар, өй салдылар. Үз әти-әниемне дә күченеп кайтырга үгетләдем. Кайнанам, кайнатам кошчылык фабрикасында эшләп, лаеклы ялга чыктылар, ирем, кызым, киявебез шушында. Санап карасаң, фабриканың үзенә – 51 ел, ә безнең гаиләнең аңа багышлаган гомуми стажы – 70 елга якын инде. Һөнәрем – минем язмышым дими, ни дисең...

Кошчылык фабрикасы өчен волейбол командасында да уйнаган әле Светлана Борисовна. Мәктәптә укыган чакта спорт белән шөгыльләнүе бушка китмәгән: «Пестречинка» данын яклап, ярышларда катнашканда волейбол буенча 2 нче разряды бик ярап куйган! Светлана Борисовнаның күпчелек дуслары да – аның хезмәттәшләре. Уенынчынын бергә кушып, үзләрен «Әбекәйләр бандасы» дип атыйлар. Яшьләре барса да, яшьлек дәртен югалтмаган, кызларча шаян, кыю, тәвәккәл ханымнар алар. Бергә ял итәләр, кунакка йөрешәләр, мунча керү көннәре оештыралар, бәйрәмнәр уздыралар. Сәяхәт итү – Светлана ханымның иң яраткан шөгыле. Шул вакытта гына эшен беразга онытып, рәхәтләнеп ял итә ул. Эштә дә моны аңлыйлар – борчымыйлар. Телефоны шул вакытта гына тынып тора цех җитәкчесенең.

– Чит илләрне күргәннән соң кызлар белән яңа хыялыбыз барлыкка килде. Безнең илебез яңа ачышлар өчен үзе бер мәйдан бит! Без күрмәгән күпме җирләр бар Россиядә. Үзебез өчен Байкалны, Калининградны, Кавказ тауларын ачарга телибез. Илебездә тынычлык кына булсын!

Алсу ШАКИРОВА
Фото: Анна Арахамия

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

«НАЗ БАЛАНЫ БОЗМЫЙ»



Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Әни кешенең генә түгел, үсмернең фикерен дә тыңлап карыйк әле. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты Алсу КАЮМОВА һәм аның кызы НӘРГИЗ.

Нәргиз, әниең синең өчен иң элек дус кызмы, әниме?

– Дус кыздыр, мөгаен. Әниләрнең балалары белән аралары начар булганын күп ишетәм. Әгәр «мин – әни, димәк, мин хаклы», «нәрсә әйтәм, шуны эшлисең», «минем кебек уйларга тиешсең», ди икән, бу бик начар. Әлбәттә, мондый әниләргә берни сөйлисе килми. Шулай итеп аралар суына инде ул. Ә минем әни башка әниләрдән аерылып тора. Ул мине аңлый.

Димәк, әниең бик йомшак, сиңа чикләүләр куймый?

– Бик йомшак түгел инде. Ул аңлый торган кеше. Әтигә караганда, әни яшьләргә якынрак. Безнең әти – консерватив кеше. Әни белән үзара яшьләр сленгы кушып сөйләшүебезгә күпләр аптырый да. Мин нәрсәнең начар, нәрсәнең яхшы икәнен аңлыйм инде. Балачактан ук яшьтәшләремнән аерылып тордым. Әти дә шундый булган. Киләчәк турында, болай эшләсәм нәтиҗәсе ничек булыр икән дип гел уйлыйм.

Нәргиз, синең әти-әниең танылган кешеләр. Моны тою сиңа рәхәтлек бирәме, әллә комачаулыймы?

– Мин аларны шуның кадәр танылган дип санамыйм да. Алар бит миңа иң элек әти-әни. Әйе, классташларым: «Әти-әниеңне телевизордан күрдек» йә «Спектакль карарга баргач, күрдек», диләр. Мин моңа күнеккән инде. «Әти-әниең актерлар, сәхнәдә шундый матур уйныйлар, ә син оялчан, аларга охшамаган», – ди укытучым.

Киләчәктә нинди һөнәр иясе булачагың турында уйланасыңдыр. Бу җәһәттән әти-әниең басым ясамыймы?

– Юк! Кайсы юлны сайласаң да, кабул итәрбез, диләр. Һөнәрне бит теләсә кайчан алыштырырга була. Беркайчан да соң түгел. Кечкенә чакта актриса булам дип йөри идем. Хәзер миңа музыка бик ошый. Музыка мәктәбен тәмамладым. Башта анда уку ошамады, билгеле, иреклे буласым, уйныйсым килә иде. Инде менә мәктәпне тәмамладым да, күңелсез булып китте. Музыка белән шөгыльләнүдән рәхәтлек алганмын. Хәзер гитарада уйныйм, вокалга йөрим. Миңа электрогитара алып бирделәр.

Нәргиз, идеаль әти-әниләр нинди булырга тиеш?

– Аңласыннар иде. Бигрәк тә үсмерлек чорында. Кирәк вакытта алар ярдәмен тоясы килә! Уйларың, проблемаларың белән ялгыз калмаска тиешсең. Комплекслар булмасын өчен алардан мактау сүзләре ишетүе мөһим. Һәм юмор хисле булсыннар иде, юкса күңелсез булачак.

Әти-әниеңнән иң шәп киңәш?

– «Сине борчыган ул проблема ун елдан мөһим булмаячак». Әти гел шулай ди. Һәм мин аны аңлый башладым инде. Хак әйтә әти. Әни бик күп киңәш бирә. «Бераз битарафрак бул», – ди. Мин бик борчылучан, шул ук билгеләр өчен дә.

Гаиләдәгеләр белән конфликтлар буламы?

– Ул бар кешеләрдә була торгандыр инде. Эмоцияләр чыга инде ул. Аннан бер-беребездән гафу үтенәбез.

Кем беренче гафу үтенә?

– Әни күбрәк.

Энекәшләрең аптыратмыймы?

– Юк, алар икәү булгач, гел бергә нидер эшлиләр. Безнең бит яшь арасы өч яшь ярым гына. Бергә үсәбез дисәк тә була. Кайвакыт икәүләп юри мине үртиләр. Менә шул якларын яратмыйм. Әмма аларның булуы зур бәхет. Мәктәптә безнең кабинетлар күрше генә. Минем янга кереп сөйләшеп йөриләр.

Нәргиз, әниең белән иң бәхетле мизгел?

– Ой!.. Икәү генә авылга һәм Чаллыга кайтудыр! Машинада музыка кушып куйдык та, юл буе сөйләштек. Бик рәхәт сәяхәт булып истә калды ул.

Хәзер үсмерләр башка дип, сезне тәнкыйтьләүчеләргә җавабың...

– Бу кешеләр үзгәрешне кабул итә алмый. Һаман да совет заманындагы кебек тормыш булуын телиләр. Хәзер күп нәрсә үзгәрде. Ә аларның үзгәрәсе килми, башкаларны гына үзгәртергә телиләр. Минем яшьтәшләр аңлырак, толерантлырак. Алар киләчәк турында бик күп уйлыйлар. Тизрәк мөстәкыйль булып яшиселәре килә.

Алсу, сез – өч үсмер әнисе. Кызыгыз Нәргиз һәм игезәк улларыгыз Ирхан белән Әмирхан. Аларның холыклары төрлеме? Үсмерлек чорын ничек кичерәсез?

– Безнең очракта малайлар белән җиңелрәк, алар игезәкләр булуга карамастан, бик тыныч булдылар. Ә менә Нәргиздә, «үз кубызына биетә» белү сәләте бар. Ул үз теләгәнен эшләми калмый. Балалар белән бар нәрсәне уртага салып сөйләшергә тырышабыз. Әлбәттә, алар бөтенесен дә тыңлый дигән сүз түгел бу. Психологлар әйтүенчә, аларның болай булулары бик дөрес. Әйткәнне генә тыңлап торган тәртипле баланың киләчәге өчен борчылырга кирәк икән. Ул үскәч тә син әйткәнне генә көтеп яшәячәк. Ә кечкенәдән үзенчә эшләгән балада ныклы холык формалаша, диләр.

Димәк, сез балаларыгызга һәрвакыт рөхсәт бирә торган әни?

– Компромисска күп барам инде мин. «Юк» дип дулап алсам да, сындыралар – йомшаклыгым бар. Холкым шундый. Ә менә әтиләре «юк», ди икән, димәк, юк. Ул шулай булырга тиештер, мөгаен. Әнидә «әтиегезгә әйтәм», дип, әтигә аркалану булсын инде ул. Мин гел, әтиегездән сорагыз, дим. Соңгы сүзне әти әйтергә тиеш дип уйлыйм.

Алсу, балаларыгызга, тулысынча ышанасызмы?

– Мин ышанам. 100 процент ышанам.

Инстаграмда кызыгыз белән төшкән фото астына сердәшем дип язасыз...

– Мин кызыма дус кыз да, әни дә. Әмма дус кыз дәрәҗәсендә булам дип, бала каршында әни абруе югалырга тиеш түгел. Дус булсаң, алар күбрәк ачыла. Баланың нәрсә белән яшәвен, башында нинди уйлар булуын беләсең. Өчесе дә мәктәптән кайткач, көннәре ничек узганы турында сөйләшәбез.

Күп үсмерләр, үсмерләр генә түгел, хәтта кечерәкләр дә мәктәп хәлләрен өйдә сөйләми. Ул гадәтне ничек булдырырга соң?

– Өч кыз үстек, әни укытучы иде. Безнең гаиләдә дә сәгатьләр буе сөйләшеп утыру гадәте бар иде. Мәктәп хәлләрен, уку турында, проблемаларны. Үзеннән-үзе бу модельне үз гаиләмдә кулланам. Без бит бар нәрсәне үзебез үскән гаиләдән күчерәбез.

Үзегез нинди үсмер идегез?

– Апаларым арасында малай кебек булдым. «Синең үскәнең сизелмәде дә», – ди әни. Минем бик хыялый үсмер идем. Артист булам дигән максат канатландырып торды. Шуның белән яшәдем. Хәзер күп үсмерләр күңел төшенкелегенә бирелә. Аларда романтика юк. Интернеттан артык күп мәгълүмат алу да начардыр, мөгаен. Алар бит бездән күп беләләр. Ә без хыялыйлар идек.

Актриса – гаилә кешесе түгел, сәхнә кешесе, диләр...

– Балалар – беренче урында! Иҗат бит ул – эш. Картайгач, иҗат сиңа нәрсә бирәчәк соң?! Бер стакан суны, ни дисәләр дә, балалар суза. Үз балаларыңнан башка син беркемгә кирәкмисең.

Кичләрен өйдә булмауны, гастрольләрне балалар ничек кабул итә?

– Яратмыйлар инде. «Тагын спектакльмени?» – дип калалар. Кич белән әниләр чыгып киткәнне кем яратсын, үзебез дә яратмый идек. Кечкенә вакытларында бергә йөрдек инде театрга. Гримерка тулы уенчык була торган иде. Гастрольләр вакытында исә әбиләре килә.

Өч балагыз да музыка мәктәбендә укый. Үз теләкләре белән керделәрме?

– Юк инде, әтиләре шулай хәл итте. Музыка мәктәбенә йөргән, музыка тыңлаган балалар аерылып торалар. Ике кул да эшләгәч, баш миенең ике ярымшары да эшли дигән сүз.

«Отличник синдромы» кирәк дип саныйсызмы?

– Юк, әлбәттә. Бервакытта да балаларга син «бишле»гә генә укырга тиеш дигән шарт куймадык. Идеаль булып булмый ул. Бездән матуррак, акыллырак, уңышлырак, талантлырак кешеләр барлыгын беләбез. Моны кабул итеп һәм аңлап яшәргә кирәк.

Алсу, әйттек инде, балалар бездән күбрәк белә. Кайвакыт аларга безнең белән кызык та түгел. Әмма шулай да аларны ничек үз яныңда җыеп торырга?

– Гап-гади аның рецепты: яратканыңны күрсәтергә кирәк. Шартларсыз ярату ул – бу җирдә булганнары өчен ярату. Һәрвакыт кочаклап-сөеп тору кирәк. Моны психологлар да киңәш итә. Мин балаларны гел кочаклап-үбеп торам. Нәргизнең әле кайвакыт кочаклашып, иркәләнеп ятып торасы килә. Узып барганда үбеп, тупылдатып сөеп алам. Малайлар миннән озын, мәктәптән кайткач үзләре килеп кочаклап ала. Иркәләп уятам, массажлар ясыйм. Кечкенә чакта безнең өйдә дә шулай иде. Балалар синең яратканыңны һәрвакыт сизеп яшәсеннәр.

Алсу Каюмовадан кызлар тәрбияләүдә өч кагыйдә:

– Кыз баланы иркәләү кирәк. «Син иң матуры, иң акыллысы, иң талантлысы» дип үсендереп тору аларга үз-үзләренә ышаныч өсти. Үз-үзен карарга, тәрбияләргә өйрәтү кирәк. Кызлар үз бәяләрен белсеннәр иде.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия



Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.
«Сөембикә» журналы «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

«ИРЕҢНЕҢ ӘНИСЕН ЯРАТ!»



Минем дә килен булып төшкәнемә инде 20 ел. Үзебез генә белмибез, хәтта күп вакыт очраклылык дип саныйбыз, ә Аллаһы Тәгалә, вакыты җиткәч, насыйп ярың белән сине кавыштыру өчен бөтен юлларны да ача икән ул...
Мәктәпне тәмамлагач, Казандагы 68 нче лицейда белем алдым – компьютерда җыю белгечлегенә укыдым. Компьютерларның тормышыбызга кереп кенә килгән чаклары иде әле. Практикамны «Татарстан» телерадиокомпаниясендә уздым: машбюрода эшләдек, яңалыкларның текстларын җыйдык. Ошады! Инде эшкә дә шунда калырга тиеш идем. Телерадиокомпаниянең ул чактагы җитәкчесе Айрат Сибагатуллин: «Ярты елдан барыгыз да журналистлар булачаксыз!» – дип өметләндереп торды. Әмма күктә инде барысы да хәл ителгән булган...

Районыбыз башлыгы Рәис Нургалиевич белән бер авылдан – Лесхоз кызы мин. Контора янында очрашып, әти белән сөйләшкәндә, инде диплом алуымны белгәч: «Үзебездә дә телевидение ачарга җыенабыз, монда кайтсын», – дигән. Әтигә шул сүз җитә калды: «Безнең янда булырсың», – дип, мине авылга кайтарды.

Телевидение ишеген шакырга ук кыюлык җитмәде. Сабага, «Балалар иҗат үзәге»нә эшкә урнашырга барырга дип чыктым. Юл читендә кул күтәреп, машина көтеп басып торам. Һәм шул вакыт мине район башлыгы Рәис Миңнеханов туктап утыртты. Кая баруым, нәрсә эшләп йөрүем белән кызыксынды. «Хәзер туп-туры телевидениегә барасың, безгә анда кеше кирәк», – диде ул, икеләнергә урын калдырмаслык итеп.

Чәчләр ясалган, бизәнгән – яшь, матур, зифа чагым иде бит. «Саба дулкыннары»нда: «Илдар килгәч, сине туры эфирга чыгарып карарбыз», – диделәр. Илдар дигәннәре Чаллыдан килеп эшләп йөрүче инженер икән. Аны шунда ук олы кеше дип күз алдыма китердем. Мине стажер итеп алдылар: планеркаларга йөрим, эшкә өйрәнәм. Ике атна вакыт шулай узды. Һәм бер көнне планеркада кемгәдер: «Илдар», – дип эндәштеләр. Карыйм, яшь кенә егет! Калганын барысын да вакыт хәл итте...

Бер елга якын очрашып йөргәч, Илдар мине әти-әниләре белән таныштырырга дип, Чаллыга кунакка чакырды. Үзе ике атналык ял алып, алданрак кайтып киткән иде. 2001 елның җәе бу... Июнь ахыры. Бүгенгедәй хәтеремдә – шундый матур көн иде. Ул елларда Чаллы якларына Сабадан автобуслар йөрми иде әле. Мине Шәмәрдән аша үтә торган автобуска утыртып җибәрделәр. Саба белән Чаллы арасы – 200 чакрым тирәсе. 21 яшемә җитеп, беренче тапкыр берүзем шушындый ерак юлга чыгуым... Барам тәрәзәдән тирә-юньне күзәтеп, ә башымда мең төрле уй. Әти-әнисе ошатырлармы, ничек кабул итәрләр, нәрсә дип сөйләшеп китәрбез? Илдар каршы алырга онытмасмы дигән курку да бар күңелдә – ят шәһәргә барып төшәм лабаса. Фикерләремне бер туплыйм, бер сүтәм; тагын җыярга тырышам, кабат очларын югалтам.. Беренче очрашуыбызны күз алдыма китерергә тырышып карыйм. Аннан: «Ничек үтәр ул?» – дип яңадан хафага төшәм... Ниһаять, килеп җиттем. Илдар мине, әлбәттә, автовокзалда ук каршы алды. Ничек мин киләсен онытсын ди инде?! Чаллы бик матур, чиста, якты, иркен шәһәр икән. Аңа шул көнне үк гашыйк булдым. Илдар яшәгән, ул һавасын сулаган кала бит!

Илдарлар Чаллының үзәгендә – мэрия бинасы каршында ук яшиләр икән. Фатирларына күтәрелдек. Миңнегөл апа белән Исмәгыйль абый өйдә түгелләр икән әле, безне Илдарның сеңлесе Гүзәл каршы алды. (Алгарак китеп булса да әйтим, аларда исемнәр белән шулай кызык килеп чыкты: кызлары да, мин – киленнәре дә Гүзәл, уллары да, кияүләре дә – Илдар.) Өйләре иркен, шәһәр фатиры өчен бик зур булып тоелды миңа.

Ул арада әтисе белән әнисе бакчадан кайттылар. Иң беренче мине әтисе күрде һәм... «Исәнмесез?!» – диде дә үз бүлмәләренә кереп тә китте. Ә әнисе: «Сөбханалла, бездә кунак бар икән бит!» – дип, мине кочаклап ук алды. Бераздан аңлаштык: әтиләре мине кызы Гүзәлнең дус кызы дип уйлаган. Өр-яңадан исәнләштек, һәм ул да мине килеп кочаклап алды. Күңелдәге куркулар бер мизгелдә таралды... Бик ачык күңелле кешеләр булып чыкты алар. Әнисенең сабырлыгы йөзендә үк чагыла. Сорауларны да әкренләп, җайлап, урынлы гына бирә, бөтен нәрсәне дә ашыкмыйча гына хәл итә. Танышу көне тиз һәм бик күңелле үтте минем өчен.

Шуннан соң без Илдар белән бергә Сабага кайтып киттек, ә июль ахырында ул миңа тәкъдим ясады. Чаллыдан әти-әнисе авылга кыз сорарга кайттылар, шул ук көнне никах та укыттык. Мәрхүм әтием абыйсы Фәриткә: «Киявебез мишәр була инде», – дип сөйләгән. Фәрит абый исә: «Илдар бер дә мишәргә охшамаган, аннан, безнең Гүзәл дә төшеп калганнардан түгел – махы бирмәс», – дигән. Шөкер, миңа исә үткенлегемне эшкә җигеп, берәү белән дә көрәшергә, нәрсәдер исбатларга кирәк булмады.

Килен һәм кайнана диләр менә. Ә минем өчен кайнана дигән сүз бервакытта да булмады, ул минем өчен – ӘНИ. Яраткан иремнең әнисе! Улын якын иткәч, аның әти-әнисен дә шундый ук дәрәҗәдә якын итәргә, яратырга, хөрмәт итәргә тиешсең дигән әйберне миңа үскәндә үк сеңдерделәр инде.

Никах алдыннан, гадәттә, олы кешеләрнең хәерфатыйхасын алалар бит: мин дә әтиемнең әнисенә – Гөлсем әбиемә сөенечем белән уртаклашырга киттем. Ул чакта яңалыгымны җиткергәч, әбинең иң беренче биргән киңәшен бүгенгә кадәр күңелемнең түрендә йөртәм һәм нинди генә никах мәҗлесенә, туйга чакырсалар да, барлык кәләшләргә дә нәкъ шул киңәшне әйтәм. Әбием: «Кызым, тормышта бәхетле буласың килсә, иреңнең сине ныграк яратуын теләсәң, иң беренче итеп аның әнисен ярат», – диде. Урыннары оҗмахта булсын Гөлсем әбиемнең... Икенче көнне, шатлыгымны кочагыма кысып, әбинең олы апасы Мөсәвәрә әбигә бардым. Ул да нәкъ шушы сүзләрне кабатлады! Инде азмы-күпме тәҗрибәм бар, икеләнмичә әйтә алам: мин бу киңәш белән 100 процентка килешәм! Очрашып йөрү – бер нәрсә, ә тормыш итү – башка. Бергә яши башлагач, аптырап та каласың: сез әле бер-берегезнең холкын да ахыргача белеп бетермисез икән, ирең нәрсә ярата яки яратмый – күп вакыт анысы да мәгълүм түгел, аңа ничек яраклашырга икәне дә синең өчен сер... Ә ул әниеңнең – кайнананың – тудырып-үстергән баласы, улын биш бармагы кебек белә: көйли дә, җайлый да, сүзен дә таба... Бүгенге көнгә кадәр шулай – минем көчтән килмәгәнен, шыпырт кына әни белән сөйләшеп алабыз да, тиз генә хәл итеп тә куябыз. Әмма шуны да искәртеп үтәсем килә, моның өчен кайнананың бик зирәк, акыллы булуы кирәк шул.

Шулай тормыш башланды... Бер елдан кызыбыз Камилә туды. Ерак дип тормадылар, безне бала тудыру йортыннан каршыларга Чаллыдан әти белән әни дә кайтты. Беренче оныклары бит! Чаллы әни (кеше арасында сөйләгәндә кайнанамны «Чаллы әни» дип йөртәм – беркайчан да кайнанам дип әйткәнем юк) кызыбызга үзе тегеп, шундый күп итеп фланель бала чүпрәкләре алып кайткан иде. Андый нәрсәләр онытылмый...

Аралар ерак булса да, күңелләр якын безнең әни белән.

Әни дә, әти дә бик булган, тырыш кешеләр безнең. Туганнар белән аралашканда «эш атлары», дим алар турында. Бакчалары Чаллыдан 40 чакрым ераклыкта урнашкан. 30 сутыйга якын җир ул! Җәен көн саен эштән соң икәүләп шунда китәләр. Әти моңарчы гел кырык башка якын умарта тотты, хәзер генә азрак киметте. Ә бакчалары! Ул 30 сутый җирдә йөрергә сукмак таба алмыйсың – нәрсә генә утыртмыйлар, ни генә үстермиләр! Без бит инде үзебез дә авылда яшибез – бакчабыз да бар. Камилә бәләкәй булса да, бераү генә иде бит: итәк тулы ишле бала карамыйм. Әмма әни: «Яшь бала белән сиңа авыр була», – дип, Чаллыдан кадәр өчәр литрлы банкада кыяр, помидор, төрле салатлар, компотлар ябып алып кайтты ул җәйне. Унбишәр банка! Аннан әни: «Кызым, Чаллыга кайтып тормыйсыңмы соң? Камиләне дә карашыр идек, сиңа да җиңел булыр. Оныкны без дә үстерештек дип куанырбыз», – диде. Мин ризалашуга, безне Чаллыга алып та киттеләр. Илдар көне-төне эштә – телевидениенең старт алган вакыты, проблемалар чыгып кына тора. Без Камилә белән дүрт айдан артык Чаллыда яшәдек. Яңа туган сабыйның мәшәкате, өйдә күпме кеше булса, шуның кадәргә җитә – «бала карашабыз» дип ике ягымда әти белән әнинең өзелеп торуы миңа бик рәхәт булды, әлбәттә. Моның өчен дә Аллаһының рәхмәте яусын аларга.

«Әни, бер дә ярдәм итә алмыйбыз, шуның кадәр күп утыртмагыз инде бакчаны. Безгә бит үзебезнеке җитә», – дим кайчакта. Ә ул гел: «Кызым, сез бәхетле торсагыз, без ул бакчаны сөенеп, шатланып кына үстерәбез!» – дип җавап бирә. «Сез генә әйбәт торыгыз!» – дип адым саен кабатлый ул безгә.

Тормыш арбасы гел тигез юлдан гына тәгәрәми – сикәлтәләре дә чыгып тора. 2013 елда ирем бик каты юл фаҗигасенә эләкте. Ай ярым хастаханәдә ятканнан соң өйгә кайттык. Берничә көн узган гына иде, көтмәгәндә өйдә авария килеп чыкты: йортыбызның бер як ниргәсе череп (су кереп ятканын белмәгәнбез булып чыкты), идән такталары түбән өйгә ишелеп төште. Идән белән бергә түбән өйгә душ кабинасы, унитаз, кер юу машинасы, раковина да төшеп китте. Барысы да җимерелде – яраксыз хәлгә килде... Болай да бик авыр вакыт – Илдар эшли алмый, мин дә аны калдырып эшкә чыга алмыйм – икебез дә эшсез дисәм дә була... Шул вакыт Чаллы әти белән әни акчалата бик зур ярдәм иттеләр: барлык туганнарыбыз җыелышып, өйнең түбәсен алыштырып, туалет-ванналарны яңартып киттеләр.

Тормышта әнигә мең рәхмәтле булган очракларны санап кына бетереп булырмы икән?! Ул мине бик күптөрле эшләргә өйрәтте. Әйтик, бәйләргә дә мин аннан өйрәндем һәм бүгенге көндә дә ул – иң яраткан шөгыльләремнең берсе.

Ә сынаулар... Алар һаман чыгып кына тора. Узган елның ахырында, 24 декабрь кичендә коточкыч хәл булды. Минем өстемә 700 килограммлы плитә төште. Һәрберсенең авырлыгы җитмешәр килограмм булган ун плитә... Исән калуым – үзе бер могҗиза... Бу хәбәрне ишетүгә, әни икенче көнне үк Чаллыдан туп-туры яныма хастаханәгә кайтты. Мине операцияләргә озатты, ут йотып дүртәр сәгать көтеп торды, «бар да әйбәт булыр» дип каршы алды... Аякка басканчы бер айга якын саклады ул мине. Барлык сызлануларыма, көйсезләнүләремә түзде. Авыртуга чыдый алмыйча, вакыт-вакыт кычкыруларыма, кирелекләремә... Аның ярдәме белән авыртуларым көннән-көн җиңеләйде, һәм Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән мин инде менә аякка бастым. Әни көн саен аякларыма массаж ясады, кулларымны гел хәрәкәтләндереп, уып торды. Хәрәкәт булмагач, мускуллар шундый тиз ката икән, моны әле белми идем. Палатада ярдәмгә мохтаҗлар бер мин генә түгел бит – әни аларга да вакыт тапты. Менә шундый олы йөрәкле, сабыр кеше ул минем!

Кайнана белән матур яшәүнең сере нидә соң? Барысы да үзебездән генә тора дип уйлыйм. Әгәр кайнанаң, аның туганнары сине якын күрүләрен теләсәң, әйткәнемчә, иң элек үзең аларны якын күр, хөрмәт ит – яратуыңны яшермә. Мәсәлән, мин Илдарныкыларны «мишәр туганнарым» дип йөртәм. Аларның һәрберсе белән яхшы мөнәсәбәттә. Әлхәмдүлилләһ, үзләре дә минем өчен «Саба килен» дип өзелеп торалар. Матур яшәүнең сере сабырлыкта да. Моңа сабырлык үрнәге булган үз әниемнән дә өйрәнәм.

Әлбәттә, укучылар арасында: «Син бит аның белән бергә тормыйсың, кунак кына булып кайтып китәсең: син дә яхшы, кайнанаң да яхшы», – дип уйлаучылар табылмый калмас. Ялгышасыз, бер түбә астында яшәсәк тә, әти-әнигә карата мөнәсәбәтем нәкъ бүгенгедәй булыр иде. Алар минем өчен бар нәрсәгә әзер торган, мине өзелеп яраткан, сабыр, тыйнак, акыллы кешене – иремне тәрбияләп үстергәннәр. Минемчә, бөтен сорауларга да җавап шушы.

Әни киңәшләр бирергә ярата, мин аның барлык киңәшләрен дә кабул итәм, тыңлыйм, әмма, яшермим, үземчә эшләгәннәре дә күбрәк. Аралар ерак булса да, күңелләр якын бит: телефон аша еш хәбәрләшеп, сөйләшеп торабыз. Безнең әни аз сүзле: күбрәк мин сөйлим, ул тыңлый. Миннән арып китсә, сабыр гына: «Кызым, сүзең беттеме?» – ди. Шуннан барысын да аңлыйм. Әни белән сөйләшә башлауга, башта аның хәлен белешәм, аннан әтинекен сорыйм: шул гап-гади сүзләргә күңелләре була. Бер нәрсәне яхшы беләм: әнинең килене белән киявенә генә түгел, үзенең ике баласына да бер тапкыр да: «Сез моны дөрес эшләмисез!» – дигәне юк. Ялгыш кына әйтсә дә, ишетер идем. Бер булмаса, бер колакка керер иде. Баласының бәхетле тормышта яшәвен теләгән ана шундый булырга тиеш дип уйлыйм. Ир белән хатынның бүген сүзләре килешмәсә дә, иртәгә алар бер фикердә булып уянырга да мөмкин бит...

Гүзәл ШӘРИФУЛЛИНА.
Саба районы.
Фото: гаилә архивыннан

«МИҢА МАЛАЙ КИРӘК!»

Без – күп балалы гаилә. Ирем беренче баланы ук малай дип көтте. Аның әти-әнисе дә малай онык турында хыялланды. Икенче балама уздым, тагын кыз бала насыйп булды. Инде өченчесен куркып кына көтәрдем. УЗИда кыз буласын белгәч, үземә дә авыр булды. Ирем артык сөенмәде дә кебек. Малай кирәк дип, дүртенче тапкыр бәбигә уздым... Шулай итеп, дүрт кыз үстерәбез хәзер. Ирем әле дә улы турында хыяллана. Ләкин мин моны башка күтәрә алмам кебек. Малай көтеп узган йөклелек чорларым болай да тоташ стресска әйләнде. Бүтән бала кирәкми, боларын исән-сау үстерергә язсын, дим иремә. Ләкин ул килешергә теләми. Шушы балаларыбызга риза булсын өчен иремә нинди сүзләр табып аңлатырга? Малай телим дип, башка гаилә кормасмы дип тә куркам...

Рәмзия.
Түбән Кама.

Булат БӘЙРӘМОВ,
җырчы, алып баручы:

– Бу ирнең шулай уйлавы бик кызганыч. «Нәсел дәвамчысы булырга тиеш» дигән уйларны аның үзенә дә сеңдереп үстергәннәр, күрәсең. Кайсы баласы үзенә бәхет китерәсен берәү дә белми. Мин Аллаһтан хәерле, сау-сәламәт балалар сорадым. Гел малай сорап, бала кимчелекләр белән туган яисә үскәч әти-әнисенә бик зур авырлыклар китергән, яшь килеш вафат булган гаиләләрне беләм. Кыздан нәрсә күрәсен, малайдан нәрсә көтәсен беркем дә алдан әйтә алмый. Малай теләп, сез үз кызларыгызны кимсетәсез түгелме соң? Алар сезгә кадерле түгелмени? Кызларымның берсен дә биш малайга да алыштырмас идем... Ул кызларыгыз сезгә шулкадәр бәхет китерерләр әле, нишләп алай дип әйттем дип үкенерсез.

Нәсел дәвамчысы, фамилияңне калдырганчы, башта син үзең тормышта ниндидер эз калдырырга тиеш. Мөхәммәд пәйгамбәребезнең (с.г.в.) уллары яшьләй үлгән, кызлары гына үсеп җиткән. Аның нәселен түгел, үзен беләбез. Тарих битләренә кергән шәхесләр дә балалары белән түгел, үз гамәлләре белән танылганнар.

Хатын-кызның монда бер гаебе дә юк. Яшь барган саен, бала тапкан саен сәламәтлек тә артмый. Булган балалардан игелек күрергә язсын дип теләргә кирәк. Кияүләрегез улларыгыз кебек булыр әле, бәлки. Күп гаиләләр, гомумән, бала таба да алмый бит. Алар кем туса да, бергә генә дә риза булырлар иде... Иң элек үзегез яхшы кеше булыгыз, гаиләгездә, кызларыгызда, җәмгыятьтә якты эз калдырыгыз.

Ләйсән ГЫЙМАЕВА,
җырчы:

– Сез үзегез өчен яшәгез, сау-сәламәт балаларыгыз булганга сөенегез. Үз сәламәтлегегезне корбан итмәгез. Тагын ничә бала алып кайтсагыз да, аларның барысы да кыз булырга мөмкин бит. Шушы балаларыгызны үстерегез, укытыгыз. Баланың җенесе нинди булуы тулысынча ир-аттан торганын онытмагыз. Әгәр дә инде депрессия башланганын сизсәгез, стресс кичерсәгез, психологка яисә психотерапевтка мөрәҗәгать итегез. Ирегезнең үз-үзен тотышы да белгеч киңәше сорый кебек...

Белгеч фикере



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог

– Күп кенә ирләргә балачактан нәселне һәм фамилияне дәвам итәргә кирәк дигән «программа» бирелә. Монда гайре табигый берни дә юк. Әти буласы кеше, кыз туасын белгәч, бигрәк тә икенчесен, өченчесен көткәндә күңеле төшәргә мөмкин. Ул бит үзенең «бурычын» үтәмәгән. Баланың дөньяга киләсе елы, көне, сәгате белән алдан язылган була. Үзегезгә сорау бирегез – ни өчен бала табарга уйладыгыз? Баланы җенесенә карамыйча кабул итегез, яратыгыз. Бер-берегезне гаепләмәгез. Балаларның кечкенә чагында бер үк дәрәҗәдә үсүен һәм җенес аермалары бөтенләй диярлек сизелмәвен исәпкә алыгыз. Алар бер үк дәрәҗәдә сөйкемле, назлы һәм иң яраткан кешеләр бит.

Беренчедән, баланың җенесен ир-ат билгели – Y-хромосоманы ир кеше йөртә бит. Бу турыда ирегезгә сөйләгез. Кемне чәчкән – шул туган. Икенчедән, кызлары аңа оныклар алып кайтачак, аларны тәрбияләр өчен вакыты да, сабырлыгы да, зирәклеге дә булачак – барлык хыяллары аларда тормышка ашачак дип аңлатыгыз. Өченчедән, хәзер кайбер кызлар үзләренә әтиләренең фамилиясен калдыра һәм аны үз балаларына да тапшыра. Шуны истә тотыгыз: бала безгә ни өчендер түгел, ә алар – безне, без аларны яратыр өчен бирелә.

PRESSA

ЕФӘК БАУЛЫ БЫЛБЫЛ КОШ БАРДЫР СИНЕҢ ИЛЕҢДӘ...

– Без өйләнешәбез!
Тормышның өр-яңа этабы бүгенге гаиләләрдә шулай башлана: кызның улыгызга чыгарга риза булуы инде билгеле, хәтта никах, туй көне дә билгеләнгән – сезгә бу яңалык белән килешәсе генә калган. Димләү, яучы җибәрү кебек йолаларга мөрәҗәгать итү кирәкми дә. Әмма элеккеге гореф-гадәтләр тормышыбыздан бөтенләй юкка чыкты дия дә алмыйбыз. Әйтик, егет ягының кыз сорарга баруы бүген дә бар. Хәтта кәләш инде күптән ризалык биргән очракта да. Кыз баланы кадерләп үстергән ата-анага хөрмәт күрсәтү, аларның да ризалыгын, фатихаларын алу дигән сүз бу. Булачак киленнәре яшәгән йорт бусагасын атлап узалар да, егетнең әнисе йә әтисе сүз башлый:
– Безнең нинди ният белән килгәнне беләсез инде...
Ә шулай да кыз сорау, кыз ярәшү йоласы элегрәк ничек булган?



Буй җиткән улларына кыз сайлау белән, гадәттә, әти-әниләре үзләре шөгыльләнгән. Таныш-белеш, туган-тумача белән киңәшләшкәннәр, бик сирәк очракта гына егетнең үзенең дә теләге искә алынган. Авыл җирендә яшәүче яшьләр бер-берсен чишмәгә суга барганда, кич утырганда, аулаг-өйләрдә булса да күрә, күзли алган, ә шәһәрнекеләр мондый мөмкинлектән дә мәхрүм булган. Егет белән кызның бер-берсен кайчак никахта, туйда гына күрүе әби-бабайлар сөйләгән әкият кенә түгел ул... Кыз сайлаганда, иң беренче чиратта, ике як та бер дәрәҗәдәге кешеләр булсын дип караганнар: байлыгы, белеме, дине, саулыгы-сәламәтлеге... Бөтен нәсел-нәсәбе, әби-бабасы өйрәнелгән. Соңгысы, әлбәттә, туган белән туган никахлашмасын өчен кирәк булган: ата ягыннан җиде буын туганнарга гына кавышырга ярый дип саналган. Бик сирәк кенә – абыйсы вафат булганда энесе аның хатынына өйләнгән, ә тол калган җизнәсе исә балдызын алган. Мал читкә китмәсен, балалар ятим булмасын өчен бу адымга барганнар.

Ниһаять, улларына туры килә дип саналган кыз табылган – сорарга барырга дигән фикергә киленгән. Инде бу зур эшкә атнаның кайсы көнендә тотынырга? Татарларның күбесе дүшәмбе һәм җомга көннәре уңышлы дип санаган. Касыйм татарлары кыз сорарга – сишәмбе, чәршәмбе, җомга көнне, ә мишәрләр пәнҗешәмбе һәм якшәмбе көнне генә барган.

Кыз ярәшү (димләү)

Бу бик җаваплы һәм катлаулы эшне гомер-гомергә яучылар (димчеләр) башкарган. Башкода итеп егет ягыннан, аның туган-тумачасы арасыннан абруйлы, мөхтәрәм, җор телле кешене җибәрергә тырышканнар. Кайчак башкода булып егетнең әтисе үзе барган. Башкода тол булмаска тиеш диләннәр: ир кеше икән – өйләнгән, хатын-кыз икән – кияүгә чыккан булсын. Ул кыз ягының нәсел-нәсәбен, тамырларын сораштырган. Халыкта сакланып калган менә бу җыр да шул хакта сөйли: *Йөгереп үк төштем инеш дип, / Бөҗыралар әлдем көмеш дип. / Әзли генә торгач табыштык, / Нәселегез асыл, имеш, дип.*

Пермь татарларында кыз сорарга егетнең әти-әнисе үзе барган, ә Казанда һәм Казан артында махсус бу эш белән генә шөгыльләнүче кешеләр – яучылар булган. Алар шушы эш өчен алынган бүләкләр һәм акча хисабына гына яшәгәннәр. Яучының төп максаты – кыз ягыннан никахка ризалык алу булган. Ул ике як арасында арадашчы ролен үтәгән, килеп чыккан бөтен каршылыкларны, кытыршылыкларны җайларга тырышкан. Юкка гына халыкта: «Димче диңгез кичерер», дигән гыйбарә сакланып калмаган. Үз дигәненә ирешер, димәк!

Капканы яучы ачып кергәнен кызлы йортта шунда ук аңлаганнар: аның чалбарының бер балагы төшкән, берсе тездән өскә кадәр күтәрелеп куелган булган. Ә яучы хатын-

кыз, киресенчә, ыштанының бер балагын өскә чыгарган, икенчесен оекка кертеп кигән. Аның күзеннән бернәрсә дә читтә калмый: сөлгеләре чистамы, ишегаллары ялт итеп себерелгәнме, себерке урынына куелганмы... «Кемлегеңне беләсең килсә – башкода җибәр», дигән сүз юктан гына килеп чыкмаган! «Яхшы җирдән килдем, теләгем сезнең белән кода-кодагый булу. Сезнең кызыгыз, безнең егет бар», – ди ул. Оренбург һәм Әстерхан татарларында яучы: «Мин сезгә зур үтенеч белән килдем», – дип сүз башлаган һәм беркайчан да матча турысына утырмаска тырышкан. Малмыж татарларында яучы, кыз өенә килеп туктагач, атын алгы яктан әйләнеп узган – бу уңыш китерә дип ышанган. Ул да өйне икегә бүлеп торган матча турысына утырмаган, хуҗалар әйткәч кенә түргә узган һәм нигә килгәнен сиздерер өчен урындыкка мендәр куярга сораган. «Мин – мендәрле кунак», – дигән ул. Кызларын яучы димләгән егеткә бирергә уйламасалар, хуҗалар аны ишек төбеннән ерак уздырмаганнар. Себер татарларында яучы кыз өенә бер кулына яулыкка төрелгән ипи, икенче кулына очына кулъяулык бәйләнгән озын таяк тотып барган. Беренче тапкырдан ук кызның атаанасы ризалык бирмәгән: «Агай-эне белән киңәш итәбез әле», – дигәннәр.

Яучы итеп авылда дәрәҗәле, ышанычлы, сүзгә оста, үтемле итеп сөйли, сер саклый белә торган олы кешене җибәргәннәр.

Мәһәр

Кыз димләү йоласында мәһәр турындагы сөйләшүләр бик зур урынны алып торган. Мәһәргә акча да сораганнар, кием-салым да, урын-җир әйберләре дә (түшәк, ястык, юрган, чыбылдык), йорт кирәк-ярагы да, ит, бал, май ише ризыклар да. Хәтта ат, сыер, бозау, сарык кебек терлек-туар да. Мулла, никах укыр алдыннан, аның күләмен никахларны теркәү кенәгәсенә язып куйган. Уртача хәлле һәм баерак гаиләләрдә моның билгеле бер исемлеге булган. Казан татарлары мәһәргә тугыз төрле әйбер сораган: сандык, көзге, өс-баш киемнәре тегәргә тукыма, ефәк һәм мамык шәл, күлмәклек, калфак, күннән тегелгән аяк киеме, галуш... Әстерхан татарларында мәһәр тугыз төргәктән торырга тиеш булган: берсендә – яулыклар, шәлләр, икенчесендә – күлмәклекләр, өченчесендә тәм-том... Һәм бу төргәкләрне кияүнең тугыз туганы китергән.

Мәһәрнең зурлыгы, әлбәттә, кияүнең әти-әнисенең хәлле кешеләрмегүгелме икәненә бәйләнгән. Малмыж татарларында, мәсәлән, кызның әтисе булачак кодасына мәһәрнең күләмен үзе билгеләргә кушкан. Әгәр мәһәрне күпсенсәләр, кире кыз ягына барып, аны киметүне үтенгәннәр.

Мәһәр бик сирәк очракта гына туйга кадәр түләнеп беткән. Әгәр никахка кадәр, мәһәргә килешенгән әйберләр алынып бетмәсә һәм яшьләр озак та тормый аерылышсалар, мәһәр барыбер бирелеп бетәргә тиеш булган. Мәһәр тулысынча яшь киленнең милке дип саналган, һәм кияү гаебе белән гаилә таркалган очракта, ул хатынына шул мәһәр бәясендә мал-мөлкәт, акча бирергә тиеш булган. (Килен үз теләге белән киткән очракта гына мәһәрнең калган өлеше түләнмәгән.) Егет бай һәм кыздан күпкә өлкәнрәк булса, мәһәрнең күләме арткан. Толларга һәм аерылып кайткан хатыннарга караганда, кызларга, әлбәттә, мәһәрне күбрәк сораганнар. «Кызның хакы – утыз, кире кайтса – тугыз», дигән мәкаль дә шул хакта сөйли.

Кызның бирнәсе күп вакыт шушы мәһәргә килгән акчага әзерләнгән. Аның күләменең зурлыгы турында беркайчан да сүз кузгатылмаган. Бирнә сандыгына, гадәттә, урын-җир әйберләре, сөлге-тастымаллар, чаршау, тәрәзә челтәрләре, кашагалар салганнар. Аларны күп вакыт кияүгә чыгарга әзерләнүче кыз үз куллары белән тукыган, чиккән, теккән, бәйләгән... Кайвакыт: «Кызыбызның бирнә сандыгы әзер түгел әле», – дип, аның әти-әнисе яучыны кире дә борган. Кияүгә чыкканда бирнә сандыгы яртылаш буш булу хурлык саналган.

Аклашу

Ниһаять, яучы «риза» дигән соңгы сүзне алып кайта. Бу шатлыклы хәбәр вәгъдә бүләкләре алмашыну белән ныгытыла. Гадәттә, кыз ягыннан, вәгъдә бүләге итеп, кызның үзе чигеп, үзе сугып яки тегеп әзерләгән сөлге-ашъяулык, намазлык кебек бирәр кул эше бирелгән: бирнә сандыгының кайбер әйберләре кияү йортына җибәрелгән. Егет ягы аңа каршы акча биргән. Бу бүләк алышу йоласы татарлар яши торган төрле төбәкләрдә төрлечә аталган: «ак», «ак алыштыру», «ак апкайту», «аклашу», «аклык», «ак чыгару»... Лаешта вәгъдә бүләген егет йортына кызның ике якын туганы илткән. Аларны зурлап каршы алганнар, ике көн кунак иткәннәр. Ашъяулык, сөлге, тастар кебек бүләкләрне яучы аша гына тапшыру да булган. Әстерхан татарлары сөлге һәм яулык биргәннәр, баерак гаиләләр бүләккә түбәтәй, билбау, халат, көмеш йөзек тә куйганнар. Кайбер якларда егет йортына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган әйбер «билге» дип аталган. Билгегә ике сөлге, ике эскәтер бирелгән. Кояшлы матур көн сайлап, ике башкода билге алырга килгән. Кияү ягында аларның кайтасын туганнары көтеп калган. Башкодалар киләсе хәбәрне кыз ягына бирәр бала җиткергән. Хәбәрне әти-әниле бала китерсә, яшьләрнең дә балалары әти-әниле булып үсәр, дигәннәр. Самара татарларында вәгъдә бүләген алырга кыз йортына кияү үзе генә яки берничә дусты белән бергә килгән. Аларны зур кунаклар итеп кабул иткәннәр, бүләккә күлмәк, ыштан, оекбаш, бияләй биргәннәр. Егетләр дә буш калмаган: һәр бүләк өчен акча салган.

Шуннан соң кәләш өендә инде ике якның әти-әниләре очраша. Чәй табыны янында никах, туй чыгымнарын ничек күтәрү турындагы сөйләшүләр башлана. Казан татарла-

Кыз димләргә килгән башкодага, гәрчә ул бер теләмәгән кешедән килсә дә, дорфа, тупас җавап бирмәгәннәр, хәтерләрен калдырмаганнар.

рында аклашуга егет ягы бүләккә – акча, мишәрләр азык-төлек (ит, бал, май, чәй, он) алып килгән.

Оренбург өлкәсенең кайбер районнарында аклашу йоласы кияү ягында узган. Анда якын туганнардан бишалты гаилә дә катнашкан. Аларның һәрберсе сандыкларга салып ипи, бәлеш, ит, май кебек ризыклар алып килгән. Кәләшнең әти-әнисен егет ягы өйләренә барып алган. Олылар белән бергә килгән бала-чагага кызның әнисе кулъяулык, түбәтәй кебек бүләкләр өләшкән. Кияү өендә кунаклар җырлашып утырганнар, гармунда, кубызда, курайда уйнаганнар.

Күп төбәкләрдә шул ук көнне яшьләргә никах та укылган һәм аларга бергә яшәргә рөхсәт ителгән. Пермь татарларында исә аклашу йоласыннан соң ук, әле никах укылмаса да, яшьләр уртак гаилә тормышын башлаган.

Сөлге котлау

Бу йола күбрәк Казан татарларына хас. Егетнең әнисе туган-тумачалары белән бергә кыз йортына килгән, һәм булачак килене белән танышкан. Һәр ике як та бер-берсенә бүләкләр бирешкән. Ә кайбер төбәкләрдә, килешүләр тәмамлангач, кияүнең кием үлчәмнәрен алу өчен, егет йортына кызның ике якын кыз туганы яки хатыны белән абыйсы килгән. Аларга егетнең иске берәр күлмәген, ыштанын биргәннәр, әмма озатканчы башта ике көн кунак иткәннәр. Берничә көннән шул ук кешеләр кияүгә, аның туганнарына инде әзер кием-салым белән егет йортына кабат әйләнеп килгән. Кәләшнең туганнары яки дус кызлары алар артыннан күчтәнәчкә тәм-томнар да пешереп җибәргән. Кунакларны бу юлы да зурлап каршы алганнар һәм кундырмыйча җибәрмәгәннәр.

Пермь татарларында, кыз ярәшелгәннән соң, кияү үзенең дуслары белән аларга чәйгә килеп йөри башлаган. Яшьләрнең бер-берсе белән танышу чоры булган бу, әмма күп вакыт егет кызны күрмәгән дә диярлек. Кияү, үзенә ясаган чәйне яртылаш эчкән дә, кәләшенә дип алып килгән бүләген – колак алкасын яки йөзекне шунда салган. Чынаякны исә чаршау артында яки башка бүлмәдә дус кызлары белән утыручы кәләшкә биргәннәр. Ул чәйне эчеп бетергән һәм бүләкне алган. Бу да булачак парларны якынайта дип саналган.

Сергач татарларында да кияү белән кәләшнең беренче очрашуы, күрешүе кыз өендә булган. Егет аларга үзенең ир туганнары, якын дуслары белән килгән. Юлда килешли алар мылтыктан атканнар, гармунда уйнаганнар – тирә-юньне шаулап торган. Шул ук кичне кәләшнең бер туганы кияүне, кабат барып, үзләренә алып кайткан. 10–15 минутка гына йортның ишекләре бикләнгән, тәрәзләр ябылган – яшьләр аулакта икәү генә калганнар: берничә сүз алышырга өлгергәннәр. Аннан кияүне яңадан озатып куйганнар.

Бирнә кисү

Бу йола Тәтеш якларында очраган. Никахка кадәр киленнең сигез-ун туганын егет йортына чакырып, табын янында аларга мәһәргә бирергә килешенгән бүләкләрне күрсәткәннәр, туйга әзерлекнең барышы турында сөйләгәннәр. Ә кайбер төбәкләрдә, киресенчә, кызның әти-әнисе егет ягындагы яшьрәк хатын-кызларны чәйгә алган. Кунаклар булачак киленгә әллә никадәр бүләкләр белән килгәннәр: күлмәк, кашемир яулык, ике төрле шәл, камзул, тун, әллә ничә төрле аяк киеме – читек, галуш, итек... Булачак кода белән кодагыйга, киленнең башка туганнарына да бүләкләр әзерләнгән. Конфет-прәннек кебек тәм-томнар да булган күчтәнәчләр арасында. Кыз ягы да сынатмаган: кунакларны табыннар корып каршы алган, һәрберсенә бүләккә яулык тараткан. Аннан кызның да шуның кадәр үк якын туганы егет ягына кунакка киткән. Алар да буш кул белән йөрмәгән: булачак кияүгә, аның әти-әнисенә, туганнарына бүләкләр белән барганнар: күлмәк, ыштан, түбәтәй, чиккән аяк чолгавы, сөлге, эскәтер, намазлык, чәй, шикәр... Хуҗалар шулай ук аларның һәрберсенә яулык әзерләп куйган.

Мишәрләр олырак яшьтәге ир-атларны гына чәйгә алганнар. Һәр кунак үзе белән түгәрәк бер ипи алып килгән. Мондый табында кунакларны колмактан әзерләнгән эчемлек – буза белән сыйлаганнар. Самара өлкәсендә ир-атларны кәләш ягыннан китерелгән күчтәнәчләр белән дүрт көн рәттән кунак иткәннәр.

Сембер губернасында, Вятка өяздында булачак киленнең кайда, нинди йортта яшәячәген күрсәтү, хуҗалык белән таныштыру йоласы да булган. Моның өчен егет йортына кызның әти-әнисен, аның туганнарын чакырганнар.

Бирнә озату

Туй алдыннан үтәлә торган иң мөһим йолаларның берсе. Кызның бирнәсен алырга, атлар җигеп, дус егетләре белән кияү үзе килгән. Аларны һәрвакыттагыча мул табыннар белән каршы алганнар. Калганнар чәй эчкән арада, егетләрнең берсе авыл буйлап йөреп, кызның туганнарын туйга дәшкән. Бирнә салынган сандыкны кияүгә болай гына бирмәгәннәр: кызның энекәше аңа менеп утырган да җизнәсе белән озак кына сатулашкан. Аннан, җигүле атларга төялеп, кияү йортына юнәлгәннәр. Инде анда бирнәне сатып алу башланган. Барысы да уен-көлке белән узган. Кыз ягы кыйммәтрәк сатарга, ә егет ягы ничек тә түләмичә генә алырга тырышкан. Бигрәк тә комганны саклаганнар: аны урлату оят саналган. Ахырда, бирнә өчен түләнгән көмеш һәм бакыр акчаларны салып, сандыкны өйгә кертконнәр.

■ Фото: Касыйм татарларының туй фотосы. XIX йөз ахыры – XX йөз башы «Татарика» китабы чыганакларыннан файдаланылды.



« Кыз сорау йоласы бүген ничек узуын видеодан карау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Видео: Фәгыйлә Шакирова.

УРАЗА



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

?Намаз укымаган кешенең уразасы кабул буламы?

– Намаз укымаган кеше дә ураза тота ала. Намаз ул аерым гыйбадәт, ураза – аерым. Намаз укымаган өчен бер гөнаһ язылса, ураза өчен тагын бер гөнаһ өстәлә. Ике урынына бер генә гөнаһлы булу күпкә әйбәтрәк лабаса. Менә шуның өчен дә, намаз укымасаң да, уразаны тотарга ярый гына түгел, хәтта тотарга тиешсең.

Бүген күпләр, әле намазга басарга өлгермәсә дә, Рамазан аенда ураза тотарга тырыша. Өчәрөчәр көн, берәр атна булса да. Алар бу көннәрдә хәрам ризыктан ерак тора – тәмәке тартмый, исерткеч эчемлекләр кулланмый, гайбәт сөйләүдән, начар эш-гамәлләрдән тыела. Һәм иң мөһиме – уразадан соң да бу гадәтләргә кире әйләнеп кайтмаска тырыша. Димәк, калебләрендә исламга мәхәббәт уянып, башка фарыз гамәлләрне кылу ихтималы да арта диген сүз. Чираттагы адымнары – намаз булуы да ихтимал.

Әйе, намаз укуны да кичектерергә ярамый. Күпләр: «Әле вакыт җитмәгән, азрак эштән бушагач, лаеклы ялга чыккач укырмын намазны», – дип уйлый. Чынлап торып яшәргә дә өлгермичә, намазсыз, уразасыз киткән таныш-белешләрегезне искә төшерегез мондый чакта... Безгә күпме гомер бүлеп бирелгәнен беребез дә белми, шуңа күрә хәерле гамәлләр кылганда гел ашыгырга кирәк. Үзеңне мөселман дип санасаң, күңелеңдә Аллаһы Тәгаләгә ышану хисе булса, уразаны да тулысынча тотарга, биш вакыт намазны да калдырмыйча үтәргә тырышырга кирәк. Тоткан уразагыз хакына намазга юлны да ачарга, якынайтырга мөмкин.

?Уразага ниятне телләп әйтү мәҗбүриме, күңелеңнән генә ниятләү җитмиме?

– Уразага ниятне тел белән әйтү мәҗбүри түгел. Иң мөһиме – күңел белән әйтү. Мәсәлән, иртән сәхәр ашарга торсаң, бу үзе үк ният була инде.

Бөтен Рамазан аена бер ният кылып булмый, һәрбер көне өчен аерым ният кылырга кирәк. «Иртәгә ураза тотам», – дип, күңелдән булса да ниятне кичтән дә әйтергә ярый. Бу очракта иртә белән сәхәргә тормыйча гына да уразага керергә мөмкин.

Әгәр инде тел белән әйтергә теләсәң, аның үзенең сүзләре бар. Кыска гына ул. Гадәттә, сәхәр ашап бетергәч, уразага ният кылабыз: «Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгърибиь хаалисан лилләәһи тәгаалаә». Татарча гына әйтсәң дә була: «Илаһи ният кылдым, Раббым, үзеңнең ризалыгың өчен Рамазан уразасын тотмакка, таң беленгәннән алып кояш баеганга кадәр». Кемгәдер шулай җайлы икән, бу сүзләрне русча гына әйтә ала. Гарәпчә әйтү мәҗбүри түгел. Шулай ук күңелдән генә дә кабатларга мөмкин.

Сүз уңаеннан, авыз ачканнан соң укылачак доганы да искә төшерик: «Аллаһүммә ләкә сумтү үә бикә әәмәнтү үә галәйкә тәүәккәлтү үә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффаару мә каддәмтү үә мә әххәртү». Аны да үз сүзләрең белән, татарча гына да әйтергә мөмкин: «Йә Раббым, үзеңнең ризалыгың өчен генә ураза тоттым, тоткан уразаларымны кабул кыл. Йә Раббым, биргән нигъмәтләрең белән авыз ачам, кылган гөнаһларымны гафу кыл».

?Үзе ураза тотмаган кешегә ифтар ашы үткәрүнең савабы бармы?

– Ураза тотмаган кешегә ифтар ашы уздыру шулай ук рөхсәт ителә. Үзе ураза тотмаса да, ураза тоткан кешеләргә авыз ачтырып, ул савап алырга мөмкин. Пәйгамбәребез (с.г.с.): «Кем бер кешене авыз ачтырса, аңа ул кешенең тоткан уразасы савабы язылыр. Теге кешенең дә ураза савабы кимемәс», – диде. Ләкин шулай булса да, аның үзенең уразасы барыбер тотылмаган санала – гөнаһ дип языла. Кемдер уразага, әйтик, авыру сәбәпле керә алмый икән, аны башка вакытта – көннәр кыскарак булганда тота ала. Алай да булдыра алмаса, фәкыйрьләрне җыеп ашатырга мөмкин. Бу инде, үз чиратында, уразаның фидиясен түләү, ягъни аны каплау була.

Кеше үзе ураза тотмаса да, аңа авыз ачтырган җиргә барырга ярыймы соң? Андый очраклар да булырга мөмкин бит. Әйе, барырга ярый. Әмма чакырган кеше, әлбәттә, беренче чиратта ураза тоткан кешеләрне чакырырга тиеш. Әгәр дә инде туганнар, таныш-белешләр арасында андыйлар күп түгел икән, ул вакытта ураза тотмаганнарны да чакырырга мөмкин. Барыбер ул очракта да табынга абыстай яки мулла килә, Коръән укыла: мәҗлескә җыелучылар нәсыйхәт ишетә, вәгазь тыңлый. Һәм бу аларга дингә кереп китәргә сәбәпче булырга да мөмкин. Әмма инде мәҗлесне оештыручы бу очракта авыз ачтыру савабын алмый, аңа дингә өндәгәне, туганлык җепләрен ныгытканы өчен генә савап өстәлә. Менә ни өчен ифтарга ураза тоткан кешеләрне чакыру хәерлерәк.

Рамазан уразасы безнең өммәткә генә бирелгән олуг нигъмәттер. Аллаһы Тәгалә: «Мөхәммәд өммәтләре ураза тотып, ирееннәре агарып, ифтар вакытында кулларын догага күтәргәндә күк белән җир арасындагы пәрдә күтәрелә. Аларның догаларын кабул итәм, чөнки алар бу мизгелдә минем белән пәрдәсез сөйләшәләр», – дигән.

PRESSA




















ТВОРЧЕСКАЯ ГРУППА

«КӨМЕШ БАРС»

ООО «Көмеш барс», 420015,
Казан, М. Горький ур., 24,
корп. 3; 4. Тел.: 8-927-415-26-68.





ДИСБЕ АНАСЫ

– Таш белән эшләүгә хатын-кыз түгел, ир-ат та чыдамый. Андый һөнәрчеләр республикада да юк. Авыр, катлаулы эш бит... Тузаны турында әйтмим дә. Ә Зөһрә тотынды да эшли дә башлады! Башына яулыгын бәйли, маскасын кия дә, җыр тыңлый-тыңлый, онытылып китеп эшли. Тәмен табып! Мин аңа әле һаман да шаккатам. Ярата, күрәсең... Вадим Анатольевич якын итеп хатынына карый.

Ташлар дөньясы... Юк, аны ярату шунда ук килми әле. Ул бит авыл кызы, Кама Тамагы районының Ишем авылында үскән: аяк астындагы һәр ташка ире кебек байлык дип карарга өйрәнмәгән. Алар фатирына аяк басу белән, исәнләшүгә, булачак кайнатасы – Казан дәүләт университетының геология факультеты доценты Анатолий Михайлович Ануфриев гомер буе җыйган коллекциясе турында сөйләүгә күчә. Нинди таш, кайдан табылган, ничәнче елда... Кунакка килгән саен шулай! Тик ничек: «Миңа боларның барысы да бертөсле күренә – кызыгын тапмыйм», – диясең?! 3 яшеннән әтисе белән экспедициягә йөри башлаган, тормышын ташлардан башка күз алдына да китермәгән Вадимы аларны елмаеп кына күзәтә: Зөһрәсенең ташларга барыбер гашыйк булачагын шул вакытта ук белгәндер ул.

– Нинди кеше таш җыя диләр әле? Язын, ташулар китеп, җир кардан ачылуга Идел буена таш җыярга китә иде ул минем. Хәер, хәзер дә шулай... Көннәр буе яр буйлап йөри, рюкзагына таш асып, аркасын авырттырып... Җыйса гына ярый, ташларны сатып та ала бит әле! Уралдан, Саянскидан... Берәр кисәген унбишәр меңгә! Ә өйдә аяк астында гел таш та таш кына. Зуррак кисәкләр, кечкенәрәкләр... Гаражда исә тонналап таш ята!

Иренең бу мавыгуын кабул итәргә вакыт кирәк була. Кабул итәргә һәм яратырга: ташларга тузан оясы дип карамаска, кулга алуга аларны таный башларга, җылысын тоярга... Әмма моннан алда Вадим Ануфриевның бу өлкәдә республикада бердәнбер белгеч икәнен аңлау килә. Теләсә кайсы таш кисәгенә тотынып, аңардан нәрсә тели, шуны ясый ала ул. Ташны аның кебек тоючылар, уя, юна, шомарта белүчеләр республикада башка юк! 14 яшендә станок артына басып таш эшкәртә башлаган кеше ул. Бу – мавыгу гына да түгел, тормыш рәвеше. Бүгенге көндә Татарстанда иң бай ташлар коллекциясенең берсе – аңарда. Республикада узучы чемпионатларның җиңүчеләре өчен кубокларны, «Созвездие-Йолдызлык» фестивале, «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясе лауреатларына бирелүче «Алтын йолдыз» сыннарын нәкъ менә Вадим Анатольевич ясый.

Сүзне дисбе дип башлаган идем бит.

Иренең уң кулына әйләнүен шулай итеп сизми дә кала Зөһрә ханым. Сыннарның рәсемен башта компьютер графикасында ясау аның вазыйфасына әйләнә. Иң соңыннан һәрберсен чистартып, сөртеп чыгу да хатын-кыз кулын сорый. Үз йорты белән торган кешедә башка мәшәкать тә җитәрлек: бакча, оныклар... Эштән китәргә карар итә ул: ире җыйган ташларны эшкәртеп бетерергә бер гомер генә җитмәячәк. Ул бу мөһим адымны ясауга, пандемия башлана һәм дәүләт заказлары килүдән туктый. Аның каравы, буш вакыт арта. Һәм, ниһаять, күңелдә йөргән хыялларны чынга ашырырга мөмкинлек туа...

Татарстанда «Ел һөнәрчесе» бәйгесе узуын ишетеп, мәдәният министрлыгына дисбеләрен илтеп тапшыра Зөһрә Бәширова (Ануфриева). Ике атнадан: «Эшләрегезне килеп алыгыз, узмадыгыз», – дип шалтыраталар. «Кытайдан кайтарткан ташлардан җыйган дисбенең бу бәйгегә ни катнашы бар?!» – дигәннәр икән... Министрлык вәкилләрен үзләренә мастер-класска чакырып кайта Зөһрә. Алар һөнәрче түгелме?! Килсеннәр, күрсеннәр...

Дисбенең бер төймәсен ясауда, беләсезме, ничә станок катнаша? Унбиш! (Һәр станогын үз куллары белән тудырган Вадим Анатольевич, хатыны дисбеләр ясарга керешкәч, тагын эшкә тотына: остаханәдә станоклар тагын арта.) Ташны башта тасма-тасма итеп, аннан шакмак-шакмак итеп кисәсе, түгәрәклисе, шомартасы, ялтыратасы, тишәсе, җыясы... Шомартып ялтырату этабыннан кала, барысын да күзәтергә, карап торырга мөмкин, ә полировкалау исә – сер: һәр останың үз технологиясе, аның белән, гадәттә, бүлешмиләр.

Ниһаять, дисбенең төймәсе әзер – Зөһрә аңа тишек тишәргә утыра. «Ультратавыш ярдәмендә эшли торган станокка ир-атның күбесе якын да килә алмый – тавышына түзмиләр», – ди алар.

– Мин көнгә илле төймә дә тишә алам, siксәнне дә, – ди Зөһрә. – Ташның төп-төгәл уртасын табарга компьютерлар курсын тәмамлавым булыша. Озак тишәмме? Барысы да ташның катылыгына, ныклыгына бәйле. Нефриттан ясалган төймәне тишәргә, мәсәлән, ун минут кирәк. Ул – эшкәртү өчен иң авыр таш. Аңардан соң, әйтик, лазуритны тишү уен гына. Әмма миңа иң ошаган таш барыбер нефрит. Аның матурлыгын берни белән дә чагыштырып булмый. Нефрит кашлы алкаларымны таксам, бөтен кешенең күзе шуңарда гына була... Күреп торасыз, каяндыр кайткан төймәләрдән җыймыйбыз дисбене, хәтта фурнитурасына кадәр үзебез ясыйбыз.

Кайнатам соңгы елларда ташларның кешегә тәэсире белән бик нык кызыксынды. Нефрит менә хатын-кызларга гаилә җылысын сакларга булыша, үз-үзенә ышанычы булмаган ир-атларга көч өсти. Обсидиан әңгәмәдәшеңнең начар энергиясен сиңа уздырмый... Әмма ташның кайсысыннан гына ясасаң да, психологлар белеп әйтә – дисбе тынычландыру сәләтенә ия. Мин үзем инде утыз елга якын рульдә: бөкегә эләктемме, кул дисбене эзли башлый. Дисбе тарту йөрәк тибешенә, сулышка йогынты ясый, эчке әгъзаларның эшчәнлеген яхшырта, артрит, артроз вакытында файдалы, тәмәке ташларга теләүчеләргә дә ярдәм итә диләр.

Лазурит, лабрадор, чароит, змеевик, аметист, мәрмәр оникс... Ташның ниндиеннән телисез, шундый дисбене сайлап аласыз. (Соңгысы үзебездә – Татарстанның Кама Тамагы, Спас районнарында табылган таш!) Киләчәк буыннарга калдырырлык кадерле ядкарь булачак бу затлы дисбе... Бертөрле тәсбих сүзләреннән икенчесенә күчүне белдергән зур төймә бар дисбедә. Аңа «дисбе анасы», диләр. Дисбегә яңа сулыш өргән Зөһрә ханымга да шулай дип әйтеп буладыр.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Язучы, шагыйрә, журналист, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы матбугат үзәгенең алыштыргысыз белгече... Депутатлар даирәсендә аны Чулпан Шәриповна дип йөртәләр. Журналист язмаларында ул – Чулпан Әхмәтова. Шигърият сөючеләр Таңчулпан дип белә үзен... Иҗаты да – нәфис-нәзберек-нечкә: чулпан-йолдыз кебек балкып, күңелләрне яктыртып тора...
Бүген ул Таңчулпан булып, сезне-безне якты, ягымлы, язлы, яратулы шигырьләре белән сөендерер.


ТАҢЧУЛПАН

МИНЕМ ҖИРДӘН ҮТЕП БАРЫШЫМ...

Альбом шигыре

Әй сөйләп тә карадылар шулай:
Үзе чибәр, үзе ирдә түгел,
Бөек мөнбәрләргә менәм дисә,
Мондыйларга берни киртә түгел.
Бер елмайса – куйган максатына
Ирешергә яшел юллар ачык,
Шөһрәт, уңыш, зиннәт килә булыр
Кара төндә юрган читен ачып.
Әй сөйләп тә карадылар шулай –
Мир авызы төпсез чиләк бит ул.
Күңел чибәрлеген күрүчеләр,
Кызганыч ки, бик тә сирәк бит ул...
Сер бирмәскә соңгы көчем җыеп
Елмайганда тешләп иреннәрне,
Баш куярга иңнәр эзләдем мин –
Аллам булыр адәм күренмәде.
Туфрак булам, – дидем – юлларында,
Аңлый белсә җанны карашымнан,
Яклый алса керсез күңелемне
Гайбәтләрнең тирән ярасыннан...
Мине яклар иңнәр табылмады,
Мин сагынган мине сагынмады,
Үзен «бөек» иткән вак җаннарга,
Ялынмадым һәм дә табынмадым.
Сүзләр һаман ишетелә килеп:
– Нәрсә көтә, һаман ирдә түгел...
Гади генә ласә – сезгә яраганнар,
Миңа, миңа һич тә тиңнәр түгел.

Шушымы инде яшәү –
Таң ата да, кич була,
Гади генә, тыныч кына
Гомер уза да уза...
Яшен булып яшьнәлмәгән,
Йолдызлар чүпләнмәгән,
Сирәк кенә карыйм Күккә,
Хәтта Ай үпкәләгән.
Шушымы инде яшәү?!

* * *

Төшләремә Яшьлек керә...
Көлә-көлә,
Елый-елый уянам да
Уйлап куям:
Олгаела, димәк...

Төш

Төшемдә мин яшьлегемне күрдем –
Биреп йөрим, имеш, имтиханнар.
Һәм бер караш эзәрлекли мине,
Абына язып йөрим шул караштан.
Ул таныш та, таныш түгел дә күк...
Кайнар учка кунган кар күк җаным:
Янам, пешәм, тамчы булып тамам,
Гакылым җуеп аңа сарыламын...
Уяндым да –
Иренемдә тәме,
Чәчләремә сеңгән кебек исе...
Яңа гына!..
Әле яңа гына!..
Керфегемнән кайнар тамчы төште.
Ул таныш та, таныш түгел дә күк...
Җанда сагыш. Сагыш түгел дә күк...

* * *

Шул ук төш –
Мин аның
Төш икәнен беләм:
Үтә газиз ямьле ишегалды,
Яшел бәрхет чирәм.
Көмешсыман тавык үлән чемчи,
Чеп-чеп чебиләре,
Ишетелә әбиемнең шунда
Медер-медер нидер сөйләнгәне.
Җилләр кочып китә, иркәләнәм,
Миңа шундый рәхәт!
Калыр идем бәрхет чирәмнәрдә,
Туялмаган ләззәт.
Әбиемнән шундый тәмле булып
Җиләк исе килә,
Сөялләнгән кулкайлары белән
Йомшак итеп сөя.

Уяндыра...
Уйлар уйландыра.
Гамьсез үткәнемә
Кайта алам икән, мин бәхетле –
Булсын төштә генә!

Төш икәнен беләм,
Шуңа елыйм.
Азга, төштә генә
Вакытларны чигеп кайтам әле,
Кайтам үткәнемә!

* * *

Әгәр үтсә яратуың,
Сүнсә җанда янган утың,
Үтенәмен, кит син миннән –
Күзләреңдә ялган күрмәм.
Сыкрап янган иреннәрне
Син үпмәсәң, буран үбәр.
Миннән киткән эзләреңне
Карлар күмәр,
Карлар күмәр...
Әгәр үтсә яратуың,
Мин ризамын югалтуга –
Кирәк түгел ялган назлар,
Ялган сөю, ялган язлар...
Бер елармын. Керфегемнән
Тамчы-тамчы сөю тамар.
Синең сурәт бер истәлек,
Ядкарь булып җанда калыр.
Әгәр үтсә яратуың,
Сагынуың, табынуың.
Үтенәмен, кит син миннән –
Күзләреңдә ялган күрмәм.
Акланма да, юатма да.
Ялгыз түгел – җырларым бар.
Саклый алмаган мәхәббәт
Булып минем җанымда кал.
Әгәр үтсә яратуың...

* * *

Тәрәз читеннән үрелеп
Бер йолдыз карый –
Яшь сылу кыз ай нурында
Чәчләрен тарый.
Ефәктәй чәчләр үбәләр
Нәфис иңнәрен,
Чит күзләрдән каплый тәннең
«Кайбер җирләрен».
Ай нурында коена кыз,
Алтын тарагы,
Төн-пәрдә дә яшерәлми
Татлы газабын.
Мөлдерәмә хисләренең
Тулышкан мәле,
Уйларының гөнаһланган,
Сугышкан мәле.
Чәч тарый кыз, очкынлана
Толым очлары,
Таш йөрәкне эретерлек
Кайнар кочагы.
Күз тимәсен чәчләреңә,
Пәрдәләрне яп,
Таң ата бит озакламый,
Йокла, кызый, ят.
Төшләреңдә килер ярың,
Ап-ак ат менеп,
Бик татлы да, газаплы да
Яшәве сөеп.

Мәңгелекнең йөрәге

Бала табу йорты.
Төнне ярып
Аваз салды яңа туган сабый.
Шул сабыйның тәүге авазыннан
Тулган шатлык минем җанга сыймый,
Саркып чыга тозлы яшь булып.
Мин дә көтәм,
Керфек какмый көтәм
Сабыемның туар мизгелен.
Карынымда яткан нәниемнең
Һәрбер хәрәкәте сизелә.
И дулаган була...
Ашкынадыр
Якты дөнья йөзен күрергә –
Хыялымда
Ак бантиклы кызым
Яшел болын буйлап йөгерә.
И сабыем минем,
Бу дөньяга
Бәхетле җан булып тусаңчы.
Мәхәббәтле булып, өебезнең
Кояшы һәм Ае булсаңчы.
И сабыем минем,
Көтелгәнем,
Ходаемның олуг бүләге.
Яңа туган сабый елавында
икән Мәңгелекнең йөрәге.

Үтеп барышым

Керфегемнән ап-ак карлар үбә,
Күзләремдә көзләр сагышы,
Бертуктаусыз аккан болыт булып
Минем Җирдән үтеп барышым...

Бәйләнәсем килә кыяларга
Билбау итеп саба җилләрен.
Әллә ничек, һич сиздерми генә
Уза икән гомер дигәнең...

Ышык эзлим – килеп кунар өчен,
Тояр өчен кемдер җылысын...
Бер өн килә бәгыремне өтеп
«Тукталырга инде, инде соң...»

Китү

Яшь бер шагыйрь
Тәүге шигырендә
Искә алган урам чаты иде.
Мин бик озак гөлләр арасында
Сиңа диеп чәчәк сайлап йөрдем.
Синең туган көнең...
Суга куйган
Ак чәчәкләр миңа иш булды.
Аяк тавышлары килгән саен
Өметләнеп көттек кич буе.
Син кайтмадың –
Башын иде гөлләр,
Кашык тими табын суынды.
Тәнгә генә түгел, җанга үтте
Кышкы төннең зәһәр суыгы.
Яшь бер шагыйрь тәүге шигырендә
Искә алган шул ук урам чаты.
Иртә әле. Тәмле төшләр күреп
Йоклый булыр чәчәк саткан хатын.
Ә мин көтәм тәүге трамвайны...
Еракларда ямалыр күк ярам.
Кичә синең туган көнең иде –
Әйтелмәгән сүзләр бик күп калган...
Трамвай килде –
Инде китеп барам...

Юк

Күптән инде үксеп елаган юк,
Күптән инде шашып көлгән юк...
Нияз Акмал

Сагынып идем, сагыныр кешесе юк,
Елар идем, күздә яше юк.
Эч пошканда башын сыйпар идем,
Янымда хет эт йә мәче юк.
Язар идем, язу карасы юк,
Кара тапсам, башта фикер юк.
«Чукынсын!» дип кулым селтәр идем,
Шул шигырьдән башка килер юк.
Җырлар идем, моңлы тавышым юк,
Аңа карап моңсыз чагым юк.
Урам тулы кеше арасында
Күңел өчен таныш чалым юк.
Шагыйрь сыман: күптән яраткан юк,
Табынган юк, шашып көлгән юк...
Һәм ни гаҗәп – башка күзләрдә дә
Җанга якын хисләр күргән юк.
Кая бара дөнья?
Белгән юк...

Кыргый чәчәк

Мин бит чәчәк идем,
Кырда үскән чәчәк.
Җилләр мине назлап үпкән иде.
Кыргый чәчәк чорым
Хәзер – хәтер.
Гамьсез үткән инде.
Үткән инде...
Син дә сокландың ла,
Шашып сөйдең.
Чәчләремне җилгә тараттың.
Өзеп алып суга куйдың мине
Һәм шиңгәнче генә яраттың.
Мин хәзер дә чәчәк,
Кипкән чәчәк.
Төшләремдә кайтам аланыма.
Рәнҗү дә юк сиңа, үпкәм дә юк.
Күңелемдә бары
Яра гына...



Ләлә Сабирова (Гыймадиева) – повесть-хикәяләре гадилеге, ихласлыгы, җылылыгы белән җәлеп иткән язучы ул. Укытучы, балалар газетасы редакторы, журналист булып эшләгән еллары язучының иҗатында да чагыла. Аның «Бер уч борчак», «Рәхәткә чыдап кара», «Мин аңа бәхет телим», «Чуфут-кале малайлары», «Кызарган алмалар» китапларын укучылар аеруча яратып кабул итте. Балалар дөньясын, хатын-кыз психологиясен оста итеп ачып биргән әсәрләре тормышчан, җиңел тел белән язылган, рәхәтләнеп укыйсың.
Бу көннәрдә 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Ләлә ханымны гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез!



Ләлә САБИРОВА

ӨЛГЕРӘСЕ ИДЕ!..

(Хикәя)

Аркамда – биштәр, аякларымда – кроссовкалар, өстемдәге курткам да пикникка чыкканда кия торган, яңасы никтер тәнемә ябышмый. Көзге каршында сәгатьләр буе чәч ясап азапланучыларны, гомумән, аңламыйм. Бейсболкамны башыма ябыштырып куям да чыгып чабам. Минем арттан тутыкай гел сукранып кала:

– Бала-чага түгел бит инде син! Дәрәҗәле институтта укыйсың! Өстенә юк дип уйларлар, бигрәк адәм көлдереп йөрисең! Ул чәчләреңне дә матурлабрак йөртергә була торгандыр. Кыз бала бит син!

Мин аның белән бәхәскә кереп тормыйм, дөресрәге, җавап та бирмим. Ничә әйттем инде, ничек телим, шулай киенәм, миндә берәүнең дә эше юк, дип. Аңламый. «Ошамаса, кайтып кит үз өеңә, монда сине берәү дә тотмый», – дип әйтәсе килә дә, әлегә түзәм...

– Сылу!

Кем дәшкәнен белергә дип артыма борылмадым, адымнарымны гына акрынайттым. Бер Тимур гына исемемне шулай кыскартып әйтә, «Таңсылу» дияргә иренә, күрәсең. Әтине дә әйтер идем, тапкан кушарга исем. Тулысынча әйтсәң, җайсыз, татарча ипи-тозлык кына белгәннәр бөтенләй азапланып бетә. Сылу дисәң... Нинди сылу инде мин! Юри мыскыл итәләр дип уйларсың.

Тимур белән кызык кына очраштык без. Төнге клубта минем белән бер төркемдә укыган кыз белән биегән бу. Анысына егет ошамаган, күрәсең, үзен «Таңсылу» дип таныштырган, телефон номерын да минекен әйткән. Шалтырата бер көнне, «очрашыйк әле», ди. Кем икәнен сорап тормадым, киттем. Тегенең гаҗәпләнүен күрсәң! Ачкан авызын да ябалмый карап тора. «Син чынлап та Сылумы?» – ди. «Ник, сылу кебек түгелмени?» – дим. Нишләсен, кафега да алып керде, озатып та куйды. Кабат кайчан очрашачагыбызны сорамады, билгеле. Шулай да берничә тапкыр очраклы гына юлларыбыз кисеште. Анда да сөйләшүебез гел теге кыз тирәсендә барды.

– Тәки әйтмәде үзенең кем икәнен, ә? Каян эзләргә икән соң аны миңа?

– Ник эзлисең аны? Синең аңа кирәк түгеллегеңне аңламадыңмыни?

– Бәлки, шаярткандыр да, хәзер үкенәдер...

– Андый кеше үкенә белми инде ул!

Бүген дә шул кызны сорашырмы дисәм, юк икән. Болай гына дәшкән, юк-барны гына сөйләшеп алдык. Юкса аның өчен төркемебездәге егерме кыздан минем телефон номерын кем биргәнен белешеп йөри алмыйм инде.

Тимурга минемише кызлар кирәк түгел дә түгел. Ул чибәрлеге, ул өстенә кигән киемнәре... Артист булса, гел уңай геройлар гына бирерләр иде аңа уйнарга. Теге кыз ник шулай шаярткан-

дыр. Мин булсаммы?! Хәер, бу турыда аңа үлгәндә дә сиздерәсем юк.

Бүген «очрашулар көне», ахры. Дәресләр бетүгә, институт ишек төбендә әти көтеп тора иде. Мин аның белән салкын гына исәнләштем.

– Берәр нәрсә кирәк түгелдер ич?

– Синнән нәрсә кирәк булсын инде миңа, кызым! Менә, әз булса да, бераз акча алып килдем. Бусы – тәм-том...

Акчасын да, пакетын да алдым, тик исем китмәгән кыяфәт чыгардым. Янәсе, синең ярдәмнән башка да тормышым гөрләп бара!

– Берәр уенчык салырга да онытмадыңмы? Син бит мине сабый чагымда ташлап киттең, уенчык уйнар чакта...

– Кызым...

Хәзер тагын аклана башлый инде. Күзләре дә дымланачак... Яратмыйм сытык кешеләрне, андыйларга җәлләп түгел, нәфрәтләнеп карыйм.

Әти турында сүз чыкса, тутыкай гел аны яклый.

– Әниең вафатыннан соң күпме ел яшәде бит ул син дип кенә! Яше бара, берзаман син дә кияүгә чыгып китәрсең, олыгайган көнендә ялгыз калсынмыни ул? – ди. Күңелем аның белән килешә дә кебек, тик әтинең үзен күрүгә, эчемдә тагын бураннар уйнап ала. Мин дип торса, ташлап чыгып китмәс иде әле.

Тутыкай дигәнем – әтинең бертуган апасы, озак еллар ялгызы яшәгән, әти, икенче хатынга өйләнеп, йорттан чыгып китәргә ниятләгәч, минем янга күчеп килде.

Кайтырга Сәвия белән бергә чыктык. Ул да безнең якта тора, әти белән сөйләшеп бетергәнне көтеп тора икән.

– Ник алай коры кыланасың аның белән? – дип аптырый Сәвия. – Сине сагынып килгән бит ул!

Мин аңа күзләремнең агы белән генә карап алам. Нәрсә аңлыйсың соң син, янәсе.

– Менә минем әтием булса иде әле, елга бер күрешсәк тә риза булыр идем!

Мин аны аңларга тырышып та карамыйм, сүзсез атлыйм. Аерылышканда да кул болгап кына саубуллашам. Тормышыма тыкшынганнарны яратмыйм мин. Андыйлар ни әйтсә, шуның киресен эшлисем килә башлый.

Икенче көнне урынымнан тора алмадым. Гәүдәмнең сул ягы үтереп сызлый, укшыта-укшыта башым авырта иде. Тутыкайны көч-хәл белән дәшеп китердем. Ул әллә ни сорашып маташмады, шундук «Ашыгыч ярдәм» чакыртты. Табибларга да хәлемне үзе аңлатты:

– Йөрәге тумыштан чирле аның. Тагын кайчан кабатланыр дип котым очып көтә идем...

Аның тавышы әллә каян, кое төбеннән килгән шикелле ишетелә. Аннары ул хастаханәдә кирәге чыгачак әйберләремне җыеп төйнәде, табибларга мине машинага утыртырга булышты.

...Мин яткан палатада бөтенесе дә – операция көтеп ятучылар. Кайсы үзен тыныч тотарга тырыша, кайсы качып кына елый. Икенче берәүләр үзләрен кая куярга белмәгәндәй туктаусыз йөреп тора.

Башымда бер уй да юк. Ни күрәсе булса да, миннән тормый. Күңелем белән күптән әзер инде мин моңа. Кайчан да булса килергә тиеш иде ул көн: йә, ниһаять, куркып яшәүдән туктыйсың, йә... Бармы мин дөньяда, юкмы, аннан берни үзгәрми. Шуңа күрә күзләремне түшәмгә текәп ятам да ятам. Берни сорашмыйм да, сөйләшмим дә.

Көндезге йокы сәгате узуга, палатама халык агыла башлады.

Иң беренче булып әти килде.

– Бар да яхшы булыр, кызым, борчылма, – ди. Бүтән чак булса, тупас итеп җавап кайтарыр идем. Бүген миңа аннан да якынрак кеше юк. Әти дә, әни дә булды бит ул минем өчен. Үзе мине юата, ә үзенең күзләрендә – яшь.

– Син дә борчылма, – дим, миңа таба сузган кулыннан сыйпыйм. Озак утырды, чыгып, табиблар белән дә сөйләшеп керде.

Әти артыннан тутыкай килде. Җылы аш китергән. Тамагымнан ризык үтми бит әле минем, апам-җаным. Тик алай дип кычкырып әйтмәдем, азапланып булса да, бер-ике кашык йоттым. Минем өчен тырышкан бит инде ул.

Сәвия дә килде, аның артыннан бер төркемдә укыган башка иптәшләр дә күренде.

– Имтиханнар өчен борчылма, булышырбыз, – диләр. Имтихан кайгысы түгел әле миндә. Аны биреп торасы булырмы, юкмы... Шулай да рәхмәт дигән кебек елмайдым. Елмаюым бик күңелсез килеп чыкты, билгеле.

Иң соңыннан Тимур күренде. Бер бәйләм чәчәк тоткан. Исәр! Үләмме-каламмы дип яткан кешегә нинди чәчәк ди инде!

– Сылу!

– Нинди сылу инде мин, Тимур!

– Сылулыгыңны үзең аңламыйсың шул син!

– Ник монда килеп вакытыңны әрәм итеп йөрисең? Теге кызны эзлисе урында!

– Таптым бит мин аны! Дәресрәге, әле монда килгәндә автобуста очраштык.

– Озата китәргә иде...

– Китәргә иде дә... Булмады инде.

– Ник?

– Синең янга ашыктым бит.

– Һе... Кабат югалтудан курыкмыйсыңмы?

– Курыкмыйм. Әллә ни зур югалту булмас ул.

Тимурның елмаюы да матур. Сак кына чәчләремнән сыйпаганда рәхәтләнеп күзләремне йомып яттым.

Ул киткәч, башымда берәм-берәм төрле уйлар баш калкыта башлады. Миңа барыбер дигән булам да... Үз-үземне алдарга тырышуым гына ул.

Иртәгә операция өстәлenә ятасы. Палата табибы, әллә ничә керә, хәлемне сорап чыкты. «Син әзерме?» – ди. «Ие»,– дип, иягемне каккан булдым. Үзем күңелем белән бер тамчы да әзер түгел. Күпме кешене борчуга салам бит мин! Шуларны юатырга өлгерә алмам дип куркам...



ТАЯНЫР ТАЛЛАРЫҢ БУЛМАСА...

(Хикәя)

Дамирә аны беренче күрүендә үк ошатмады. Җете итеп бизәнгән... Сарыга манган чәчләрен тузганак башына охшатып тараган... Изүе ачык... Нәрсә, ул монда эшләргә түгел, кәттә кияү эзләргә кайткан мәллә?

– Менә документларым. Ясирә исемле мин. Яраса, бүгеннән үк тотыныр идем.

Кызый үзен бик иркен тота. Ни әйтсәң дә, шәһәрнеке шул. Хәер, авылныкылар да ким куймый хәзер.

– Ашыкма... гыз. Училищены быел бетердегезме? Ник нәкъ менә безнең авылны сайладыгыз?

Ясирә яктырып китте. Йөзе генә түгел, күзләре дә елмайды. «Ошарга тырыша... Миңа ошап кына эш бетми әле. Халык ничек кабул итәр...» Дамирә эченнән генә көйсезләнә, үзен ничек тотарга белми аптырый иде.

– Алай олылап дәшмәгез инде. Син дип кенә әйтегез. Сезнең янда мин бала-чага гына бит. – Кызыйның бу сүзләренә Дамирәнең тагын ачуы килде. Мин яшь, син карт диюме? – Училищены, әйе, яңа бетердем. Ә авылыгызны... мин сайламадым, районга килгәч, үзләре тәкъдим итте. Авыл җирендә эшләп карыйсым килде. Сезнең кулдаш фельдшер декрет ялына киткән икән бит, иеме?

Дамирә аңа төксе генә карап куйды.

– Китсә, соңыннан кире килер бит ул. Аннары кая барырсың соң?

– Аннары күз күрер! Миңа беренче чирканчык алырга кирәк. Практика үтәргә.

Алай икән! Авыруларны карыйсы урында, Дамирә аны эшкә өйрәтеп утырырга тиеш икән!

– Иртәгә... Иртәгә башларсың, бүген түгел. Фатирыңа кайтып ял ит... – Дамирә шунда туктап калырга теләгән иде, үзен тыеп тора алмады. – Түлке эшкә болай килмә инде! Юынып, чәчләреңне җыеп, изүеңне каплабрак кил! Кеше белән эшлисе бит.

Ясирә күңелсез генә саубуллашып чыгып китте. Бу апа аны эшкә генә түгел, авыл культурасына да өйрәтәчәк икән әле...

Ул фатир төшкән әби киң күңеллегә охшаган. Теле тәмле, йөзе ачык.

– Монда килгән кеше кире китми. Син дә шушында кияүгә чыгып калырсың әле, әйтте диярсең, – дип такылдый.

Ясирә аңа көлеп карый. Ярый да дими, каршы да дәшми.

– Дамирә белән борчагың пешәр күкме соң? Үзенең кулы шифалы аның. Тик менә холкы гына... корырак. Шуңа күрә кияүгә чыгалмый картаеп бара бугай инде.

– Шулайракка охшаган шул...

Ярар, ни булса, шул. Ясирә үзе дә төшеп калганнардан түгел. Шулай да вакытында медицина институтына керә алмады. Барыбер үземнекен итәм дип, фельдшерлыкка укып чыкты. Шәһәрдә калу мөмкинлеге дә бар иде, Ясирә өчен алай кызык түгел, аның чын тормыш белән очрашасы килде. Үзен күрсәтәсе. Киләчәктә барыбер врач буласы килеше лә ул!

Тик менә Дамирә апасының гына аны чирләреннән зарланып килүчеләргә бик якын җибәрәсе килми. Беренче көнне үк кулына озын исемлек тоттырды.

– Быел диспансеризация үтәргә тиешле кешеләр болар. Һәркайсының өенә барып, кул куйдырып чыгарга кирәк. Берсекөнгә аларны район шифаханәсенә алып барып кайтырсың.

Һе... Шундый заманда... Телефоннан гына булмый микәнни? Юри кылана инде бу...

Дамирә кызның кара коелган йөзен күрмәмешкә салышты.

Автобусны да идарәдән үзе юллап, Ясирә атна буе яңа авылдашлары белән район шифаханәсен таптады. Берсе көйсезләнә, икенчесе юк-бар белән аптырата... Шуларны тыңлар өчен кайттымы ул монда? Шулай да түзәргә кирәк, түзәргә... Үзен күрсәтеп бетергәнче түзәргә...

Ул эш беткән иде, иртән медпунктка килеп керүенә Дамирә аңа тагын бер кәгазь сузды:

– Дарулар исемлеге. Аптекадан алып кайтасы. Районга баручы машиналар була, үзең белеш.

Ясирәнең бөтенләй төсе качты. Нәрсә инде бу, йә? Йомышчы малай шикелле...

Икенче көнне сүзен ныклап әйтергә дип килгән иде, Дамирә үзе дәшеп кертте.

– Хәзер синең белән сменалап эшли башлыйбыз. Минем телефонны язып ал, срочно хәл итәсе булса, шалтырат. Башбаштакланма! Бусы – уколга йөрүчеләр исемлеге. Дарулары менә монда. Бутый күрмә! Монысында – өйләрендә дәваланучылар. Алары янына үзең барып йөрисе булыр.

Ясирә җиңел сулады. Икәү бергә тыкшынып йөрмәгәч, әйбәт инде ул! Юкса Дамирә янәшәсендә булганда гел җаны кыршылып торган шикелле аның.


Рәсем: Наталья Васильева

Бу авыл апалары кызык икән – медпунктка килгән бере Ясирәнең кем икәнлеген энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыга. Ата-аналарың кем? Ник безнең авылга киләсе иттең? Йөргән егетең бармы? Монда озак эшләргә уйлыйсыңмы?

Ясирә эчтән генә ярсый, шулай да үзен иркен тотарга тырыша. Күзләре җылынмаса да, иреннәре елмая. Үзен шулай гел контрольдә тотарга тырыша. Ныклап кереп китсен әле эшенә, аннары башкачарак та сөйләшә алыр. Юкса кергән бере башта Дамирәне сорый.

Атна-ун көн узмагандыр, кибет тирәсендә дә, көтү куганда да халыкның телендә Ясирә исеме булды.

– Бигрәк ачык чырайлы бала, күз тимәсен...

– Кулы җиңел, уколны бик ипле сала, «әһ» итәргә дә өлгермисең...

– Аңлатып бетермичә җибәрми, ул дару төймәләрен ничек-ничек кабасын кәгазьгә язып ук бирә...

Арада кире сүз кыстырып куючысы да табыла тагын:

– Һи-и, баштарак һәммәсе дә шулай аның. Ияләнә төшсен әле...

Боларның бөтенесен дә хуҗа әби эсселәтми-суытмый кызга ташып бара.

Ияләнә төшкәч, эше тагын да күбәйде Ясирәнең. Чирләре артык каты булып, медпунктка үзләре килә алмаганнар өйләренә дә Дамирәне түгел, аны чакырта башладылар. Дамирә моңа артык исе китмәгәндәй кыланды:

– Яра-ар, бигрәк яхшы. Миңа да бераз ял кирәктер. Юкса кич димиләр, төн димиләр...

Шулай да яшь фельдшерны бераз кисәтеп куярга да онытмады:

– Син, сеңел, әзрәк чамала инде... «Айт» дигән саен «тайт» дип торма. Эчләре пошканнан да чакырта кайбер әбиләр. Сөйләшеп утырасы килгәннәре дә. Бер өйрәтсәң, гел шуны куалар.

Шулайрак икәнен чамалый инде Ясирә. Тик берсенә дә каршы әйтми. Нәкъ менә аны атап чакырталар бит, ничек күңелең эремәсен! «Син» дип кенә торучылар барын белү бик рәхәт бит ул!

Көтелмәгән ике вакыйга кызның шома гына барган эшенә ук булып кадалды.

Бер көнне Дамирә килгән, Ясирә китеп өлгермәгән иде. Көч-хәл белән атлап, медпунктка бер ир килеп керде. Аны күргәч, кызый коелып ук төште:

– Абау, тагын ни булды инде, Рәшит абый? Рәтләнгән күк булган идең бит теге көннән соң?

– Һе... Уколдан соң төшә ул кан басымы... Аннары кабат күтәрелә... Аякларым бүрәнә күк булды, атлап та булмый... – Рәшит авыр сулый, телен көч-хәл белән әйләндерә иде.

Ясирә аңа чишенергә булышты, кушеткага ипләп яткырды.

– Ник үзегез өстерәлеп килдегез инде? Шушы хәлдә? – Ул аңа аптырап карады.

– Һаман саен сезне борчып та туйдым...

Рәшитнең чалбар балакларын күтәртеп карагач, «ах» иттеләр: ике аягы да куркыныч хәлгә килеп шешкән иде. Ю-ук, кан басымын төшереп кенә булмый монда, срочно районга илтергә кирәк... Дамирә, Ясирәне аның янында калдырып, машина белешергә чыгып чапты.



Икенче көнне ул кулдашын бик төксе каршылды.

– Мин сиңа әйттем бит инде, акыллым. Шикләнгән нәрсәләрең булса, минем белән киңәш, дидем. Кайчак кирәкмәгәнгә дә чыгып чабасың. Ә монда... Чак алып калдылар Рәшитне. Бөерләре шешкән булган. Ә син аны күпме укол белән «сыйлап» яшәткәнсең...

Ул һәр сүзенә басым ясый-ясый сөйли. Ясирәгә болай да исеме белән сирәк дәшә, «акыллым» дип, үзенең өстенлеген күрсәтүе инде. Кызый аны иреннәрен чәйни-чәйни тыңлап торды. Нишләргә тиеш иде соң ул? Рәшит абзые бит үзе гел «кан басымым» дип зарланды. Кайчан әйтергә кирәк Дамирәгә, кайчан юк икәнен каян белсен ул? Бигрәк әлләкем булып сөйләшә инде...

Ә бер кичне Ясирәне бер үсмернең әнисе өенә дәштереп алды.

– Мәктәптән көч-хәл кайтып егылды. Эче бора. Прәме тәгәрәп ята инде...

Ясирә, сумкасына авыртуны баса торган дару төймәләре тутырып, тизрәк чыгып йөгерде. Малай, дөрестән дә, караватына да менеп җитә алмаган, кәкрәеп бетеп идәндә ауный иде. Ясирә аны аркасына яткызырга азапланды.

– Кайсы җиреннән бора? Күңелең болганамы? Шулаймы? Мәктәптә нәрсә ашаган идең? Әйдә, башта укшып карыйбыз.

Икәүләшеп сәгатьләр буе азапландылар. Ясирә малайның авызына тегесен каптырды, монысын көчләп тыкты. Авыртуны баса торган уколлар кадады. Дамирәнең телефон номерын җыймакчы булып әллә ничә талпынды. Үзен җиңә алмады. Бераздан, ниһаять, малай тынычлана төште. Әнисе белән икәүләшеп караватына иплəп яткыргач, Ясирә иртән сугылырга вәгъдә итеп кайтып китте.

Тик аңа сугылырга туры килмәде – иртән малайның бик яман температурасы күтәрелгән, әнисе Дамирәне дәшеп китергән. Анысы, кызулап, малайны районга алып киткән.

Ясирә Дамирәнең җил-җил атлап кереп килүен тәрәзәдән күреп алды. Әһә, тагын нидер булган... Кызый «начальнигы»н урыныннан купмыйча гына каршы алса да, эчендә шартлап ярылырдай киеренкелек иде. Бер дә аның тәмсез сүзләрен ишетәсе килеп тормый шул...

– Башбаштакланма дигән сүзнең мәгънәсен аңламыйсың мәллә син?! Чүт харап итмәгәнсең бит малайны! Андый чакта синең түгел, минем дә кулымнан килми, шуңа күрә район хастаханәсе бар безнең, тәҗрибәле табиблар бар! Сукыр эчәгесе шартлаган булган, операцияне дүрт сәгать ясадылар. Кичә үк илткән булсак шунда! Нинди мин-минлек соң ул синдә?!

Дамирә дулады, дулады да чыгып китте. Ясирәнең күңеле генә айкалып калды.

Авылда хәбәр тиз тарала бит ул. Бу хәлдән соң Ясирәнең абруе төссезләнгән кук булды. Медпунктка аны түгел, күбрәк кабат Дамирәне сорап килә башладылар. Кызый эченнән генә янды, көйде.

Бер көнне районга дарулар алырга баргач, хастаханәгә сугылды. Баш табиб урынбасары – аның туганнан туган апасы, бу авылны да аңа ул тәкъдим иткән иде. Сөйләшеп киткәч, Ясирә сүзне юри Дамирәгә китереп чыгарды:

– Абау-у... Бигрәк дорфа инде. Ничек тоталардыр аны анда. Зарланмаган кеше юк. Шуңа күрә бөтенесе минем сменага эләгергә тырыша. Арыта, билгеле. Җитмәсә, җае килгән саен таларга гына тора, тегесен дөрес эшләмәгәнмен, монысын тегеләй иткәнмен...

Апасы аны күңелсез генә тыңлап торды.

– Килешеп эшләмәгәч әйбәт түгел инде ул. Ярар, бер очрашканда мин дә сүз катармын әле...

«Сүз каткан», күрәсең, Дамирә берничә көн сөйләшмичә йөрде. Сөйләшсен иде ул, хет әләкләгәнсең дип гаепләсен иде, Ясирә дә аңлатып бирер иде кеше белән алай эшләргә ярамаганын.

Ә бер кичне Дамирә кызның кесә телефонына шалтыратты. Тавышы хәлсез иде.

– Кереп чык әле минем янга. Авыртуны баса торган уколларның кайдалыгын беләсең, шуны да алып кил...

Алай... Авыру булып кылануы микән? Әллә чыннан да Ясирәнең кирәге чыктымы? «Айт» дигән саен «тайт» дип тормаскамы әллә? Үзе шулай өйрәтте ич!

Ачудан гына көйсезләнүе Ясирәнең. Нишләсен, әйткәч, бара инде. Ул капкадан кергәндә Дамирә баскыч төпләрендә утыра иде. Бер аягын әллә ничек җайсыз итеп сузып куйган. Сызлана бугай, аһылдап-аһылдап куя. Ясирәнең сорашуын көтмәде:

– Сындырдым, ахры. Сарай түбәсенә йомырка карарга менгән идем, баскыч черек булган...

Ясирә каушап төште. Мондый чакта нишлиләр соң әле? Хәзер, хәзер...

Дамирә аңа карамый да, үзенекен сөйли:

– Башта укол ясa. Аннары әнә, сарайда юка такта кисәкләре бар, бер озынрагын алып чык шуның.

Ясирәнең башы уйларлык дәрәҗәдә түгел, Дамирә ни әйтә, шуны эшләп тик йөри.

– Тукта, такта белән тире арасына менә, мә, бу чүпрәкне кыстырып калдыр, юкса шуып йөри ул. Бинтың бармы? Булмаса, кухня ягындагы аптечкадан ал. Ай, ай, ул җиренә алай нык кагылма, шок ясыйсың хәзер. Бинтны кысыбрак ура, курыкма!

Училищеда чакта бөтенесен өйрәткәннәр иде инде үзе, берсе дә хәтерендә калмаган Ясирәнең.

– Югалып калдың әле син. Андый чакта салкын канлырак булырга тырыш. Бүтәннәр янында дип әйтүем. Мин ярар инде... Куркуыңны сизмәсеннәр. Ярар, молодец, булдырдың. – Аның Ясирәне беренче мактавы. Әллә көлеп әйтүе микән? – Хәзер районга илтергә кирәк инде мине...

...Районны урап кайткач, бераз аптырап утырды Ясирә. Каушады. Озак төзәлер микән Дамирәнең аягы? Үзе генә ничек эшләр икән соң ул? Таянам дигән җиреннән куллары бушлыкка төшеп киткәндәй тойды ул бүген үзен.

12+

«КИТАП» ТЫҢЛА!

КИТАП МИЛЛИ радио

КАЗАН 98,6 FM



АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834

РЕКЛАМА



ОЛЫ ЮЛНЫҢ СИКӘЛТӘЛӘРЕ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН

Миңа әдипнең сөекле хатыны Өммегөлсем (Гөлсем) апа Мөхәммәдова белән утыз ел чамасы аралашкалап яшәргә туры килде. Ул Сәмәркандтан Казанга күчеп килгән чорда мин Татарстан Язучылар оешмасында эшли идем. Соңрак аның Галимҗан Ибраһимовның иҗади эшчәнлеген һәм гаилә тормышын чагылдырган өч документаль повестен китап рәвешенә китереп нәшер итүче мөхәррир дә мин булдым. («Эзләнүләр», ике повесть, 1987 ел; «Олы юл», 1994 ел.)



Фото: автор архивыннан

■ 1929 ел, Ялта. Әдипнең аяк очында – уллары Рөстәм, хатыны Өммегөлсем; уңда – Өммегөлсемнең сеңлесе Сөмбел. Сулда – әдипнең туганнан туганы Рәйхана белән ире Батыр Гозәеров һәм аларның баласы.

* * *

Галимҗан Ибраһимов 1887 елның мартында хәзерге Башкортстанның Солтанморат авылында туган. 11 яшендә аны әтисе Оренбургтагы «Вәлия» мәдрәсәсенә укырга алып килә – заманча белемле мулла итмәкче була. Нәкъ шул елда чит илдә укып кайткан Мөхәммәдвәли Хөсәенов «Вәлия»нең башлыгы итеп билгеләнә. Казан артындагы «Кышкар» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, ул берничә ел Гарәбстанда укыган. Атасы Гани бай – Оренбургның атаклы сәүдәгәре – шул төбәктә үз исәбенә яңача (җәдидчә) укытуга йөз тоткан берничә дистә мәктәп һәм мәдрәсә ачкан, җәй айларында укытучылар белемен күтәрү курсларын оештырган. Яшүсмер Галимҗан бу калага килеп укыган елларны татар әдәбиятының гөрләп үсеш алган чоры дияргә була. Шул елларда монда күренекле шагыйрьләр Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев актив иҗат итә. Мәдрәсә башлыгы Вәли Хөсәенов та шәһәргә кайтып төпләнү белән үк үз типографиясен булдыруга керешә, дини һәм гаилә тәрбиясенә йөз тоткан «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгарырга рөхсәт ала. Совет хакимияте чорында Вәли мулланың бу эшләре, фәкать дини юнәлештә дип, еш тәнкыйтьләнде. Галим Әбрар Кәримуллин хәбәр итүенчә, «Дин вә мәгыйшәт» басмаханәсендә 1918 елгача 104 китап нәшер ителә, шулардан кырыгы гына дини эчтәлекле була. Ул типографиядә күләмле әдәби һәм иҗтимагый эчтәлекле әсәрләр дә, татар, казакъ шагыйрьләренең аерым җыентыклары да басылган.

Галимҗан килеп укый башлаган елларда Оренбург, Казаннан кала, икенче бер әдәби үзәккә әверелә. Әдәбият сөючеләр арасында танылып өлгергән язучы Гаяз Исхакый да 1902 елда «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытырга килә. Шакирҗан агасы укыган ул мәдрәсәдә Галимҗан еш була. Ул Г. Исхакый белән дә аралаша. (Кайбер истәлекләрдә аларның аерылмас дуслар булуы турында әйтелә. Әмма совет хакимияте чорында «ак эмигрант» Гаяз белән Галимҗанны якынайтмаска тырышалар.) Г. Исхакый «Хөсәения»дә укыткан елларында «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) әсәрен иҗат итәчәк. Шул ук мәдрәсәдә укыткан Сәгыйть Рәмиев белән дә дуслашып китәчәк.

Атаклы мәдрәсәдә укып, ата-бабалары кебек абруйлы мулла буласы Галимҗанның олуг әдип булып китүе менә

шушы вакыйгаларга бәйле. Ә «Вәлия»нең элек бик абруйлы уку йорты булуы тарихи документларда теркәлгән. Анда казакъ иле хан-солтан балалары да белем алган.

1907 елда беренче әсәрен Казан матбугатында бастырып чыгару бәхетен татыган 20 яшьлек егет, ун ел үтмәстән, классик әдип дәрәҗәсенә ирешәчәк. Шул дәвернең иң яратып укылган әсәрләреннән саналган «Яшь йөрәкләр» романын бастырганда (1912 ел) аңа әле 25 яшь кенә була. Тагын ике елдан соң ул «Безнең көннәр» романын язып төгәлләячәк. Ләкин ул әсәрнең беренче бүлекләре матбугатта басыла башлауга, патша цензурасы аны тыя. Шул ук 1910 еллар башында Галимҗанның берничә хикәясе һәм тел, милләт мәсьәләсенә кагылышлы мәкаләләре бертуган Рәмиевләр нәшер иткән «Шура» журналы укучыларына да тәкъдим ителә. Аннары алар Рәмиевләрнең «Вакыт» нәшриятында аерым китаплар булып басылып чыгачак. «Казакъ кызы» романының беренче варианты да Рәмиевләр басмаханәсенә җибәрелә. Әмма кульязма 1911 елда Бубый мәдрәсәсе вакыйгасыннан соң тентүләр оештырылганда юк ителә. Әсәр 1924 елда дөнья күрәчәк.

Әдип шул елның көзендә Касыйм төбәге сәүдәгәрләре Максудовларның Киевта яшәүче бер гаиләсенең балаларын укытырга чакырыла. Аны анда барырга Каюм Мостакаев димли. Татарстан Милли архивының Фатих Кәримигә багышланган фондында саклanучы бер хатта әдипнең Киевтан Дәрдмәндкә тагын бер күләмле кульязма җибәрүе турында хәбәр бар.

1913 елның апрелендә бер революцион шаулы җыенда катнашкан студентлар белән бергә Галимҗан да кулга алына. Шунда әдипнең яңабаштан яза башлаган «Казакъ кызы» әсәренең бер өлеше дә юкка чыга.

1917 елгы революция вакыйгаларын Галимҗан Уфада каршы ала. «Галия» мәдрәсәсендә укыту белән бер үк вакытта, ул язучы Фатих Сәйфи-Казанлы белән бергә сул эсерлар рухындагы «Ирек» газетасын нәшер итә. Казанда һәм Мәскәүдә уздырылган татар милли җыеннарында актив катнаша. Ә бераздан Мулланур Вахитов белән бергә Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариатын җитәкли. Бердәм башкорт-татар милли автономиясен булдыруга кагылышлы җыелышларны төрле төбәкләрдә оештырып йөри.

Казанга кайткач, Галимҗан Ибраһимов иҗатта кайный. Элек язган «Безнең көннәр» романын тиз арада нәшер итә. Шул ук вакытта татар милли матбугатын торгызу эшенә дә җиң сызганып керешә: «Эшче» газетасын нәшер итүдә, «Мәгариф», «Безнең юл» журналларына нигез салуда актив катнаша. 1922 елда «Татарстан» газетасына эшкә билгеләнә. «Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте»н оештыручыларның берсе була. Әмма аның татар иҗтимагый фикерен үстерүгә керткән иң нәтиҗәле эшчәнлеге «Гыйльми үзәк»не җитәкләгән 1924–1927 елларга туры киләдер.

* * *

Менә шушындый киеренке иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлек алып бару нәтиҗәсендә аның шәхси тормышы беркадәр «аксый төшә» шикелле. 1915–1917 елларда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укытканда һәм аннан элгәрерәк аның гаилә корырга нияте булгандырмы, истәлекләрдә

Шушы ике-өч елда ул башкалар дистә еллар дәвамында да ирешә алмаган **эшләрне уңышлы башкарачак.**

бу хакта мәгълүмат бик аз. Шул елларда «Галия»дә мөгаллимәләр курсында укучы Кызылъяр сәүдәгәре кызы Хәдичә Фәтхуллина белән аралашканлыгы турында гына хәбәрләр бар. Ләкин ул кыз ил күләмендәге түнтәрешләр башланганчы ук укуын тәмамлап, туган ягына кайтып китә, кияүгә чыга. Г. Ибраһимов иҗатын һәм биографиясен барлаган Афзал Шамов: «Аны бер муллага кияүгә биргәннәр», – дип искә ала иде. 1935 елда әдип шул Хәдичәне Ялтага чакырып алачак. Ул кулга алынгач, Хәдичә янә Казакъстанга кайтып китәчәк. Ә соңгы өч-дүрт елын ул Казанда яшәде, 1967 елда вафат булды...

Себер якларында йөреп кайтканнан соң, әдип берара бер мөгаллимә белән яшәп ала. Ләкин ул ханым үзен бик иреклe тотарга яраткан. «Галимҗан аганың кырыс холкын, таләпчәнлеген кабул итә алмыйча, Уфага китеп барган», – дип әйтә иде Афзал ага.

1923 елда әдип Әстерханнан килгән Өммегөлсем Мөхәммәдованы очрата. Аңа гашыйк була. Шул танышудан соң озакламыйча алар рәсми рәвештә кавышачаклар. Әдип сөеп, яратып «Гөлсем балакай» дип эндәшә торган җәмәгате 1903 елның 19 сентябрендә туган. Аның атасы Давыт Мөхәммәдов Идел белән Каспий суларында балык аулау белән шөгыльләнүчеләрнең көймә-корабларын төзүче һәм төзекләндерүче эшмәкәр була. Әстерхан татарлары арасында ул хәйрия җәмгыятен ачуда, төрле-төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда танылган шәхес санала. Балаларын да шул әдәби-музыкаль кичәләргә алып баргалаган. Татар хатын-кызларыннан беренчеләрдән булып Петербургта рәсми музыкаль белем алуга омтылган Мәрьям Искәндәрованы Гөлсем апа еш искә ала иде. 1911 елда шәһәр күләмендә оештырылган концерттан соң ул җырчы Давытлар өендәге мәҗлестә дә катнаша. Шәһәргә килгән башка дәрәҗәле кунаклар да алар йортын читләтеп үтми. Сәгыйть Рәмиев тә шул шәһәрдә газета мөхәррире булганда алар өенең мансарда өлешендә яши. Габдулла Тукай да шәһәргә килгән беренче көннәрен Сәгыйть бүлмәсендә уздыра.

Башлангыч белемне татарча үзләштергәннән соң, Өммегөлсем шәһәр гимназиясендә русча укый. Укуын Казанда дәвам итәргә бик теләсә дә, илдә гражданнар сугышы барганга, башта ул хыялына ирешә алмый. Ике кыш татар мәктәбендә укыта. 1922 елда Казан университетының медицина факультетына укырга керә. «Казанга баручы пароходка утырганда бер кулымда – чемодан, икенчесендә камыштан үрелгән зур сумка иде», – дип искә ала ул. Шул сумкада ризыклары, яңарак укый башлаган «Безнең көннәр» романы һәм Галимҗан Ибраһимовка тапшырырга дип бирелгән хат була. Ул татар әдәбиятын, шул исәптән, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен дә даими рәвештә укыган. Университетта укый башлагач та әдипкә

Уртак эш бу ике җанны бер-берсенә тагын да якынайтачак. Гөлсем дә үзен иренә тиң итеп тоячак.



Өммегөлсем улы Рөстәм белән.

тапшырырга тиешле хат барлыгын онытмый. Ләкин фатирдан-фатирга күчү вакытында ул хат югала. Галимҗанның университет студентлары белән очрашуыннан соң, аңа әлеге хатны югалтуы турында сөйләргә мәҗбүр була. Беренче танышу менә шул үкенү вакыйгасыннан башлана. Ә язга табарак әлеге хат иясе Казанга килә. Гөлсемнең укуы белән кызыксына. Кыз аңа унбиш кеше бер салкын бүлмәдә яшәгәнлекләрен сөйли. Язгы имтиханнарны уңышлы тапшыра алырмынмы икән, дигән шөбһәсен белдерә. Танышы аңа Галимҗан белән киңәшергә кирәклеген әйтә. Әдипнең фатирына – Икенче Совет йортына алар икәү баралар. Шул рәвешле икенче танышу, өчәүләп чәй эчү вакыйгасы була.

Җәйге каникул башланыр алдыннан Өммегөлсем белән иптәш кызы, тулай торактан китеп, эшкә урнашырга ниятлиләр. Гимназияне уңышлы тәмамлаганлыгын истә тотып, хезмәт биржасында аңа бик җаваплы эш тәкъдим итәләр. «Халык Комиссариаты Советына төрле рәсми документларны русчадан татарчага тәрҗемә итүче кирәк икән. Сынау шарты белән эшкә алырга булдылар. Юридик бүлек мөдире Ротенберг эш бирде. Күрше бүлмәдә утыручы тәрҗемәче белән таныштырды. Кирәккәндә ярдәм итәрсең, диде аңа. Беренче тәҗрибәләремне рецензент Мөхетдин Корбангалиев тә хуплады», – дип искә ала Гөлсем апа «Олы юл» китабында.

Бу чорда алар Галимҗан абыйсы белән еш очрашкалыйлар. Җәйнең көзгә таба авышкан бер көнендә Галимҗан алар яшәгән бүлмәгә килә. Бераз сөйләшеп утыргач та кәгазь алып: «Син минем хатыным булырга ризамы?» – дип яза һәм шуны Гөлсемгә тоттыра. Гөлсем аптырап кала. Бераз тып-тын гына утыргач, әдип: «Җавапны өч көн көтәм», – ди дә чыгып ук китә. Өммегөлсем әдипнең бу тәкъдиме турында ике якын дустына хәбәр итмичә булдыра алмый, билгеле. Иң якын ахирәте: «Ике арада мәхәббәт булмагач, мин бармас идем», – дип җавап бирә. Икенчесе – инде кияүдә булган Хәдичә исә: «Аңладым, мәхәббәт юк, фәкать үзара хөрмәт итешү генә бар, димәкче буласың... Ә Галимҗан агаң, Гөлсем, синнән олы булгач, үзеңне кадерләп, уч төбендә генә тотар. Син аны хөрмәт итәрсең, ә ул сине сөяр, иркәләр... Аның тәкъдимен кире какма!» – дип киңәш бирә. Өч көн үтеп китә. Ә Гөлсем ни дип җавап бирәсен дә белмичә аптырап йөргәндә, төштән соң Галимҗан пәйда була. «Әйдә, киттекме?» – ди. Урамда, кеше арасында аңлашу җиңелрәк булыр, дип, Гөлсем аңа иярә. Ә анда аларны шәп ат җигелгән затлы фаэтон көтә икән. Галимҗан агасы шәһәр урамнарын күрсәтергә тели, ахрысы, дип, кыз аның янәшәсенә менеп утыра. Атның елга порты тарафына атлыгып чабуын чамалагач, ул: «Без кая барабыз соң?» – дип сорый. Галимҗан исә, елмаеп: «Елга портына», – ди.

Шул китүдән алар Иделнең аргы ягына – Югары Ослан тарафына барып чыгачаклар. Якын араларга йөрүче кечкенә пароходка утыргач кына Галимҗан агасы аңа кая барасыларын әйтәчәк. «Җитәкчеләрең белән сөйләшеп, сиңа ике атналык ял алдым. Ул көннәрне без шушындагы ял йортында уздырачакбыз. Шул арада син минем үтенечкә җавап бирергә тиешсең», – ди. Башта ун көнләп алар монда абыйлы-сеңелле кебек йөриячәкләр. Кошлар сайрашкан мондый урманнар, киң, иркен болын-басулар Өммегелсемгә бик тә ошый. Идел буенда су чәчрәтеп коенулар да үзгә кебегрәк тоела аңа. Шулай аралаша-аралаша, Өммегөлсем күңелендә дә ияләшү, якынлык хисләре туачак. Үзеннән күпкә өлкән кеше белән яшәргә ул ризалык бирү фикеренә киләчәк. Һәм ике атна ял иткәннән соң, алар Казанга инде яңа кавышкан пар булып кайтачак. Шул көннәрдән башлап Галимҗан аңа һәрчак диярлек, яратып, «Гөлсем балакай», дип кенә дәшәчәк. Хәзерге Кремль урамындагы 21 нче йортның икенче катындагы 33 нче озынча тар бүлмәдә бергә яши башлаячаклар.

Иң элек аларның ничек яшәвен, тормыш-көнкүрешен күреп китәргә килүче – Гөлсемнең апасы Гайшә була. Гөлсем аны Әстерханнан үзе чакырып китерә. Элек ялгызак ир яшәгән шыксызрак бүлмәне икәүләп тәртипкә китерәләр. Түрле урында, шул исәптән, тәрәзә төбендә дә өелеп торган китапларны ике шкафка тутыралар. Апасы киткәч кенә әдип аңа: «Ул китапларның һәр төркеме аерым темага багышланган иде. Киләчәктә алай эшләмә», – диячәк.

Гайшә китүгә, Казанга әдипнең абыйсы Шакирҗан килеп төшә. Бертуганнарның урындыкка кара-каршы утырып, тезгә-тез куешып сәгатьләр дәвамында сөйләшүләре Гөлсем өчен бик кызык тоела... Шакирҗан ерак бер авылда укыта икән. Киемнәренең шактый таушалган икәнлеген күргәч тә, Гөлсем: «Аңа яңа костюм, аяк киеме алып бирәседер, бәлки», – дип сүз башлый, Галимҗан аңа каршы килми, якын арада басылып чыгасы «Казакъ кызы» романы өчен керәсе керемне дә истә тотып, «балакае»ның тәкъдимен хуплый. «Алай ук кирәкмәс иде», дигәләсә дә, Шакирҗан сөенеп кайтып китә. Ул китеп бераз торгач та,

тагын бер кунакны – Галимҗанның энесе Габделхәкимне кабул итә яшь гаилә. Әдипнең Хәким энесе аларның төп йортында – Солтанморат авылында яши икән. Бу юлы да ике бертуган, тезгә-тез куешып, авылның барлык кешеләрен искә төшереп кич утырачаклар. Кунакларның Казанга килеп китүе яшьләрне тагын да якынайта.

Галимҗан шул көздә үк бик зур эшкә тотына. 1905 елгы революция вакыйгаларында татарларның ни дәрәҗәдә катнашуын чагылдырган китап язарга алынган була. Ул китап 1925 елда ике телдә басылачак икән. Аны басмага әзерләшүдә Гөлсем дә актив катнаша. Башта ул рус телендә чыккан китап, брошюраларны туплаша, әдип билгеләгән кайбер битләрне тәрҗемә дә итешә. Беркөн эшнең барышы белән танышырга килгән обком кешесе С. Гафуров: «Бу хезмәтнең русчага тәрҗемәсен кемгә бирик икән?» – дип сорый әдиптән. «Миңа бирегез», – ди Гөлсем, тыйнак кына. Галимҗан җәмәгатен хуплый. «Ул Халык Комиссариаты идарәсендә дә тәрҗемәче иде бит, эшне белә, – ди. – Гөлсем башлам өлешен эшләсен. Ул текстны рецензентларга бирербез. Алар хупласа – эшен дәвам итәр», – дип куя әдип. Татар һәм рус телендәге бу китаплар 1925 елда Мәскәүдә нәшер ителәчәк.

1924 елның көзендә аларга хәзерге Мөштәри урамындагы 33 нче йортның беренче катында берничә бүлмәдән торган фатир бирергә булалар. Өстәге катта да Мәгариф комиссариатында эшләүче бер татар гаиләсе урнашкан була. Ибраһимовлар гаиләсе монда ике ел ярым чамасы гомер итәчәк. Гөлсем апа анда узган чорны иң бәхетле айларыбыз булды, дип искә ала. Ул укудан кайтып ашапэчкәч тә, алар парлап әдипнең чираттагы эшенә тотына торган булалар. «Тирән тамырлар» романының кульъязмасын, башка шул чор хезмәтләрен бергә төгәлләп чыгачаклар. «Ул язган каралама вариантны укып чыгып, акка күчерә идем», – дип искә ала иде Гөлсем апа. Шунда яшәгәндә, 1926 елның 5 ноябрендә аларның көтеп алган уллары Рөстәм туа. Дөрес, ул туганда әтисе өйдә булмый. Яңа күчкән фатирларының бер бүлмәсендә яшәгән, өй эшләрен башкарырга ялланган Феня исемле хатын белән алар икәү генә калган булалар.

– Улыбыз туганда Галимҗан өйдә юк иде. Шул елда Бакуда узган, гарәп әлифбасын алыштыруга багышланган җыенда ул андый үзгәрешне кабул итмәүчеләрнең берсе була бит. Шуннан соң кайбер җитәкче оешмаларда аңа карата мөнәсәбәт кискен үзгәрә. Моны Галимҗан бик авыр кичерде. Бала туар алдыннан гына дәваланырга китәсе булды. Бу хәлеңдә сине дә алып бара алмыйм, дип гафу үтенде, – дип искә алган иде Гөлсем апа.

Улы тууны әдипкә дуслары хәбәр итә. Ул тиз арада юлга чыга. Кайткач та көненә берничә мәртәбә бала бишеге янында сокланып карап торучан була. «Башының формасы минеке, борыны да минекенә охшый бугай. Ә күзләре синеке – зурлар, күк төсендәләр...» – дип кабатларга яраткан ул. Ләкин мондый бәхетле көннәр озакка бармый шул. Тиздән аның үпкәсендә кан какрулы яман чир булганлыгы ачыклана. Яңа елның бер аен әдип университет клиникасында дәваланып үткәрә. Аннан чыккач та ятагыннан тора алмыйча атналар буе дәвалана.

1927 елның башыннан өстәге фатирдагы күршеләрендә яшәгән булачак галимә Җамал апа Вәҗиева истәлекләренә дә тукталыйк. Ул фатир хуҗабикәсенең әнисе әдип өйдә юк чакта күршесе Гөлсем белән бик аралашкан була. Галимҗан авыргагда да аларга еш кереп йөри, Гөлсемгә булыша. Җамал апа яза: «Галимҗан мин пешергән кесәлне ярата, дип, кайбер көнне ул миннән кесәл төшертә иде. Галимҗан абый үз бүлмәсендә урыныннан тормыйча ята. Икенче бүлмәдәге бала бишеге аңа күренеп тора иде. Гөлсем апаның 8–9 яшьлек сеңлесе дә шул бишек тирәсендә чуала. Вакыт-вакыт ул кызчык баланы күтәрергә үрелсә, Галимҗан абый шундук: «Күтәрмә, балакай, егылырсың», – дип кисәтер иде».

Шул чорның танылган докторы Әбүбәкер Терегуловның авыру әдип янына көн саен диярлек килүен Җамал апа да, башкалар да искә ала.

Табиблар никадәр көч куйсалар да, әдипнең хәле яхшырмый. Татарстан хөкүмәте аны Кырымга – Ялтага дәваланырга җибәрергә карар кыла. «Бер кулга – баланы, икенчесенә көн дә кирәкле кием-салымны алып, фатирны бикләдек тә ерак юлга кузгалдык. Хәл белергә дип Казаннан, Уфадан язучылар еш килә иде. Ләкин дүрт яшь ярым тулмастан, 1931 елның 21 мартында Рөстәмебезнең кинәт вафат булуы барысына да чик куйды. Ул кинәт авырый башлагач, Ялта врачлары: «Салкын тигән, аякларын җылы суда тотыгыз, ике-өч көннән терелер», – дип юандырдылар. Бу фаҗиганең килеп чыгуына бүген дә үземне гаепле саныйм. Поликлиника врачларының сүзенә ышанып, Рөстәмнең дифтерия авыруыннан интеккәнен чамаламаганмын», – дигән иде Гөлсем апа. Шушы фаҗигале вакыйга берничә айдан соң Галимҗан белән Өммегөлсемнең аерылышуына китерәчәк. Өммегөлсем апа Ялтадан Симферопольгә күчеп китәргә мәҗбүр булачак. Элек Галимҗан янына килгәләп йөргән Кырым язучылары аны озакламыйча үз журналларына эшкә урнаштырачак. Үз әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүне үтенүчеләр дә шактый була.«Тормышым җиту генә иде. Әмма җан тынычлыгы булмады. Ә Галимҗанны кулга алу хәбәрен ишеткәч, бөтенләй авыруга сабыштым. Янында булсам, бәлки, андагы танышлар ярдәмендә аны коткарган булыр идем, дип, үз-үземне күпме битәрләдем. Аңа чаклы әле күңелдә: «Бәлки, кабат кушылу турында барып үтенәсе- дер», дигән хыялый уйлар да тугалый иде. Әйе, бик-бик үтенсәм, бәлки, ул мине гафу итәр, дигән уйлар еш бимазалады. Ул хыялый өмет тә юкка чыккач, үзенә димләп йөргән берәүгә кияүгә чыктым», – дигән иде Гөлсем апа Әмирхан Еники дә катнашкан бер әңгәмә вакытында.

Әмирхан ага – хаксызга гаепләнеп төрмәгә ябылган, шунда вафат булган олуг әдип Галимҗан Ибраһимовны Сталин вафатыннан соң аклауда актив катнашкан шәхес. Шул чордагы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гомәр ага Бәширов: «Иҗатын бик зурлаган Галимҗан агаңның эшен яңадан карауны үтенеп, ҮЗӘК Комитет исеменә хат язуга алынмассыңмы?» – ди аңа. Әмирхан ага ул тәкъдимне кабул итә, берничә айдан соң уңай җавап килә. 1955 елның 24 сентябрь карары белән Г. Ибраһимовның аклануы турында була ул.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Совет чорында югары уку йортларын тәмамлаган милләттәшләребезне илнең төрле төбәкләренә эшкә билгелиләр иде. Кызганыч, бер дә дөрес адым булмады.

Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаганнан соң мине юллама белән Горький шәһәренә эшкә җибәрделәр. Бик теләсәм дә, Татарстанда калу турындагы үтенечемне кире кактылар. Финанс министрлыгының контроль ревизия идарәсендә эшли башладым. Вазыйфам буенча районнарда еш булырга туры килде. Шатко районында булган бер хәлне онытасым юк. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, гадәттә, район советы башкарма комитеты утырышында чыгыш ясыйбыз. Нотык вакытында шул төбәкнең финанс бүлеге мөдире – милләттәшебез Наил Кадыйр улын мактап, төрле оешмаларны вакытында тикшереп, чарасын күрәләр дип әйттем. Шул вакыт район Советы башкарма комитеты рәисе: «Безнең Николай Константинович Наил Кадырович буламыни?» –дип гаҗәпләнеп куйды. Ә үзеннән: «Исемегезне ни сәбәпле үзгәрттегез?» – дип сорады. Наил әфәнде, уңайсызланып: «Русча әйтергә җиңелрәк булсын өчен генә үзгәрттем», – дип җаваплады.

Кайвакыт рус милләтендәгеләр: «Сезнең русча исемегез ничек?» – дип сорыйлар әле. Бервакыт фәннитикшеренү берләшмәсенә эшкә күчү турында уйладым. Аның генераль директоры, сөйләшеп һәм расланып кайтыр өчен, мине Мәскәүдәге идарә җитәкчесенә җибәрде. Әңгәмә вакытында аның урынбасары: «Сезнең русча исемегез ничек?» – дип сорады. Аңа җавап итеп:

– Анна Александровна, сез татар хатынына охшагансыз, татарча исемегез ничек? – дип сорагач, ул миңа:

– Әниемнең әбисе татар милләтеннән булган. Аннан бит һәрбер рус кешесендә казынып карасаң, аның тамырларында татарлык табарсың», – дигән әйтемне искә төшерде. Без дәррәү көлешеп алдык. Белемем һәм хезмәт юлым белән танышканнан соң, уңай нәтиҗә ясадылар. Шушы хезмәт урынында ун елдан артык эшләдем.

Совет чорында барлык төзелешләрдә дә эшчеләрнең шактый өлешен татарлар тәшкил итте. Кызганыч, аларда милләттәшләребезнең сафлыгы югалды: яңа җирләргә киткән егет-кызларыбыз башка милләт кешеләре белән никахлашып, тел, милли гореф-гадәтләр онытыла башлады...

Туган җирдән аерылу милләтебез өчен куркыныч икәнлеген һич кенә дә истән чыгармыйк. Кайда гына яшәсәк тә, татар булуыбыз белән горурланыйк! Татар сафлыгын югалтмыйк!

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ.
Казан шәһәре.

Калмия авыл китапханәсендә якташыбыз, авылдашыбыз, шигъри җанлы, нечкә күңелле, бөтен гомерен тырыш хезмәт белән яшәгән шагыйрә Нәкыя Динмөхәммәтова белән очрашу кичәсе үтте.

Җирле шагыйрьләр иҗатын белү, алар иҗаты белән авылдашларны таныштыру максатыннан оештырдык без бу кичәне. Очрашу кунакларның барысына да хуш килде дисәк тә, ялгыш булмас.

Нәкыя Шәехзадә кызы Динмөхәммәтова 1953 елда Пермь шәһәрендә дөньяга килә. Кызга 6 яшь тулгач, гаиләсе Минзәлә районы Калмия авылына бөтенләйгә күченеп кайта. Шул җәйдән кечкенә Нәкыя үзе дә табигать баласына әйләнә. «Балачак хатирәләре күңелемә уелып калды, – дип искә ала шагыйрә. – Күрше кызы Илгизә белән Кукчә якларыннан кайтып керми идек. 1 Май көнне Карга боткасына барулар, кача-поса Зәңгәр күлдә су керүләр... Аның суы кибүгә, күл төбеннән кузгалаклар чыга иде. Өйдән тоз эләктереп, кузгалак ашаулар, җиләктән кайтканда эсседән әлсерәп тәгәрмәч эзеннән яңгыр сулары ятып эчүләр... Балачакның кышларын да бик сагынып искә алам. Өшегән алма кимереп, тау



шуулар, карлы миләшләргә, чыршыларга карап сокланулар!»

Мәктәпне тәмамлагач, Чаллы шәһәренә төзелешкә китә Нәкыя апабыз. Ә каләмен... 65 яшьтә генә тибрәтә башлый! Хәзер инде Нәкыя апа иҗаттан башка яши дә алмыйдыр. Тәненең бөтен күзәнәкләре иҗат белән сулый да, уйлый да сыман.

Нәкыя Динмөхәммәтовага багышланган кичәдә бик күп матур шигырьләр укылды, ихлас теләкләр әйтелде. Авылыбызда яшәп иҗат итүче язучы Зөләйха Закирова үзенең киңәшләрен, теләкләрен җиткерде. Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, авылдашыбыз Хәния Гәрәева да үзенең уй-хисләре белән уртаклашты. Кичәбез кунаклары бик канәгать калды. Әнә шундый күңелле кичәләр, кызыклы чаралар оештырып, гөрләп яшибез авылда. Нәкыя апа Динмөхәммәтова кебек талантлы авылдашлар булуы – үзе бер бәхет ул.

Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА.
Минзәлә районы.

Фатыйх абый Солтанов – авылдашларымның тирән ихтирамын казанган, вакыт белән исәпләшмичә тырыш хезмәт куйган укытучыларымның берсе.

Ул безне барыбызны да диярлек спортчы да, рәссам да итте! Рәсем, сызым, хезмәт, физкультура дәресләрен укытты ул безгә. Төгәллеккә, чисталыкка зур игътибар бирә, таләп тә итә иде Фатыйх Асылгәрәевич. Рәсем дәресендә салмак адымнар белән килеп керер иде дә, өйгә бирелгән дәрес материалын тикшереп, һәрбер парта саен йөреп чыгар, дөрес, чиста, төгәл башкарган эшләрне үрнәк итеп күрсәтер иде. Рәсем төшерелгән биттәге хаталарыбызны бөтен нечкәлекләренә кадәр әйтеп аңлатыр да, төзәттерер дә иде...

Сызым дәресләре өчен такталарны да үзе кайтартты, дәрестән тыш түгәрәкләр оештырырга да вакыт таба иде. Агач тактада яндырып бизәк төшерү алымнарын бик кызыксынып өйрәнгәнем әле дә хәтердә калган. Ул эшләр: рәсем сәнгатеме, кул эшләреме – күргәзмәдә һәркемгә үрнәк булырлык иде! Үз эшенә бирелгән укытучыбызның, шуңадырмы, югары уку йортларын бетергән шәкертләренең күбесе – рәссам, архитектор булдылар.

Хезмәт кабинетын да, физкультура залын да Фатыйх Асылгәрәевич үзе башлап йөреп торгызуга ирешкән. Физкультура дәресләре дә, дружина сборлары да, җыелышлар да бездә шул залда үтә иде.
Кыш җитсә, чаңгыда йөрергә күлгә төшәбез. Аның дөрес алымнарын: таяк белән дә, таяксыз да башта үзе йөреп күрсәтә. Аннан безне шудыртып, хаталы адымнарыбызны искәртә, яхшы якларыбызны гел мактый иде. Мин әле хәзер дә кыш җитсә, чаңгыда йөрергә яратам, баскан саен, хөрмәтле укытучымны да, биргән дәресләрен дә сагынып искә төшерәм.

Фатыйх абый бик сабыр да, тыйнак та булган икән! Без аның орден-медальләр таккан гимнастеркасын 9 Май бәйрәмнәрендә генә күреп соклана идек. «Мәгариф музее»нда эшли башлагач, миңа аның үз кулы белән язылган, фронт юлларын тасвирлаган «Тормыш ядкаре» дигән истәлек язмалары белән якыннан танышырга туры килде. 18 яшендә Калинин фронтында – пулеметчы, аннан Пензада артиллерия училищесы курсанты булган ул. Сугыш кискенләшкәч, Фатыйх Солтановны 13 нче һава десанты бригадасына җибәрәләр. Карелия фронтының кеше аяк басмаган сазлыклары аша үткәндәге михнәтләре, ургып аккан Свирь елгасын кичүләре, Маннергейм линиясендәге ак финнар һәм фашистларны тар-мар итүләре турында да яза ул истәлекләрендә. Ниһаять, көтеп алган Җиңү көннәре якынлаша. Тик гвардия өлкән сержанты Фатыйх Солтанов илебезнең көнчыгышында япон милитаристларын тар-мар итеп, 1947 елның язында гына туган якларына кайту бәхетенә ирешә.

Җитмеш төрле һөнәр иясе иде Фатыйх Асылгәрәевич! Мәктәбебездә сантехник та, электрик та булырга туры килгән әле аңа. Озак еллар дәвамында «Уразман» колхозының партия оешмасын да җитәкли, үзе оста итеп плакатлар яза, рәсемсыннар ясый, өздереп тальянда уйный, ә аның тормыш иптәше Җуәйрә апа Вәлиева – башлангыч сыйныф укытучысы, моңлы җырчы иде. Тормышлары мәхәббәткә корылып, күпләргә үрнәк булырлык итеп гомер кичерде алар авылда. Игътибарны, ихтирамны казана белү җиңел ул, ә менә гомер буе саклап калу – авыррак. Алар икесе дә саклый белде. Үз балаларына да югары белем һәм тәрбия биреп, укытучылар династиясен дәвам иттеләр. Алар да – әти-әниләре кебек абруйлы, хөрмәтле укытучылар. Фатыйх Асылгәрәевичның «Тормыш ядкаре» истәлекләрен бер китап итеп бастырып чыгаруга ирештеләр. Балалары кульязмаларны, әтиләренең үз куллары белән ясалган картиналарын бик кадерләп, тормыш фатихасы итеп саклыйлар. Рәхмәт аларга!

Тәкъсимә ГАРИПОВА.
Азнакай шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



ЧИКНЕҢ ТЕГЕ ЯГЫНДА

Алсу ШАКИРОВА

60 нчы еллар... Тарихка бик матур вакыйгалар белән кереп калган чор ул. Юрий Гагаринның космоска очуы, яшьләрнең Высоцкий, Окуджава иҗаты белән кызыксынулары, яңарыш, үзгәрешләр... Ә менә СССР белән Кытай чигендә, Казакъстан белән кисешкән урынында барган дулкынлануларны илнең башка почмагында яшәүчеләр сизми дә калгандыр. Ул вакыйганың үзәгендә булганнар өчен 60 нчы еллар бик күп фаҗига, тетрәндергеч сынаулар алып килгән. Шундый кешеләрнең берсе – Руман апа Йосыпова. 1959 елда Кытайның Кургаз шәһәрендә туа ул. Әнисе Раушан апа белән әтисе Әсхәт абыйның тәүге мәхәббәт җимеше. Тиешле вакытын көтмичә якты дөньяга аваз салырга ашыга Руман. Алда үзен нинди тормыш көтәсен белсә, әни җылысына төренеп, әниле татлы хисләрен озаккарак сузарга тырышыр иде...

Руман апаның әтисе Әсхәт абый хәрби хезмәткә бурычлы кеше булгач, үзен кая җибәрсәләр, гаиләсе дә шунда барып урнаша. Әнә шулай яңа җирләр үзләштерергә китә алар. Табигать уңдырышка бик саран булып чыга бу якларда – тирә-якта коры дала гына.

– Әле бер әйбер чәчеп карыйбыз, әле икенчесен, дип сөйли иде әти. Комлы буран күтәрелә дә, орлыкларны себереп алып китә. Аннан теләсә кайсы җирдә теләсә нинди орлык шытып чыга икән...

Советлар Союзы белән Кытай арасында Бөек Ватан сугышыннан соң урнашкан дустанә мөнәсәбәтләр 60 нчы елларда шактый катлаулана. Ике дәүләт арасында чикнең каян үтәсен билгеләү мәсьәләсе моңа кадәр дә үзен сиздергән була инде. Ләкин тегендә-монда чыгып йөрүләргә чик сакчылары моңарчы бармак аша карый, тыюлар, катгый таләпләр куелмый.

– Халык Кытайдагы авыр тормышка, ачлыкка чыдый алмыйча күченә башлаган вакыт була ул. Кайчандыр Россия империясендәге авырлыклардан качып, Кытайга килеп төпләнгән, ә 50 нче елларда мондагы авыр тормыштан китәргә теләүчеләргә башта бернинди киртә булмаган – тыныч кына китеп котылганнар. Аларны соңыннан «бәхетлеләр» дип искә алалар иде. 60 нчы елларда чикне алай җиңел генә чыгып булмый инде. Кем ничек булдыра алган, шулай качкан... – ди Руман апа.

Руман апаның әби-бабасы Казакъстанга якын урнашкан Чәүчәк шәһәрендә яшәгән. Кургазга балалары янына килеп-китеп йөргәннәр. Руманга ике яшь ярым чакта әбисе кунакка килә. Күтеп алган олы оныкларыннан бер дә аерылырга теләми әбисе. Үзе киткәндә аны да алып китәргә уйлый – оныгын озак күрмәгән бабасына да күрсәтәсе килә. Руманның әнисе Раушанның йөрәге сизенгәндер шул вакытта – кызыннан бер дә аерыласы килми. Бу адымы өчен гомере буе үкенеп яшәячәген белгән булсамы?!.

Әсхәт абый, әнисе белән кызын алып, алар яшәгән Чәүчәк шәһәренә озата китә. Нәкъ шул вакытта Кытайда яшәүчеләр күпләп күченә башлый һәм кинәт чикләрне ябалар: солдатлар беркемне чыгармый. Тиз арада телеграмма бирә Раушан, ләкин ул соң барып җитә – Әсхәт кызын калдырып киткән була инде...

– Бабайлар мине күтәреп чик янына алып барганнар. Бәлки бәхет елмаер, әти-әнигә тапшырып булыр дип өметләнгәннәрдер. Теге яктан әти белән әни дә килгән. Әмма бөтен җирдә өч телдә плакатлар эленгән – «Чикләр ябык!» Әни кечкенә энем Ришатны күтәреп, бер атна буе чикне чыгу җаен эзләгән... Ләкин без кавыша алмадык... – дип сөйли Руман ханым.

Бер Йосыповлар гына дучар булмый мондый язмышка. Бик күп гаиләләр аерыла ул чакта. Әти-әнисе чикне чыккан, ә балалары теге якта калган гаиләләр дә күп була. 3 яше дә тулмаган Руман әти-әнисен бөтенләй хәтерләми. Әби-бабасына юанып, алар белән яши башлый. Әтисенең төпчек сеңлесе Мәрхәбә дә алар белән була. Әнә шул дүртесе яшәгән чакларын иң бәхетле еллар дип искә ала соңыннан Руман ханым.

– Чалма чәчәккә күмелгән тарлавыклар, ап-ак умырзаялар түшәлгән тауларны күреп үстем. Бабай кабаклар үстерә иде. Шул зур кабакларны машинага төяп алып кайтканыбыз хәтердә. Мин аларны күтәрә дә алмый идем, – дип искә төшерә бәләкәй чагын Руман апа.

Бәхетле балачак көннәре озак дәвам итми. Бу сәяси вакыйгалар бәләкәй Руманның әбисе өчен күтәрә алмаслык йөрәк газабына әйләнә. Балаларының өчесе – чикнең бу ягында, калганнары тегендә калганын белеп, газапта яши ул. Андагы яшәү шартларының, ачлыкның нәрсә икәнен белгән ана йөрәге бу сынауны күтәрә алмый. 5 яшьлек оныгы белән бакчага баргач, хәле китеп, чирәмгә барып ята. «Кызым, бабаңны чакыр, мин үләм», – дип әйтергә өлгерә. Күзләре йомыла башлаган әбисен уятырга, торгызырга тырыша Руман. Аннары елый-елый бабасы янына – ерак бакчага йөгерә...

Сынау арты килгән сынаудан кызчык Мәрхәбә апасына сыена. Кайдадыр әти-әнисе барлыгын аңлый, белә башлый инде ул вакытта үсә төшкән бала. Әби-бабасы, апалары аерылуның беренче көненнән үк Кытайда калган туганнары белән элемтәгә керергә тырышалар, ләкин анда хәтта хатларны да чыгармыйлар. Алай гына да түгел, Советлар Союзыннан хат килеп ирешсә, ул гаиләне җәзага дучар итәләр, тынычлык бирмиләр дигән хәбәрләр дә йөри. Газизләренең иминлеге өчен бу омтылыштан да баш тартырга мәҗбүр була гаилә.

Шул көннән ике якка аерылган гаиләләрдә өмет тулы **билгесез тормыш башлана.**

Бик сагынган вакытта кичләрен айга карап тынычлана Руман. Әти-әниле вакытыннан бирдәнбер истәлеге – әнә шул түгәрәк сылубикә була кыз өчен. Үзе айны күргәч, аның дөньяда бер генә булуын аңлап, әтием белән әнием дә мине күрәләрдер дигән уй белән юана бала.

– Әби үлгәч, Мәрхәбә апа минем өчен әни дә, әби дә булды. Без яшәгән фермадагы көтүчегә кияүгә чыккан иде ул. Ире начар кеше булмады. Төньякта аның туганнары яши иде, алар шунда күченеп китәргә теләде. Мине дә үзләреннән калдырмаслар иде. Мин Мәрхәбә апама «әни» дип дәшә башлаган идем инде... Ләкин аны да югалттым.

Моның ничек шулай килеп чыкканын әле дә аңламый Руман апа. Сәбәбе нидә? Нәрсә этәргән? Мәрхәбә апасы аның кулында диярлек фаҗигале рәвештә дөнья куя – ире аңа пычак белән кадый.

– Иренең туганнары кунакка килде ул көнне. Мин бүлмәдә аларның балаларына күз-колак булып уйнап утырам. Апаның баласы юк иде бит, әллә шул турыда сүз чыккан... Белмим, нәрсә булгандыр. Апа бүлмәгә кереп бинтлар алды да, тиз генә чыгып китте. Чыгуга, коридорда ук егылды. «Ашыгыч ярдәм» машинасы аны алып китте, ләкин коткара алмадылар. Әнә шулай тормышым яңадан чәлпәрәмә килде. Соңрак документларын таптым, алар мине кызлыкка алырга теләгәннәр. Ире ни өчен аңа пычак белән кадаганын белә алмадым. Соңрак ул утырган төрмәгә дә бардым, сорауларыма җавап эзләргә тырыштым. Ул минем белән озак сөйләшмәде, анык кына җавап та бирмәде... Сигез ел утырып чыкканнан соң тагын бер кат өйләнгәнен белдек. Ул аның өченче хатыны иде инде, берсе дә бала таба алмаган... – дип, ул вакыйгаларга тагын бер әйләнеп кайта Руман апа.

Үз гаебен таный ул кеше. Ләкин шул пычак белән Руманның да язмышын сызып үткәнен аңладымы икән җинаятьче? Әниле булырга да өлгермичә, 10 яшендә тагын бер тапкыр ятим кала кыз. Бу юлы аны әтисенең тагын бер апасы – Сания апа тәрбиягә. Әмма аның үзендә дә Руман кебекләр – алтау. Шуңа күрә аларда ел ярым гына яши кыз.

Тормышының яңа чоры әтисенең Мәсхүдә исемле икенче апасына, Алма-Ата шәһәренә күченүдән башлана. 4 нче сыйныфны гына тәмамлаган Руман район башкарма комитетыннан барлык документларын үзе алып, Алма-Атада мәктәпкә дә үзе барып урнаша. Мәсхүдә апаның русча белмәве кызны бөтен җирдә үзе йөрергә, сөйләшергә өйрәтә. Бу гаиләдән китәсе килгән чаклары күп була... Мәсхүдә апасы: «Мин сине тәрбиялим, ашатам, әниеңне алыштырам, миңа әни дип эндәш», – ди. Ләкин Руман «әни» сүзен башка берәүгә дә әйтергә теләми инде. Таш булып каткан бала

Фотолар: Руман Йосыпова архивыннан.

PRESSA

Чикне чыгарга дип рөхсәт алу өчен «сират күпер»ләрен узарга кирәк.



Чагантугай шәһәрендә әти-әнисе янында кунакта.



Әсхәт абый белән Раушан апа Алма-Атага килгәч.

48 биттә – Руман апаның Кытайга икенче тапкыр баруы. Әнисе һәм иң төпчек энесе Гали белән.

күңеленә ачкыч таба алмый Мәсхудә апасы. Ә Руман теге тетрәндергеч вакыйгадан соң үз эченә йомыла. Әмма Мәсхудә апасына ул әле дә рәхмәтле. «Балалар йортына бирмәделәр, тәрбияләделәр, яшәттеләр», – ди. Ләкин кызга бу гаиләдә яшәве ничек бирелгәнен берәү дә белми. Руман апа үзе дә бу хакта искә төшерергә дә, сөйләргә дә теләми...

– Моңарчы гомерем әтием туганнары белән узган булса, 10 нчы сыйныфта укыганда әнинең туганнары белән кавышырга насыйп булды – мине Рафыйк абыйлар эзләп тапты. Алай гына да түгел, ул очрашуга ияреп, тагын да күңелле вакыйгалар ишек какты безгә, – дип искә ала Руман апа.

Бу көнне Руман апаның әбисе дә, бабасы да зарыгып көткән була. Ләкин икесе дә тансык хәбәрне ишетә алмыйча дөнья куя. Бабасы 1980 елда вафат була, соңгы сулышына кадәр чикнең теге ягында калган балалары турында бер сүз ишетергә өметләнеп яши. Аз гына өлгерми кала...

Әнисенең абыйсы Рафыйк Кытайдан Советлар Союзына 50 нче елларда ук күченеп киткән була. Сәяси вакыйгаларны игътибар белән күзәтеп бара ул, чикне япканнан соң туганнарына хатлар язып карый – берсен дә уздырмыйлар. Таләпләр беraз йомшара төшкән вакытны туры китереп, тагын берничә хат яза. Бәхеткә, хатның берсе Раушан апа белән Әсхәт абыйга барып ирешә һәм... җавап килә! Рафыйк абый хатны алып, Фрунзе шәһәреннән шунда ук Алма-Атага килә, хатны Руманга укый.

– Хатны укыгач, иң беренче бабамны кызгандым. Ишетми китте... Кытайда әти-әниемнең исән булулары, сеңелләрем, энеләрем барлыгын белү зур сөенеч иде миңа, – ди Руман апа.

Шушы бердәнбер хатның килеп ирешүе дә – могҗиза! Рафыйк абыйлары әкренләп элемтәне җайга сала тора, гомер уза... Аралашуда яңа киртәләр барлыкка килә. Кытайдан хатлар гарәп хәрефләре белән татарча язылып җибәрелә. Ә монда аны укый белүче юк. Җаен табалар: әнисе кайчандыр латин графикасын өйрәнгәнен исенә төшерә – хатларны латин хәрефләре белән яза башлый. Тагын бер киртә – Руман апаның әтисен, элеккеге кебек, эше буенча әле тегендә, әле монда җибәреп торалар: гаилә гел күченә. Хатлар алар артыннан өлгерми калган вакытлар да була. Шулай да фотографияләр аркылы газиз туганнарын, әти-әнисен күрү бәхетенә ирешә ул.

Мәктәпне тәмамлап, бер тиен акчасыз олы тормышка атлый Руман. Хыяллары белән Кытайда булса да, тормышны монда алып барырга кирәк бит. Читтән торып укырга керә кыз, эш таба. Эзләп тапкан фатирына да беренче хезмәт хакыннан түләргә сүз биреп урнаша. Ата-анасы белән бүлешә алмаган, үзе тоярга гаҗиз булган хисләр кәсәсе шулкадәр ташып чыккан була – 19 яшендә үк гаилә кора яшь кыз. Озак көттермичә уллары туа.

– Күп еллар үз эчемә бикләнеп, чын гаиләнең нәрсә икәнен белми яшәвем, бу тормышта күргәннәрем эзсез калмаган, күрәсең. Тулы гаиләдә үскән кеше өчен үзеннән-үзе бирелә торган җиңел генә әйберләр дә миңа авырдан бирелә иде. Нәрсәгә тотынсам да, төртелеп калам. Балаларым күп булсын иде дип хыялландым. Без үзебез тугыз бала икән бит әти-әнидә. Моны белмәсәм дә, кечкенәдән үзем дә шул гаилә моделенә тартыла идем. Моңа кадәр берәүгә дә бирмәгән назымны, игътибарымны иремә юнәлттем. Әнә шул артык тырышуым, бетмәс хисләрем белән аны артык бастырып яшәгәнмендер, буганмындыр дип уйлыйм. Мин хыялланган гаилә барып чыкмады, без аерылыштык... – дип дәвам итә Руман апа.

Шушы еллар буе әти-әнисе белән кавышу теләге көч биреп тора аңа. Ике арадагы элемтә җайга салынгач та, җыенып юлга чыгып китәр көнгә кадәр яшисе дә яшисе икән әле... 80 нче еллар ахырында Кытайда да, бездә дә болганчык чор башлана. Документлар белән озак йөрергә туры килә. Әле теге кәгазь дөрес түгел, әле монысы, әле өченчесе...

– Туганнарым турында беренче хәбәр килгәнгә ун елдан артык вакыт узды. Ниһаять, 1990 елның көзендә юлга кузгалдык. Олы улыма – 9, кечесенә 6 яшь иде

ул вакытта. Самолет белән Өремчегә очтык, Ришат энем безне шунда каршы алды да, әниләр яшәгән Чәүчәк шәһәренә алып китте. Безне каршы алырга бик күп туганнар җыелган иде. Ике яшь ярым вакытта туган йортыннан чыгып киткән апалары 30 яшьлек булып кайтып керде. Иң беренче чиратта әни белән кочаклаштык... Әти мәет озатуда иде, ул соңрак кайтты, – дип искә ала Руман апа кадерле мизгелләрен.

– Ишегалдында әни белән кочаклашып, икесе дә озак елаштылар. Без дә еладык... Үз гомеремдә әтинең елаганын бер генә тапкыр күрдем – шул көнне... Бер сәгать буе туктый алмыйча елады әти, – дип сөйли ул көн турында Руман апаның энесе Ришат абый.

Йөзгә-биткә икесенә дә охшаганын аңлый Руман апа. Ә холкы белән – нәкъ әтисе икән бит!

– Бер-беребезне күрмичә ничә еллар яшәп тә, икебез бертөрле булганга гаҗәпләндем. Оныкларын сөйгәннән соң әни, беләсезме, нәрсә өчен борчылды? Аларның вакытында сөннәткә утыртылмаган булулары өчен, – ди ул.

Бу җитешсезлекне Руман апа кире Казакъстанга кайткач та төзәтә, шунда ук әнисенә дә язып җибәрә. Ә әлегә ул – үзенекеләр янында. Чәүчәктә үткәргән һәр көнен мизгеленә кадәр сеңдереп калырга тырыша. Руман бәләкәй булганда әтисе эшләгән далаларга да баралар. Хәзер анда уңыш үстерү серен тапканнар, дала буйлап ком буранын тоткарлый торган җайланмалар урнаштырылган, ә ул киңлекләр таный торган түгел – ямь-яшел булып утыра! Гаиләдәге тәртипләр, кешеләрнең әдәплелеге, әхлагы – искиткеч! Андагы тәрбия дә бөтенләй икенче төрле икәнен күрә Руман апа. Аз булсалар да, татарлар шулкадәр бердәм булып яши. Мәдәният тә, тел дә, дин дә, гореф-гадәтләр дә сакланган. 1917 елгы Октябрь революциясе елларында Россия империясеннән бу якларга китеп урнашкан татар сәүдәгәрләре, интеллигенциясенең йогынтысы озак елларга җиткән шулай.

– Анда бергә җыелсалар, кирәкмәгән сүз сөйләп, буш аралашу белән мавыкмыйлар, мәгънәле сүз генә сөйләшәләр. Теге кешенең хәле ничек, монысы исән-саумы, сәламәтлеге ничек? Кешелеклелек сыйфатлары сокландыргыч! Минем дә үз улларымны шундый итеп күрәсем килде – аларда бер-берсен олылау, хөрмәтләү, якын итү шулкадәр матур күренеш булып күңелемә кереп калды. Алты энем, ике сеңлем һәрберсе гомер буе аралашкан якын кешеләрем кебек иде. Кечкенәдән зур гаилә турында хыялланууым әнә кайдан килә икән бит! Әти-әнидән дә, туганнарымнан да аерыласым килмәде. Ике айга якын яшәдек аларда. Балалар хәтта укырга да соңарып бардылар.

Сәяси вакыйгалар ул чорда күп гаиләләрне аера. Яңа язмышлар турында ишетеп кайта Руман апа. Бер туганнары чик аша качып чыкканда авырый башлаган кызларын чит кешеләрдә калдырып китәргә мәҗбүр була. Кире чыгар өчен юллар ябылган... Күп еллар узгач кына кызларын эзләп тапканнар, ләкин... Ул аларны гафу итә алмаган. Үзен тагын бик күп башка язмышлар белән чагыштырып, Руман апа шөкер итә. Менә нинди бәхетле бит ул! Балалары да бар, әти-әнисе дә исән!

Шул беренче баруында Кытайда талон системасы буенча яшәүнең нәрсә икәнен белеп кайта Руман апа. Энесе Ришат: «Тиздән сездә дә булачак», – дип кисәтә. Кире Алма-Атага кайтканда аның фаразлары тормышка ашкан була инде. Улларын мәктәпкә киендереп җибәрер өчен ак күлмәк тә таба алмый Руман ханым – киштәләр бушаган була...

Бер табышкач, гаиләсеннән кабат озакка аерылышырга теләми Руман апа. Тик Кытайга бару зур кыенлыклар белән генә бирелә. Виза алу – үзе бер сынау. Казакълар өчен чикне чыгу таләпләре бер кәгазь битенә сыйса, Кытайда туып, аннан киткән Руман апа өчен ерып чыкмаслык авырлыклар белән бирелә бу рәсмиләштерүләр. Бөтенләйгә күчеп китәргә дә талпынып карый ул, берни барып чыкмый. «Кытайда туган» дигән мөһер аркасында аңа туган җиренә юллар ябык... Шул метрика кәгазендә туган җире Казакъстан дип язылса, турист буларак чикне чыгу да күпкә җиңел булыр иде бит.

– Әти белән әни үзләре дә безгә – Казакъстанга килделәр. Әнинең бездә өч тапкыр булганы бар. Ә мин үзем туган җиремдә әти үлгәч – 2017 елда соңгы тапкыр булдым. Кызганыч, соңгы юлга озатырга ярты сәгать кенә өлгермәдем. Шул баруымда иң кече сеңлем дә вакытсыз арабыздан китте... – ди Руман апа.

Тормыш тоташ бәхеттән тормаган кебек, тоташ сынаулардан гына да тормый. Соңарып килгән бәхете өчен Аллаһы Тәгаләгә бик рәхмәтле Руман апа. Һәр көненә шөкер итеп яши ул. Еракта булса да, әнисенең барлыгын, аның белән сөйләшә, киңәшләшә алуын да зур бүләк дип кабул итә.

«Һәр кеше – үзе бер дөнья, – диярга ярата Руман ханым. – Аның аркылы бу дөньяның яңа якларын ачасың». Руман апа үзе үк – без моңарчы күрмәгән, белмәгән, күз алдына да китермәгән бер дөнья. Аның тарихының азагы сөенечле. Бар кешегә дә язмыш алай мәрхәмәтле булмый. Болгавыр елларда туганнарыннан аерылып, әле дә бер-берсен таба алмаган гаиләләр бик күп. Кайберләре бу бәхетле мизгелләренә ирешә алмыйча дөнья белән хушлашкан... Руман апа, үз өлешенә канәгать булып, бәхетле гомер кичерә. Янында – уллары, оныклары. Теләгән вакытта әнисе белән сөйләшә ала. «Сөйләшү» дисәң, хәтере калыр инде ул аралашуның.

– Казанга кайтып төпләнгән Ришат энем әни белән икебез арасында хат ташучы кебек. Элек WeChat мессенджеры аша турыдан-туры аралаша идек. Әлеге мессенджер Кытайда теркәлгән, анда гына кулланырга ярый. Шуңа күрә берничә ел элек чик аша барган аралашуларны бетерер өчен, элемтәне өзделәр. Аны яңадан кушар өчен Кытайга барырга кирәк. Хәзер чикләр карантин аркасында ябык. Шуңа күрә башка аралашу чаралары эзләргә мәҗбүрбез. Мин әнигә дигән хәбәрне ватсап аркылы – Ришат энемә, ул WeChat аша әнигә җибәрә. Җавапны шундук миңа кире иреште рә. Шулай аралашып яшибез. Сәясәт үзгәреп, бар да рәтләнер дип өметләнәм. Гаиләләр кавышсын, барып, аралашып яшәргә язсын иде...

КҮЗЛӘРЕМӘ БЕР КАРАВЫҢ ҖИТӘ...

Популяр җырчы Радик Динәхмәтов башкаруында яңгыраган бу җырны күпләр беренче ишетүдән үк яратып, халык җыры итеп кабул итте. Менә утыз ел инде сәхнәдән булсынмы, радио-телевидениедәнме, ул башкарылмый калган берәр көн бар микән? Шул җырын тыңлау өчен генә Радикны төрле чараларга, иҗат кичәләренә, юбилейларга чакыралар. Берәр концертында җырламый калса, алкышлап, җырлавын сорыйлар... Радикны олы сәхнәгә шушы җыр алып чыкты һәм танытты. Шуңа да аның авторларына күңелендә бетмәс-төкәнмәс рәхмәт хисләре йөртә. Ә җырның туу тарихы бик кызыклы.


Рәйсә һәм Байрас Абдуллиннар


Рәйсә һәм Шәриф Биккол

Фотолар: гаиләләр архивыннан

Фәния СӘЕТГӘРӘЕВА-ГАБИДУЛЛИНА

...1940 нчы елларда, ягъни унбиш-уналты яшьләрендә үк, Шәриф Бикколның шигырьләре газета-журнал битләрендә басыла башлый. Дәүләкән педагогика училищесында укып йөргән чагы бу. Аны тәмамлагач, укытучы булып эшли, иҗат дөньясына чума. Тик үсмернең җырлы юлын сугыш өзә...

Шигырь сөючеләр бәхетенә Шәриф Биккол канлы сугыштан исән кайта һәм бөтен гомерен журналистикага, шигъриятькә багышлый. Шигырьләренә композиторлар берсеннән-берсе матур көйләр яза. Ә бөтен дөньяга таралган «Әле дә син бар әле дөньяда» җырының сүзләрен Шәриф Биккол 40 яшендә, 1964 елда ук язган була. Шигырь хәләленә – Татарстан кызы Рәйсәгә багышланган. Рәйсә ханым үзе бу хакта миңа нәрсәләр сөйләгән иде:

– Бөтен булмышын эшенә, иҗатка багышласа да, фикердәшләре, каләмдәшләре белән күңелен ачып сөйләшә алмый – бөтен зарын минем белән уртаклаша иде. «Эч серләремне сөйләр, борчу-мәшәкатьләремнән арындырыр, киңәш бирер иң якын кешем – син», – дия иде. Мин бит мулла нәселеннән. Тәрбия – үрнәкле. Ике институт тәмамладым. «Идеаль холыклы хатыным», – дия иде... Балачакта, сугыш пыран-заран китергән үсмер елларында ала алмаган белем-тәрбияне миннән алды ул. Төрле башваткычлар чишәргә ярата иде. Белмәгәнен кыенсынмый – миннән сорый. Ул белмәгән нәрсәләрне белүемә соклана, шатлана.

Шулай беркөн Шәриф эштән бик моңсу кайтты. Кәефе юклыгын сизәм, тик нигә икәнен аңламыйм. Үзе дә сүз кузгатмый. Күзләремә күк йөздәй зәңгәр күзләре белән тутырып карый да йөзен читкә бора. Сизеп торам: мине борчыйсы килми. Менә нәкъ шул көнне туды аның бу шигыре... Ә йөрәгенә таш булып төшкән теге борчылуының нәрсәдән икәнен соңрак белдем. Бер-ике көн элек кенә бездә Шәриф дус итеп йөргән, ул якын күргән ике каләмдәше кунакта булып китте. Шәриф аларны «аһ» итеп каршылады. Мин табын әзерләдем дә, аларны кунак бүлмәсендә калдырып, үз эшем белән шөгыльләндем. Бик озак матур гына сөйләшеп утырдылар. Соңыннан трамвай тукталышына кадәр озатып куйдык. Менә шушы икәү: «Шәрифне исертеп йоклаттык та Рәйсә белән «күңел ачтык», – дип сөйләп йөргәннәр. Бу гайбәт иремә дә килеп ишетелгән. Ул аның дөрес түгеллеген, әлбәттә, белә. Шуңа да миңа әйтмичә эчтән генә сызган...

1964 елда ук язылган «Әле дә син бар әле дөньяда» шигыренә икенче гомерне композитор Байрас Абдуллин бирә. Моңа булачак хәләшенә беренче күрүдән гашыйк булуы сәбәпчедер, ди дуслары. Тормыш юлында Рәйсәне очраткач, егерме көннән (!) кызның Хәйбуллада яшәүче әти-әнисенә кодалар җибәрә ул. Рәйсә – булачак укыту-

Әле дә син бар әле дөньяда

Күптән инде әйтер
хисләрем бар
Кем яулавын күңел
түремне.
Айга бары ачам
йөрәгемне,
Ай тапшырсын сиңа
серемне.
Күзләремә бер каравың
җитә
Бөтен кайгыларым югала.
Әле дә син бар әле
бәхетемә,
Әле дә син бар әле
дөньяда.
Тәрәз шакып назлы таң
җилләре
Миннән сиңа сәлам
китерер.
Тыңла күңел биреп,
алар сиңа
Минем сүзләремне
җиткерер.

чы, бишенче курста имтиханнар тапшырып йөри, үзе кайта алмый. Әти-әнисенә телефон аша гына: «Театрда эшли, акыллы егет, мин аңа кияүгә чыгарга риза, рөхсәт итегез», – дип хәбәр сала. «Йа Хода! Бер дә белмәгән артистка ничек инде курыкмый кыз бирмәк кирәк! Байрас дигән артистны ишеткәнебез дә юк», – дип хафага кала әти-әнисе. Әмма Байрасның итагатьлелеге, тыйнаклыгы аларның икеләнүләрен җиңә... Егерме биш ел тату, матур яшәү елларында Рәйсәсенә бик күп җырлар багышлый Байрас Абдуллин. Туганнары белән җыелганда үзе үк аларны җырлап та ишеттерә. Шундый бер бәйрәмдә – җәмәгатенең 30 яшьлек юбилеенда өр-яңа бик моңлы көй уйный да: «Туачак балабыз өчен сөекле хатыныма бүләк бу көй», – ди. Барысы да моң тәэсирендә әсир кала... Бераздан гына: «Нигә сүзләре юк? Сүзсез җыр буламы? Көй дә булган икән бүләк!» – дип битәрләп тә алалар.

– Кунаклар киткәч, төн буе шигырь китаплары актардык, – дип хәтерли Рәйсә ханым. – 1987 ел иде бу. Күңелгә ятышлы сүзләр эзлибез. Дистәләгән шагыйрьнең китапханәбездә булган җыентыкларын укып чыктык. Тик берсендә дә безнең халәткә, кәефкә, сөюебезгә туры килердәй, көйгә дә ярардай сүзләр тапмадык. Шуннан ирем Шәриф Биккол китабын табып алып кайтты. «Әле дә син бар әле дөньяда» шигырен бер укуда яраттык. Тиздән өченче балабызны алып кайттым. Бәби туена килгән кунакларга шушы җырны башкарды Байрас. Барысына да ошады. Өйрәнеп кайтып киттеләр хәтта. Аннары очрашкан саен җырлый идек...

Әйе, Абдуллиннар гаиләсенең гимны кебек була бу җыр. Тик Байрасның дуслары мондый җырның сәхнәләрдә җырланмавына үпкә белдерә. Җырчыларга тәкъдим итәргә кушалар. Байрас Абдуллин җырны үзе яратып тыңлаган, матур гына тавышлы бер җырчыга биреп карый. Тик тегесе ноталарны югалта. Үзенең иҗатына шундый мөнәсәбәттән соң башкача әрсезләнеп йөрми композитор. Биш ел үтеп китә...

...Көннәрдән бер көнне Башкорт академия драма театрының музыканты булып эшләгән Радик Динәхмәтовка хезмәттәшләре бер записка һәм ноталар язылган кәгазь тоттыра. «Радик! Шушы җырны кара әле. Ошатсаң, җырла. Синең тавышка гына туры килә сыман. Байрас абыең», – диелгән була язуда. Г. Әлмөхәммәтов гимназиясендә укыганда ук Радикның җырга сәләтен ачыклаган була остазы. Яраткан укытучысына, музыкант буларак остазына әйләнгән Байрас абыйсының сүзен кире кагамы соң Радик?! 1992 елда театр коллективының гастрольләре вакытында театральләштерелгән тамашада җыр беренче тапкыр башкарыла. Зал аягүсте басып алкышлый. Бу көн Шәриф Биккол шигыренең өченче туган көне була. Яңа җырның моңы да, сүзләре дә, хәтта авторлары да сәнгать сөючеләрне гаҗәпкә калдыра. Утыз ел элек туган шигырьгә музыка дөньясында таныш булмаган композитор иҗат иткән җыр күңелләрнең әллә кайсы кылларына кагылып, бер сагышландыра, бер өметләндерә. Һәрбер тыңлаучы сөйгәненең аңа гына әйтер сүзе дип кабул итә...

Мәхәббәт җимеше булып туган бу җырның башкача тәэсир итүе мөмкин дә түгел. Гаҗәп бит: җырның сүзләре дә, көе дә Рәйсә дигән ханымнарга багышланган. Көйгә сүзләр сайлаганда Рәйсә белән Байрас аның кемгә атап язылганын белмиләр, әлбәттә.

– Җырны халык яратып кабул иткәч, Байрасның Шәриф Биккол белән очрашасы, шагыйрьгә рәхмәт әйтәсе килгән иде, – ди Рәйсә уфтанып. – Өлгерә алмый калды: Шәриф Биккол якты дөньяны бик иртә калдырып китте. Җыры гына калды...

«Әле дә син бар әле дөньяда» җырын Шәриф Биккол ишетергә өлгерә! Ул аны бик ярата. Тик композиторының кем булуын һәм көйнең кемгә багышлануын гына белми кала. Хатаны 2009 елның җәендә Радик Динәхмәтов төзәтә. Шагыйрь белән композиторны илһамландырып, үзләренә җыр багышларлык итеп ярату, яраттырган хатыннарын – ике Рәйсәне очраштыра. Гади очрашу гына булмый ул. Шәриф Бикколның туган авылы Карлымандагы музеенда күрешә алар. Бу көнне авыл мәдәният йортында шагыйрь хөрмәтенә шигырь һәм җыр кичәсе уза.

Әйе, шагыйрьнең исеме туган ягында мәңгеләштерелгән. «Әле дә син бар әле дөньяда» җыры белән Байрас Абдуллин һәм Радик Динәхмәтов исә шагыйрьгә һәйкәл куйды, диде шигърият һәм җыр сөючеләр. Ул хәзер дөньяның әллә кайсы нокталарында яңгырый: инглизчә, төрекчә, татарча, башкортча, русча... Төрек теленә – Байрас Абдуллинның улы Алмаз, русчага – Газим Шәфыйков, инглиз теленә танылган композитор Рим Хәсәнов тәрҗемә иткән.

– Күптән түгел кызым Алина Урта диңгездә ял итеп кайтты. Бу җыр ул туасы хөрмәткә миңа бүләк ителгән иде, – дип сөйләде Рәйсә Абдуллина. – Комда кызынып ятканда берничә яшь-җилкенчәкнең шушы җырны җырлый-җырлый су коенганын күргән. «Таныш моңны ишетеп, башта дертләп киттем, тик сүзләре аңлашылмады», – дип сөйләде кызым. Нинди телдә җырлагандыр ял итүчеләр? «Әле дә син бар әле дөньяда» җыры Урта диңгез ярларына барып җиткән икән, димәк, дулкыны ерак киткән...

Уфа шәһәре.

Тулысынча укыгыз »



«МӘХӘББӘТ – ДУСЛЫКНЫҢ БЕР КҮРЕНЕШЕ ГЕНӘ»



Алмаз НУРГАЛИЕВ,
режиссер;
гаилә стажы – 16 ел;
15, 13, 4 һәм 2 яшьләрдәге
дүрт малай әтисе.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Бу сорауга төгәл җавабым юк. Барысы да синең яшеңә бәйләнгән: яшьрәк чакта бер нәрсәгә игътибар ителгән, хәзер – башкага... Күпчелек очракта мин башта хатын-кызның берәр кимчелеген күрәм. Әйтик, артык бизәнгәнен һәм шунда ук: «Нигә кирәк икән бу кадәр буяну?» – дип уйлыйм. Табигыйлекне югалтмыйча, шуңа аз гына матурлык өстәүгә берни дә җитми! Шундыйлар ошый... Ә Алсуга килгәндә, иң элек аның да кимчелегенә күз төшкән иде. Беренче тапкыр күргәндә алдагы бер юл чәче буялган иде аның. Мин шунда ук: «Чәчен болай бозу нигә кирәк булды икән инде?» – дип уйладым.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хәйләкәрлеген! Без, ир-атлар, үзебезне көчле җенес дип санасак та, хисләр һәм гаилә мөнәсәбәтләрендә хатын-кыз күпкә көчлерәк дип уйлыйм. Ул бөтен вакыйгаларны да үзенең йөрәге, җаны аркылы уздыра. Балалар тормышындагы һәр яңалыктан да хәбәрдар. Ә мин күп нәрсәне белеп бетермәскә дә мөмкин. Эшемнең бөтен нечкәлекләрен хәтерлим – һөнәрем буенча шулай туры килә, ә өйдәге хәлләрне менә, белмим. Гомумән, күпчелек ир-ат шулай эш дип яши... Сизәм: мине борчымас өчен Алсу кайвакыт нәрсәнедер яшереп кала. Акыллы хәйлә дип саныйм моны. Кайчак хәтта сөенеп тә куям: шундый оста эшли ул моны. Безне: «Әти кеше кырыс булырга тиеш, соңгы сүз – әтинеке, гаиләдә төп авторитет – әти», – дип үстерделәр. Әлеге тәрбияне Алсу белән үзебезнең гаиләдә дә дәвам итәбез. Әмма мондый тәрбиянең кире ягы да бар. Бала үсеп буйга җиткәч, кырыслык аркасында ата белән бала арасы ерагаерга да мөмкин.
Бу чорда ике араны көйләү әни җилкәсенә төшә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Алдауны! Чынлыкта ул хәйләнең бер төре, тик начар ягы. Үземне хөрмәтләмәүне дә гафу итмәс идем. Хыянәт тә алдауга керә.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә кайсы якынрак?

– Икенчеседер. Безнең дүрт бала, димәк, беребез гаиләгә игътибарлырак булырга тиеш. Әйткәнемчә, күпчелек иҗат әһелләре кебек үк, мин дә үз эшемә чумган. Әйтик, вакытында «Җәлил укулары» бәйгесенең төп башлап җибәрүчесе, үткәрүчеләрнең берсе булдым. Өч ел дәвамында берничә йөз финалистның нинди шигырь сөйләгәнен хәзер дә беләм, йөзләрен хәтерлим. Шул ук вакытта, гаиләдә ир балалар тәрбияләгәч, дәресләрен карау, тәртипләрен тикшерү минем өскә төшсә дә, гап-гади әйберләрне – кайсы баланың нинди түгәрәккә, кайчан барасын онытырга мөмкинмен. Менә бүгенге көндә Әзһәр абый Шакиров турында фильм төшерәбез. Мин хәзер 60–70 нче елларда яшим. Бөтен уем шул хакта: ул чактагы Казан нинди булган, кешеләр ничек киенгән, ничек ял иткән... Ә дөньяда ниләр булып ята, күршебездә кемнәр яши – аларның бөтенесен дә хатыным белә. Миңа шулай җайлырак.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Мәхәббәт – ул дуслыкның бер күренеше. Ә дуслык – үзеңә нииндидер бер файдалы кешене эзләп табу. Шундыйлар, гадәттә, уртак телне тиз таба. Уртак эшләре булган гаиләләргә шуңа да көнләшебрәк карыйм: аларда дуслык төшенчәсе бик нык чагыла. Алар, гадәттә, бертөрлерәк тәрбия, бертөрле белем алган; эшләре төгәл бүленгән: хатын-кыз бухгалтерияне алып бара, ир таба, җитәкли... Без Алсу белән икебез ике дөнья кешесе, ләкин бер-беребезне аңларга тырышып яшибез. Күпчелек очракта минем тәрбияне кабул итәргә тырышуы өчен Алсуга рәхмәтлемен. Аның баш июедер инде бу... Клип эшләгәч, фильм төшергәч, иң беренче булып Алсу үз фикерен җиткерсә дә, эштәге проблемаларны бүлешкәнем юк аның белән.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Алсу белән без урамда таныштык. Кышкы бер матур көн иде. Мин ул көнне хастаханәдән чыктым. Нәрсә дип ба-

рып дәштем, ни сорадым икән, анысын хәтерләмим... Ә ничек тәкъдим ясавым, әлбәттә, истә. «Әйдә, өйләнешәбезме?» – дидем. Төрлечә кыланып тәкъдим ясаулар минем өчен түгел. «Нәрсәгә кирәк?» – дип карыйм мин аларга – исем китми. Без Алсу белән озак очрашмадык – дүрт ай тирәсе генә. Әти-әни белән бердәнбер таныштырган кызым ул булды. Аңа кадәр кем белән йөргәнемне дә белмәделәр. Ул елны туган көнемне туган ягымда уздырырга булдым. Шунда Алсуны да әниләргә алып кайтып күрсәттем. Кыз озату Казанда – Каравай бистәсендә булды. Икенче көнне иртәнге сәгать өчтә үк Актанышка, туйга чыгып киттек. Беренче тапкыр кайтучылар юлның озынлыгына шаккатты.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Алайга китсә, кыз бала да әтисенә охшаган егетне сайлый, диләр бит. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам – мин хатынымны әнигә охшатып эзләмәдем. Мондый нәрсә уемда да булмады. Аларның үзара мөгамәләләре бик яхшы һәм бу, беренче чиратта, әнинең уңышыдыр. Миңа калса, безнең әни кем белән дә уртак тел табар иде.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Безнең дә төрле вакытлар булды. Ләкин Алсуның «мин синнән күбрәк табам» диюен ишетмәдем. Бу хакта борчылуым да булмады. Тормыш бит бу: бүген уңыш берең кә күбрәк елмая, иртәгә – икенчеңә. Әйе, кемдәдер мал табу сәләте күбрәк. Ләкин иртәгә кем кемгә таяныч буласын беребез дә белми. Икең арасындагы мөнәсәбәтләр тотрыклы икән, гаилә нинди генә очракта да нык буладыр.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Ир-атның шөгыльле булуы кызыктыр аңа. Яраткан эше яки хоббие, мавыгуы... Ә ир-атның матурлыгы хатын-кыз өчен беренче урында түгелдер. Син, әлбәттә, пөхтә киенергә тиеш, ләкин табигый матурлык төп игътибар үзәгендә була аладыр дип санамыйм.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Дөреслек бардыр бу сүздә. Андый хатын-кызга карап: «Моның инде, мөгаен, берәр кешесе бардыр, – дип уйлыйсың. – Синең кебек йолкыш аңа нәрсәгә кирәк?» – дисең. Бу – яшьлектәге фикерләр. Хәзер, әлбәттә, алай уйламыйм.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Безнең Алсу бик пөхтәлек ярата, мин сөйләргә теләгән хәл шуның аркасында килеп чыккандыр инде. Берсендә җиде клипка заказ бирделәр. Әле бу эшкә беренче тотынуым дисәм дә була. Бер ай эчендә эшләргә кирәк иде аны. Ниһаять, барысын да төшереп бетердем, монтажга тотындым. Бишесен монтажлаган да идем инде. Ә беркөнне, өй җыештырып йөргән җирдән, Алсу минем компьютерга да тәртип салырга тотынган. Яңа папка ачканда «новая папка» дип чыга бит, минем алар барысы да шулай гына язылган иде: «новая папка № 1», «новая папка № 2», «новая папка № 3»... Алсу моны дөрес түгел дип тапкан һәм төзәтеп чыккан – папкаларга матур исемнәр кушкан. Ә монтаж программасы, папканың исемен үзгәрткәч, файлларны кайдан алганын күрми башлый. Ул вакытта чәчем бар иде әле – чүт чәчемне йолкып бетермәдем... Хәзер булса алай ук борчылмас та идем, ә ул чакта үзем дә өйрәнчек кенә. Барысын да киредән эшләргә туры килде.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Безнең 80 процент тормыш минем сүз белән барадыр. Дөресрәге, мин шулай уйлыйм. Ә чынлыкта... Элегрәк киемсалым алырга гел бергә чыга идек. Бөтен ир-ат кебек мин дә кибеттә йөрергә яратмыйм. Хәтта башым авырта башлый. Ахыр чиктә кызып ук китәм. Ә Алсу... Ул үпкәләгән кыяфәт чыгара һәм мин: «Әйдә, әйдә, нәрсә кирәк, алабыз», – дип, аны юатырга керешәм. Бу да юл бирү дип аталадыр, мөгаен. Ә башка вакыт үземне, чынлап та, хаклы дип саныйм икән, шуны төрле юллар белән аңлатырга тырышам.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Үтереп ашыйсы килгәндә: «Өйдә ашарга бармы?» – дип шалтыратып сорыйм. Юк икән, шаурма коткара – юл уңаеннан алып кайтам. Тәмле дә, туклыклы да. Ашыгыч булмаса, кайтып, тиз генә үзем пеширәм. Ләкин соңыннан мыгырдап йөрергә мөмкинмен... Алсуга болай бик авырлык китермәскә тырышабыз: идәнне, савыт-сабаны күптән малайлар юа, энекәшләрен дә карашалар. Гаиләдә балалар хәтерләп калырлык гадәтләр, йолалар булырга тиеш дип саныйм, мәсәлән, туган көннәр үткәрү. Иманым камил, туган көннәрендә әниләре краб таякчыкларыннан ясаган салат, торт һәм мин пешергән пицца гомерлеккә исләрендә калачак. Балачак дигәндә, үзем әбекәйнең шәңгәсен шулай искә төшерәм, әнинең бәлешләрен, өчпочмагын, бишбармагын... Һәм Алсуның да аларны нәкъ әни кебек пешерүен көтәм.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Бездә киресенчә – һәрвакыт мин соңга калам. Пунктуаль кеше түгеллегемне сез үзегез дә соңга калуымнан сиздегез инде... Театрга, концертка җыенсак та, Алсу мине, гадәттә, ишек төбендә басып көтеп тора. Тик минем бәхеткә, кая барсак та, ул чараны соңарып башлыйлар. «Ашыгып килгән булсак, басып торыр идек әле», – дим.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Минем өчен иң авыр әйбер – бүләк сайлау. Туры китерә алмам дигән курку бар. Ә Алсу, киресенчә, барыбызга карата да бик игътибарлы. Бездә шундый тәртип: бөтен бүләкләрне дә ул ала. Осталыгым булмагач, 8 Мартта да, туган көнендә дә: «Сиңа нәрсә алыйм?» – дип үзеннән сорыйм башта. Чәчәкләрне дә бала тудыру йортыннан каршылаганда гына алып барган бар. Үлгән чәчкәләрне кабул итеп бетерә алмыйм... Гөлләр бүләк итү дөресрәктер, әмма өйдә бик күп инде алар хәзер безнең.



Тулысынча укыгыз »


Фото: www.pixabay.com



Сорауларга теш табибы Венера **ИШТАЕВА** җавап бирә

Кызыбызның сөт тешләрендә кариес барлыкка килде. Аларны дәвалап тормасаң да була, барыбер алышына, диләр. Алар яңа үсеп чыгучы тешләргә зыян сала аламы?

Дөрес, сөт тешләре барыбер коелып бетәчәк. Ләкин кариес аркасында авыздагы ялкынсыну процессы яңа үсеп килүче тешләргә йогынты ясый. Алар чыгуга ук коелырга да мөмкин. Дәваламаган сөт тешләренең авыртмыйча, зыян салмыйча гына төшеп бетүе – бик сирәк күренеш. Гадәттә, яңа чыккан тешләр дә зыян күрә. Алар башта сызлый. Аннары ялкынсыну башлана, шешеп чыга. Нәтиҗәдә, тешне алырга туры килә. Шуңа күрә сөт тешләрен дә кичекмәстән дәваларга кирәк.

Баланың беренче тешләре әле яңа гына чыккан иде, аларда инде кара таплар күзәтәм. Олы баланың да 3 яшькә авызында чәйнәрлек тә тешләре калмады, череп бетте. Сәбәбе нидә булырга мөмкин?

Кариес барлыкка килүнең сәбәпләре күп: авыз гигиенасын сакламау, төнге ашатулар, баллы ризык еш куллану, нәселдәнлек, тешләр формалашканда нинди дә булса авыру йоктыру, төрле препаратлар куллану үсеп кенә килүче сөт тешләренә, аларның эмаленә йогынты ясый. Шуңа күрә тешләр чыкканда ук аларны ныгытырга, сакларга киңәш ителә. Киңәшләрне теш табибы бирәчәк, ярты елга бер тапкыр күренеп тору зарур. Бәлки, ул сезгә фторлаштыру процессы билгеләр.

Кариесның беренчел билгеләреннән теш табибы көмеш йөгертү, фторлаштыру процесслары тәкъдим итте. Алар, чыннан да, кариестан саклап кала аламы?

Әйе, әлеге процедуралар кариесның азып китүеннән сакларга мөмкин. Ләкин кариесның нинди стадиядә булуын исәпкә алу мөһим. Кариес тап кына булып килсә яисә хроник формасы булса – ярдәм итә. Ә инде тештә куышлык барлыкка килгән очракта аларның файдасы юк. Көмешләндерү хәзер сирәгрәк кулланыла, чөнки эстетик яктан ул бик кулай түгел. Фторлаштыру процедурасын табиблар ешрак билгели. Сезгә кайсын сайларга кирәклеген табиб төгәлрәк әйтер.

Нәниләргә кучтәнәч!

Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга балалар неврологы Ксения ЯГУНОВА җавап бирә

Улыбызга сигез ай. Алга китеше бик тиз бара, диван, караватn кырына тотынып йөри дә башлады. Ләкин гәүдәсен тотарга авыррак әле. Еш кына авып, егылып китә. Шуның аркасында берничә тапкыр башы белән егылды, хәтта караваттан баштүбән егылып төште. Күгәргән урыны күренмәде, кызарып кына чыкты. Бу егылулар бала өчен куркынычмы? Зыяны булмады микән?

Башны бәрүләр, егылулар баш мие үсеше һәм аның эшләве өчен зыянлы булырга мөмкин. Башны җәрәхәтләүдән һәрвакыт сакларга кирәк. Шулай ук массаж, дәвалау физкультурасы ярдәмендә баланың аяк-кул мускулларын, гәүдә мускулларын ныгытыгыз. Сенсорлы паласлар ярдәмендә табандагы тоемлауны арттыру, сыйракны (голеностоп) тотып торучы профилактик аяк киеме куллану да файдага булыр.

2 яшьлек кызыбыз йоклап киткәндә сискәнеп куя. Хәзер бу төнлә дә еш кабатлана. Сискәнеп куюдан хәтта үзе куркып уяныргa да мөмкин. Сәбәбе нидә икән?

Нерв системасы көн дәвамында кабул иткән мәгълүматны төнлә эшкәртә. Йоклап киткәндә яисә уянганда сискәнеп китү, йоклаганда хәрәкәтләнү, сикереп куюлар сәламәт балага да, олыларга да хас. Бу нерв системасының артык ярсуыннан килә. Хисле балаларда ул ешрак та күзәтелә. Ләкин әлеге билгеләр тартышу, көзән җыеру да булырга мөмкин, моны истә тотарга кирәк. Шуңа күрә әлеге проблема белән неврологка мөрәҗәгать итегез. Тикшеренүләрдән соң, табиб төнлә сискәнеп уянуның сәбәбен ачыклар.

Балабызга унбер ай, баш лепкәсе (родничок) – 15 мм. «Озаграк ябыла бу сезнең», – диде табиб. Бу хакта борчылу, тизрәк ябылсын өчен нәрсәдер эшләү кирәкме?

Баланың бу яшьтә лепкәсе ябылмаганга борчыласы юк. Шулай да берничә тикшеренү узарга киңәш итәм. Д витаминына анализ бирегез һәм эндокринолог белән киңәшләшегез. Нинди дә булса тайпылышлар табылган очракта аларны коррекцияләргә кирәк булуы мөмкин.

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ–ҖАВАП

УРАЗА ТОТАРГА ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ



Тиздән зарыгып көтеп алган, гөнаһлардан чистарыну, яңару ае – Рамазан башлана. Ураза – ислам диненең биш баганасының берсе. Ул тәнебезгә саулык, күңелебезгә тынычлык, рухыбызга ныклык китерә. Изге гамәлгә организмны алдан ук әзерләү зарур. Шул очракта гына ураза җиңел тотылыр. Бу уңайдан диетолог Гөлназ ГЫЙМРАНОВА киңәшләрен бирә.

Уразага керер алдыннан организмны ничек әзерләргә?

Иң мөһиме – баллы ризык ашауны киметегез, майлы ризыкка өстенлек бирегез. Аксымлы, майлы һәм озак эшкәртелә торган ризык ашасак, энергия шактый озакка җитәчәк. Кеше энергияне шикәрдән яисә майдан ала. Майлы ит, атланмай, авокадо, зәйтүн мае ашасагыз, тамак тиз ачыкмас. Рамазан аена кадәр йоклау рәвешен көйләргә кирәк. Кичке сәгать уннан иртәнге сәгать икегә кадәр йоклау бик файдалы. Бу вакытта йоклаганда организмда мелатонин дигән гормон бүленеп чыга. Ул организмда бөтен гормоннарны көйли, шомлануны, баллы ашыйсы килү теләген бетерә, организмда майларны «яндыра». Рамазанга хәтле каһвә эчүне киметегез. Күбрәк су эчегез. Организмга файдасы булмаган шикәрле, чүпрәле камыр ризыклары, шоколад, кетчуп, йогуртлар ашамау, баллы сулар эчмәү эчәклекләргә яхшы тәэсир итәр.

Гадәттә, уразаның беренче ике көнендә баш авырта, бу нилектән?

Әгәр дә баллы ризыкка өстенлек бирсәгез, сәхәр вакытында канда глюкоза арта, ашамаганда – кими. Мондый үзгәрешләр кан басымына тәэсир итә, башны авырттыра. Организм сусызланса да, баш авыртуга китерә. Хәзерге заманда кеше ашауга өстенлек бирә, ә су эчәргә оныта. Әгәр дә организмда токсиннар (шлаклар, эндотоксиннар, гөмбәчекләр) бар икән, ураза тотканда интоксикация булырга мөмкин. Рамазан аена кадәр хиджамага барып, лимфаларыгызны чистартсагыз, яхшы булыр.

Ифтар вакытларында табында камыр ашлары мулдан була. Бу зыянлы түгелме?

Гомумән, камыр ризыгын файдалы дип әйтмәс идем, чөнки анда шикәр, чүпрә, эшкәртелгән ак он бар. Бу ризык тиз углеводка керә. Ул бик тиз авырлык артуга, эчәклек ялкынсынуына, сару кайнауга китерә. Камыр ризыклары ашамаганда кеше үзен җиңел хис итә – баш саф була, уйлау сәләте яхшыра.

Шевю
ДОМ ПАРИКОВ

ӨЛЕШЧӘ ЯКИ БӨТЕНЛӘЙ ЧӘЧСЕЗ КАЛГАНДА ПРОБЛЕМАНЫ НӘЗАКӘТЛЕ ХӘЛ ИТҮ

РӘСМИ БУЛМАГАН ШАРТЛАРДА

АЕРЫМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Казан, Себер тракты, 13
(843) 203-48-00 domparikov.ru

Реклама



МАТУР ИРЕННӘР СЕРЕ

Хатын-кызга карауга күз иң элек аның иреннәренә төшә. Сәламәтлек торышы турында да, кешенең холкы хакында да сөйли алар. Ирен тиресе бик сизгер ул, тиз картая, шуңа күрә битне генә түгел, аны да көн саен тәрбияләп торырга кирәк. «Моның өчен кыйммәтле косметика кирәк түгел», – ди массажист Ләйсән САБИТОВА. Иреннәр алсу булсын, күпереп торсын өчен, пилинг һәм дымландыру – иң кулае. Кан йөреп китсен, ирен тирәсендәге җыерчыклар бетсен өчен массаж ясыйлар. Аңа күп вакыт кирәкми.



- Иреннәрне бармаклар белән кысып, җайлап кына «дулкын» ясыйбыз. Аннары шулай тоткан килеш гармун кебек тартабыз.
- Иреннәрнең кырыйларын чеметкәләп чыгабыз.
- Авыз эчендә телне әле бер якка, әле икенче якка әйләндерәбез. Бу вакытта иреннәр бер-берсенә тиеп торырга тиеш. Әлеге массаж хәрәкәте бөтен тән мускуллары өчен файдалы.
- Иреннәрне теш щеткасы белән әкрен генә баскалап чыгабыз. Һич кенә дә ышкырга ярамый, тиреге зыян килүе бар.
- Перчатка киеп йә кулларны яхшылап юып, бармаклар белән ике яклап иреннәрне «каптырып», тышкы яктан массажлыйбыз. Аннан соң гармун кебек «тартабыз».
- Барлык күнегүләрдән соң, озак итеп «тпру» дигән аваз чыгарабыз. Бу күнегү иреннәр өчен аеруча файдалы. Аны көн дәвамында әледән-әле эшләп йөрсәгез дә була.
- Массажны тәгәлләгәннән соң, иреннәрне скрабларга онытмагыз.

Ләйсән Сабитовадан скраб рецепты: бер чәй кашыгы бал, бер чәй кашыгы шикәр комы, берничә тамчы авокадо маен (башка төрле файдалы май булса да ярый, мәсәлән, кокос мае) яхшылап болгатабыз да, шуның белән әкрен генә иреннәрне ышкыйбыз. Алар алсуланып китәр. Төнгә иреннәрегезгә бал йә май сөртеп ятсагыз, нәтиҗәсе тагын да яхшырак булыр. Матур булыгыз!



QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Брауни



«Аш-су» рубрикасы мәйданында яңа уенчы – Алмаз ГАФИЯТОВ. Бу егетне күпләр таныйдыр. Кайчандыр татар телевидениесендә «Батырлар» тапшыруы аша беренче адымнарын ясаган журналист бүген – спорт редакциясе мөхәррире, иң югары рейтинглы тапшыруларның берсен алып бара. Спорт турында тәүлек буе да сөйли ала. «Алмаз комментарий биргән хоккей уеннарын карап, татар телен камилләштерергә була», – ди җанатарлар. Әдәпле, ипле, тәрбияле чын татар егете. Алмаз исәбенә чибәр хатыны Гөлияне, уллары Айдан белән Айвазны да өстәп куйсак, чиста җиңүне аңа бирми мөмкин түгел!

Аш бүлмәсендә җаваплылыкны Алмаз үз өстенә бик сирәк ала. Ләкин пешергән ризыгын төгәл итеп, бөтен шартларын китереп әзерли. Язның беренче бәйрәме – 8 Март көнне уллары белән Алмаз, һичшиксез, аш бүлмәсендә булыр. Гафиятовлар командасы тәкъдим иткән тиз һәм җиңел рецепт буенча пешерелгән брауни белән сез дә якыннарыгызны сыйлагыз. «Янына чәчәк бәйләме дә өстәсәгез, «Иң яхшы котлау» буенча алтын медаль – сезнеке!» – ди Алмаз.

Кирәк 145 г кара шоколад / 135 г атланмай / 2 йомырка / 100 г шикәр комы / 1 кап ванильле шикәр / 1/4 чәй кашыгы камыр көпшәрткеч (разрыхлитель) / 80 г он / 35 г какао / тоз / әстерхан чикләвеге.













Эш барышы

- Май белән шоколадны су мунчасында (водяная баня) эретәбез.
- Йомырканы шикәр, ванильле шикәр, тоз белән туглыйбыз.
- Йомыркалы массаны шоколадлы масса белән кушабыз.
- Он, камыр көпшәрткеч, какаоны бергә кушып, массага салабыз. Шуңа әстерхан чикләвеге өстибез. Камырны яхшылып болгатабыз.
- Камырны формага агызабыз, 180 градуслы мичтә 25 минут пешерәбез. Брауниның эче тулысынча пешеп бетми, сыеграк була. Шуңа күрә тиешле вакытыннан артык тотарга ярамый.
- Тортны мичтән алгач, өстенә эретелгән шоколад яисә карамель агызабыз, әстерхан чикләвеге сибәбез. Кайнар браунины табынга туңдырма белән бирсәгез, тагын да тәмлерәк булачак.







Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



ӨЙНЕҢ ЯМЕ – ГӨЛЛӘРДӘ


Бегония

Төрләре күп булса да, бүлмәдә үскәннәрен шартлы рәвештә декоратив яфраклы һәм декоратив чәчәк ата торган ике төркемгә генә бүлик. Аларны тәрбияләү шартлары бертөрле диярлек.

Бегония күләгәгә чыдам. Бары эре һәм чуар яфраклылары гына яктылыкка таләпчәнрәк. Чәчәк атучы бегонияне дә кояш туры караган тәрәзә төпләрендә тотмаска кирәк: аларның яфраклары нәфис, эсседән көяргә мөмкин. Иң яхшысы – көнчыгыш яки көнбатышка караган тәрәзә төпләре.

Һава температурасы кисәк үзгәргәнне, үтәли җилләрне яратмый. Җәй көне температура 20–23, кышын 14–18 градус җылы булса яхшы. Сары чуптарлы чәчәк ата торганнары 13–18 градус җылыны кулайрак күрә.

Һаваның дымлылыгына таләпчән булса да, шәһәр фатирында да яхшы үсә. Җылылык торбаларына якын куярга гына ярамый. Дымлылык җитәрлек булмаса, пульверизатордан су сиптереп, һаваны дымландырырга була, ләкин гөлнең яфракларына су тидермәскә кирәк.

Кыска вакытлы корылыкны бегония җиңел кичерә, ә менә суны күп сипкәннән авырырга мөмкиннәр, бигрәк тә бүлбеле төрләре.

Язын һәм җәен ике атнага бер тапкыр ашларга кирәк. Чәчәк бөреләре яралганда калийлы-фосфорлы ашламага мохтаҗ. Чәчәк атмый торган төрләренә азотлысы кулай.

Бегонияне март урталарында күчереп утырталар. Ул җиңел, көпшәк туфракны ярата. Савыт гөлнең тамырына карап сайлана, шулай да артык тирән булмаганын алыгыз. Зураеп киткән төпләрен бүлгәләргә кирәк.

Көз ахырына таба бегониянең тынлык чоры башлана. Озакка түгел – 6–10 атна чамасы гына. Бу вакытта аларны ашлауны туктатып, 16 градус чамасы температуралы урынга куялар. Ләкин һава артык коры булмасын анда. Суны исә чамалап кына сибегез. Тынлык чорына кергәндә, бегонияне кыскартып кисеп, формалаштырырга мөмкин.


Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Замиокулькас, ягъни доллар агачы. Россиядә әле узган гасыр азагында гына популярлашып киткән үсемлек. Бик озак үсүе белән аерылып торучы суккулент. Бөтен гомеренә бер метр, метр ярым гына үсә.

Яктылыкка таләпчән түгел, күләгәлерәк урында да үсә ала, ләкин бу очракта үсеше бераз акрыная.

Гадәти бүлмә температурасында үзен яхшы хис итә, җәй көне 28 градус эсселеккә дә чыдый. Һаваның дымлылыгына исе китми, кыш көне хәтта җылылык торбасы янында да үсә ала. Шулай да ара-тирә җылымса душта коендырып алу зыян итми, яфраклары сафланып, чистарып китәчәк.

Доллар агачы озакка сузылмаган корылыкны җиңел кичерә, ә менә артык дымнан үләргә дә мөмкин. Җәй көне атнага – ике, кышын исә айга ике тапкыр су сибү җитә. Дымлылык җитмәвен үзе «әйтә» – яфракларын коя башлый. Ашлау белән дә артыгын мавыкмаска кирәк. Су сипкәннән соң, атнага бер тапкыр ашлый аласыз.

Яшь гөлне – ел саен, картрагын өч елга бер күчереп утырталар. Туфракның көпшәк, ә чүлмәкнең киң булмаганын ярата – таррак савытта тизрәк үсә. Күчерер өчен яз уртасы яхшы. Яз көне, үсемлек актив үскән вакытта, куакны формалаштырып кисәләр.

Замиокулькасны үрчетүе бик җайлы. Дымлы туфракка төрткән яфраклары да тамыр җибәрүчән. Куакны бүлеп тә үрчетергә мөмкин.


Замиокулькас


Эухарис

Эухарисның халык телендәге атамасы – Амазония лилиясе. Матур булса да, агулы үсемлек ул: сабый балаларыгыз, йорт җәнлекләрегез яфракларын, чәчәкләрен өзеп каба күрмәсен.

Амазония лилиясен көнчыгыш яки көнбатыш тарафка караган якта үстерү яхшырак. Туры кояш нурларын яратмый. Туган җире тропик урманнар булганга, дымга сизгер. Коры һавада начар үсә, чәчәк атудан туктый. Бүлмә һавасы коры булса, гөл чүлмәген дымлы керамзитка утыртырга мөмкин. Яфракларына су сиптергәнне яки дымлы тастымал белән сөрткәнне дә ярата.

Суны туфрагының өске өлеше кипкәннән соң мул итеп сибәләр, ләкин гөл суда утырырлык булмасын: артык дымлы туфракта суганчалары чери башлый.

Зур савытка утыртылган эухарис тиз генә чәчәк атмый. Тамырлары чүлмәккә тәрәлгәч кенә чәчәккә бөреләнә ул. Бер чүлмәккә берничә суганча утыртылганда матуррак күренә. Бу очракта савытның киңрәген алырга була. Ләкин чүлмәк тирән булмаска тиеш.

Амазония лилиясен чәчәк аткан чорда гына ашлыйлар. Ике атнага бер ашлау җитә.

Күчереп утыртканны авыр кичерә. Шуның өчен сирәк, өч-дүрт елга бер генә күчерергә тырышыгыз.

Эухарисның тынлык чоры юк диярлек. Чәчәк атып бетергәннән соң бер айга салкынчарак урынга куеп, ял иттереп алырга кирәк. Бу вакытта суны туфрагы кипкәннән соң гына сибәләр. Яктылык гадәти булсын.

Фото: www.pixabay.com

тест: сез кем: әйдәүчеме, ияреп китүчеме?

Сез кем: капитанмы, пассажирмы, лидермы, буйсынучымы, әйдәүчеме, ияреп китүчеме? Тәкъдим ителгән сораулар ярдәмендә җавапны табарсыз. «Әйе», «Юк», «Белмим» дип җавап бирегез.

1. Тормышта барысы өчен дә үзем җаваплы дип санныйм.
2. Кайберәүләр миңа карата мөнәсәбәтләрен үзгәртмәсәләр, бу кадәр проблемам булмас иде.
3. Уңышсызлыкларның сәбәбе турында уйлап утыруга караганда, нидер эшләүне кулайрак күрәм.
4. Кайвакыт үземне бәхетсез санныйм.
5. Әчкечеләр барысына да үзләре гаепле.
6. Тормышымдагы күп нәрсә өчен миңа тәэсир иткән кешеләр гаепле дип уйлыйм.
7. Салкын тидерсәм, үзем даваланырга тырышам.
8. Хатын-кызның кызулыгында, агрессив булуында башкалар гаепле.
9. Теләсә кайсы проблеманы хәл итеп була.
10. Миңа күрсәткән яхшылыкларны таный беләм, рәхмәт йөзеннән башкаларга да ярдәм итәргә яратам.
11. Конфликт була калса, беренче чиратта гаепне үземнән эзлим.
12. Юлыма кара мәче очраса, юлның икенче ягына чыгам.
13. Нинди генә хәлгә дучар булса да, һәркем көчле һәм мөстәкыйль булырга тиеш.
14. Үз кимчелекләремне беләм, ләкин янәшәдәгеләрнең кимчелекләремә йомшаграк булуларын телим.
15. Ситуацияне үзгәртә алмасам да, аны кабул итәм.

Балларны санагыз. 1, 3, 5, 7, 9, 11, 13 нче сорауларга «Әйе» дип җавап бирсәгез, 10 балл санагыз. 2, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 15 нче сорауларга «Юк» дип җавап бирсәгез, шулай ук һәрберсе өчен 10 балл санагыз. «Белмим» җаваплары өчен 5 балл кушыгыз.

100–150 балл. Сез – үз тормышыгызның капитаны. Тормышыгыз өчен җаваплылыкны үз өстегезгә аласыз. Авырлыкларны арттырмыйча гына, күпертмичә генә җиңеп чыгасыз.

50–99 балл. Сез бик теләп «рульне» үз кулыгызда тотасыз, ләкин кирәк чакта аны ышанычлы кулларга тапшыра беләсез. Сыгылмалылык, зирәклек һәм сизгерлек – сезнең юлдашыгыз.

49 баллга кадәр. Тормыш вакыйгаларына бик җиңел күнәсез. Авыр очракларда, үзегездән кала, һәркемне гаепләргә мөмкинсез. Чын бәйсезлек сезнең өчен ирешмәслек булып тоела.

йолдызнамә апрель

Кучкар. Уңышның югары ноктасына ирешерсез. Нәрсәгә генә тотынсагыз да, бәрәкәтле, нәтиҗәле эш булыр. Сезнең йолдызлы сәгатегез сукты дип әйтергә дә була. Бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз.

Үгезбозау. Тормыш энергиягез кимеп киткәнен сизми калмассыз. Бу – эшләү сәләтегезгә дә, үз-үзегезгә ышанычыгызга да йогынты ясарга мөмкин. Шуңа күрә планнарыгызны әлегә сер итеп саклагыз, аларга тотынмый торыгыз.

Игезәкләр. Активлык сорый торган эшлекле чорга аяк басасыз. Бар да үзегездән тора. Ярдәм кулы сузарга теләүчеләрдән баш тартмагыз. Элеккеге дусларның да, яңа танышларның да кирәге чыгып куюы мөмкин.

Кысла. Шикләнүләрдән, икеләнүләрдән баш тартыгыз! Артык сак булырга тырышуыгыз бер файда да китермәс. Сезне алда уңыш көтә. Ләкин аңа әзер булырга, ачылырга кирәк. Җиңел чор булмаса да, нәтиҗәсе сөендерәчәк.

Арыслан. «Тырышкан табар – ташка кадак кагар». Апрель аенда бу мәкальне үзегезгә киртләп куегыз. Бәлки, кайбер әйберләрне өр-яңадан башларга туры килер. Шулай булуына карамастан, бар да сез теләгәнчә килеп чыгачак.

Сөмбелә Зур тырышлык һәм күп көч таләп ителер бу чорда. Хисләрегезне тәртипкә салырга кирәк булачак. Башкаларга каршы торырга да туры килер, бәлки. Борчылмагыз, ай ахырына бу «язгы чыныгу» тәмамланыр.

Бизмән. Якыннарыгызга каты бәрелүдән, аларны нахакка рәнҗетүдән сакланыгыз. Әйе, шулай яхшырак булачак дип уйлыйсыздыр. Ләкин гаделлек өчен алар сүзенә дә колак салыгыз, урталык табарга тырышыгыз.

Чаян. Ыгы-зыгылы, мәшәкатьле бу чор сездән сабырлык һәм аек акыл таләп итә. Айның беренче яртысында үзегезне кулда тота алсагыз, соңрак әҗерен күрми калмассыз. Шуңа күрә көчегезне тыеп торырга тырышыгыз.

Укчы. Тынгысыз Укчыны уңыш арты уңыш көтә. Ниһаять, сезнең талантыгыз, тырышлыгыгыз, белемегез югары бәягә лаек булачак. Бу сыйфатларыгызны күбрәк ачар өчен яңа юллар, яңа мөмкинлекләр эзләгез. Һичшиксез, табарсыз!

Кәҗәмөгез. Финанслар темасы, керемне арттыру, муллык, иминлек турында гына уйлап, зур мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмагыз. Эшкә артык бирелмәгез. Сезгә хәзер тыныч, салмак тормыш рәвеше кирәк.

Сукояр. Сез бар нәрсәне дә уйлап эшлисез. Өстәвенә, бу чордагы активлыгыгыз да күпләрне сокландырырлык. Менә шушы ике сыйфатыгыз бу айда тормышның төрле өлкәләрендә уңышка ирешергә ярдәм итәчәк.

Балык. Иҗади активлык өчен уңышлы чор. Сездәге сизгерлек, кешене аңлый белү сәләте дә артып китәргә мөмкин. Ләкин тормышның рухи ягын алга чыгарып, чынбарлыктан ерагаймагыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







СОКЛАНУ ХИСЛӘРЕМНЕ СУРӘТЛИМ

Алена Әскәрованың картиналарын буяулары кибеп бетүгә үк сатып алалар.

Рәссам һәрбер күргәзмәсендә дә татарлыгын ассызыклый. «Иҗатымда җете төсләргә бай татар милли колоритын кулланам. Милли традицияләрне яхшы беләм, мин дәү әти-дәү әни тәрбиясендә үстем, аларның миңа карата булган уңай йогынтылары һәрчак истә. Әбием Бәдриәфә һәм бабам Җәләлетдин авыр, михнәтле елларда яшәсәләр дә, һәрчак шат күңелле булып, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылып, намаз укып гомер иттеләр. Бу мохиттәге хис-кичерешләр күңелем түрендә саклана, матурлыкны кечкенәдән тойдым. Һәрчак Аллаһы Тәгаләне истә тоттым һәм менә дини фәлсәфәле әдәбиятны тирәнтен өйрәнүгә килдем. Айшә исемен дә кабул иттем. Аллаһы Тәгаләгә догалар кылып, Аңа чиксез рәхмәтле булып яшим.

Әбием – кул эшләнмәләре остасы, җырлый да, бии дә, сәйләң һәм чигү җепләре белән чигә дә иде... Хатын-кызларга хас тырышлык сыйфаты минем холкымда да бар. Әнием Бибисафа сынлы сәнгатьтән ерак һөнәрдә булды, ә мин балачактан рәсемнәр ясадым. Гомерем буе хөр рәссам мин. Картиналарны даими язам, осталык дәресләре дә үткәрәм, бакча эшләрен дә алып барам, гаилә мәшәкате дә – минем өстә, кышларын исә тегәм, бәйлим... Олы улыбыз үзен кино төшерү өлкәсендә сыный, төпчек улыбыз әле мәктәп укучысы. Хатын-кыз беркайчан да авырлыклар алдында сыгылып төшми, бирешми ул: һәрчак иҗатта, алга баруда, балалар тәрбияләүдә... Хатын-кыз, балалар галәме белән бәйле әсәрләрем күп. Хатын-кыз образларым – метафоралар, аларны җан образы дисәм, төгәлрәк булыр. Җан үсеше – иң мөһиме һәм гаять кадерлесе! Әлеге идеяләрем башкаларның күңелләренә дә барып ирешеп, картиналарым күпләрне үзенә җәлеп итә».

Алена Әскәрова Чиләбедә туа, шунда яшәп иҗат итә. Чиләбе сынлы сәнгать училищесын уңышлы тәмамлауга ук, Санкт-Петербургның И. Репин исемендәге сынлы сәнгать академиясе курсларына укырга чакырыла. Питерда калырга өндәүче рәссамнар да була, әмма гаилә кору сәбәпле, Төньяк башкалага башка әйләнеп кайтмый.

Рәссам – «Инкор» Халыкара ассоциациясе, Россия Рәссамнар берлегенең Чиләбе рәссамнары бүлеге әгъзасы. Төрле милләт һәм төрле конфессиядәге хатын-кыз рәссамнарны берләштерүче «Многолетники» яшьләр иҗат төркемен оештыручыларның берсе дә. Рәссам ханымның хезмәтләре төбәкара, бөтенроссия, халыкара күргәзмәләрдә экспозицияләнә. Сигез шәхси күргәзмәсе Урал төбәге калаларында зур уңыш белән узган! Дизайнерлык өлкәсендә дә уңышлы эшли, декоратор буларак диварлар бизи, интерьер, барельефлы сәнгать әсәрләрен иҗат итә.

Алена өч тапкыр «Арт-шоу» премиясенә лаек булган. Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан аңа Рәхмәт хаты да тапшырылган. Булдыклы ханым Чиләбе өлкәсендә узучы барлык төрдәге милли конкурсларны әзерләүдә дә бик актив катнаша.


«Җиребезнең искиткеч дәрәҗәдә сихри, гаҗәеп икәнен һәр бала аңлый, моңа чын-чынлап куана. Әмма яши-яши кеше үзенең бу халәтен җуя бара, шуңа күрә дә мин үз әсәрләремдә дөнья ямен чын могҗиза буларак сурәтләп, башкаларны да, балачактагыдай, барысы белән канәгать, рәхмәтле булган әлеге халәтебезгә кайтырга өндим».

Аленаның әсәрләре дәүләт музейларында, Третьяков дәүләт галереясында, төрле шәхси коллекцияләрдә саклана. «Аллаһы Тәгалә тудырган матурлыкны кабатлап булмый. Рәссам бу матурлыкны сурәтли генә. Сәнгатьнең максаты – боеклыктан коткару, илһам өстәү, җиребезне ярату», – ди Алена Әскәрова.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













АЛЕНА ӘСКӘРОВА

PRESSA



сеть ювелирных салонов

ЭКСКЛЮЗИВ

КУЛАЙ БӘЯДӘН ЗАТЛЫ ЗӘРКӘН

Казан, Р. Зорге ур., 67; Бутлеров ур., 29; Чистай ур., 15/16; Восстание ур., 62.

exclusive.kazan www.exclusive-jewelry.ru РЕКЛАМА

